Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

06

июнь 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ВИКТОР ФЁДОРОВ. «САБАНТУЙ»

ИЗГЕ БОЛГАРДА – ИЗГЕ ҖЫЕН

20 майда «Изге Болгар җыены» булып узды. Бу юлы Болгар җиренә Россиянең төрле төбәкләреннән 40 мең мөселман җыелды. Мәгълүм ки, 1095 ел элек (310 һиҗри, 922 милади ел) 21 майда Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кабул ителә.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

5 (281)

май 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

32

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Нури Арслан*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Чатырлар лагере. Фестиваль-вакыйгалар комплексы**
6 **Юрт татарлары.** *И.Торопицын*
13 **Югары мәдәниятне саклау юлында: Габделбари хәзрәт Исаев.** *Ә.Бостанов*
20 **«Идел»дә Каюм Кулаткы мәкаләләре**
24 **Итил, Саксин, Хаҗитархан, Әстерхан...** *Ф.Җәүһәрова*
26 **Финляндиядә татар әсирләре.** *Ч.Сафиулла*

ТАТАР ГАМЕ

32 **Тормыш яме** (*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон әңгәмәсе*)
42 **Авыл — милләтнең бишеге**
49 **Муса авылы тарихы**
54 **Галәми уйлы татар улы.** *А.Хәмзин*

ДИНИ МИРАС

58 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
68 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
74 **Өч анкета**

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

78 **Гадел Кутуй**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

81 **Олуг әдипкә бәйле кайбер истәлекләр.** *Л.Хәмидуллин*
84 **Баттал булуын онытмады...** *Ф.Баттал*

6 **ЮРТ ТАТАРЛАРЫ**
Илья Торопицын

104 **ҖИҢҮ ПЛАКАТЛАРЫ**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Минем беренче театрым.** *Н.Дунаев*
93 **«Син сазыңны уйнадың...»** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

96 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
98 **Тел турында уйланулар.** *Һ.Атласи*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Җиңү плакатлары**
106 **Олы Мәрәтхуҗа һәм Туфан Миңнуллин**
110 **Ядкярләргә – бер гасыр.** *Р.Садыйкова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның май ае.**
114 **«Безнең мирас» хәбәрләре**

ШАЯН МИРАС

116 **«Шалтыр-шолтыр шаулата...»**

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Май*
119 **Мирасворд**

Заказ №А-1056. Тираж – 2000 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.04.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм А.Дубин, С.Львов, Татарстан Милли музее архивларыннан, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Чишмә янында». Киндер, майлы буяу.
И.Мусин рәсеме

НУРИ АРСЛАН
(14.09.1914 – 12.04.1991)

* * *

Уе юкның – теле юк,
Теле юкның – иле юк.

* * *

И кыска гомер – дөньяга
Бер карап алу гына...

* * *

Ир гайрәтне тәвәккәлдән ала:
Йә башын сала, йә батыр кала.

* * *

Күп белүдә, булдыруда түгел хикмәт,
Булдырам, дип ышануы – үзе хикмәт.

* * *

Яманнан яман туса – гаҗәп түгел,
Яхшыдан яман туса – хаҗәт түгел.

* * *

Туган – кандаш кына. Ләкин
Яши туганлык хакы.
Ни җитә дуслык хакына?
Чын дус – туганнан якын!

* * *

Күп сөйләүчән була аз белгән.
Акылы кыскаларның теле озын.
Күпне белгән – тыйнак ул телгә,
Хөрмәт итә сүзен, сине, үзен.

* * *

Эчемлек тә әйбәт – тәмен белеп
Эчә белсәң генә,
Бүген таңнан торып үкенмәслек
Булсаң кичәгеңә.

* * *

Купшы шигырь – бокаллардан ташып
Күтәрелгән шампан күбеге...

* * *

Мин табигать кочагында
Һәрвакыт шатлык тоям,
Ул – мине җиргә яраткан,
Шат хәят биргән оям.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2017

Болгар. Чатырлар лагере

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Чатырлар лагере Болгар шәһәрлегенең үзәк өлешендә урнашкан. Хәрәкәтчән корылмалардан – палаткалардан, станционар рәвештә куелган гомуми кулланыш биналарыннан гыйбарәт. Инвесторы – НПО «Татэлектромаш» ААҖ (генераль директоры – Илдус Исламов). Чатырлар лагере җәй вакытында зыярәт кылучыларны, Болгарны карарга килүчеләрне һәм туристларны урнаштыру максатында төзелгән.

Чатырлар лагере 2011 елда сафка бастырылды. Җәй саен биредә «Изге Болгар җыенында» катнашучылар, җәй көне археология практикасын үтүче студентлар яши. Лагерь төрле фестивальләрдә, слетларда катнашучыларны кабул итә. Мәсәлән, 2011 елда биредә Беренче республика балалар тарихи фестивалендә катнашучылар яшәде. «2012 елда чатырлар лагеренда «Сәләт» яшьләр форумы чаралары уздырылды.

Болгар. Фестиваль-вакыйгалар комплексы

Спас районының фестиваль-вакыйгалар комплексы Икмәк музее янында, Болгар шәһәрлегенең көньяк чиге артында урнашкан. Бу – хәрәкәтчән, җыелма конструкция. Аның эчендә 500 урынлык тамаша залы бар. Комплекс массакүләм тамаша чаралары – концертлар, спектакльләр, иҗат очрашулары һәм башкаларны үткәрүгә җайлаштырылган. ■



Әстерхан татарлары – Түбән Идел буенда юрт татарлары исеме белән дә мәгълүм төрки халык. 1556 елда Әстерхан ханлыгы яулап алынып, татар җирләре Мәскәү дәүләте составына кергәннән соң да юртлар Әстерхан шәһәренең тирә-ягында яшәүне дәвам иткән, җир эшкәртү, нигездә бакчачылык, терлекчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнгән.

ЮРТ ТАТАРЛАРЫ

Илья Торопицын

XVI гасырның икенче яртысында Әстерхан халкы яңа сәяси шартларга яраклашырга мәҗбүр була. Патша сәясәте акрынлап җирле төрки халыкларны дәүләт эшенә җәлеп итүгә юнәлдерелә. Әстерхан татарларының биләмәләре сакланып кала. Аларның җирләре Идел елгасының ике як ярында да, көнчыгышка таба Бузан елгасына таба, күчмәннәр яши торган Нугай Урдасы белән чиктәш булган. Әстерхан татарла-

рына дин иреге бирелгән, башкалар белән бергә алар да казнага ясак түләгән һәм Мәскәү дәүләте файдасына төрле йөкләмәләрне үтәгән.

XVI гасырның икенче яртысында Түбән Идел буенда яшәүче татарлар рус хакимияте вәкилләре – нугайларга каршылык күрсәткән. Патша хакимияте әстерхан татарларының Бузан елгасы көнбатышындагы җирләренә кул сузмаган. Нугай бие Исмәгыйльнең үзенә дошман булган татар морзаларын Әстерханнан куу турындагы таләбен дә Мәскәү түрәләре инкяр иткән. Шул ук вакытта, татарлар Явыз Иван тарафыннан оештырылган канкойгыч сугышларда, аеруча Кавказ һәм Ливон яуларында катнашырга мәҗбүр ителгән.

Мәскәү дәүләте составында яшәүгә барча төркиләр дә риза булмаган. 1569 елда кырым-төрек гаскәриләренең Әстерханга һөҗүме вакытында, әстерхан татарлары аларга актив ярдәм итә. Бу елгы вакыйгаларны, җирле татарларның Россия хакимиятенә каршы иң эре сугышларыннан берсе, дип атарга мөмкин. Нәтиҗәдә, актив сугышучы халыкның байтагы чит җирләргә һиҗрәт кыла.

Әстерхан татарларының бер өлеше патша хакимияте тарафыннан илнең башка урыннарына күчерелгән, дип әйтергә дә дәлил бар. 1570 еллар башына нисбәтле документта юртларның Новгород җирләрендә игенчелек белән шөгыльләнүе теркәлгән.

XVII-XVIII гасырларда юрт татарлары тормышына төрле социаль-сәяси һәм икътисади процесслар йогынты ясаган. Әстерхан татарлары, Идел елгасы, Хәзәр диңгезе буе, Төньяк Кавказ тау итәгендә яшәүче кавемнәр, шулай ук Көнчыгыш илләреннән, Урта Азиядән килгән башка халыклар белән дә тыгыз мөнәсәбәттә яшәгән. Вакытлар узган, нугайларның да бер өлеше юрт татарлары белән кушылып, туганлашып беткән. Әмма туганлык мөнәсәбәтләре, юртлар белән нугайлар арасында кискен каршылык булмаган, дигән сүз түгел. Дөрес, әстерхан татарлары Мәскәү белән уңай мөнәсәбәттә торган һәм Әстерхан тирәсендә күчмә тормыш белән яшәүче нугай морзаларына даими ярдәм иткән. Шул ук вакытта юртларның русларга салым түләүдән баш тарту һәм Кара диңгез буе, Төнья Кавказга килеп төпләнгән нугай морзалары олысына һөҗүм итү фактлары да билгеле.

Юртларның һинд сәүдәгәрләре белән дә үзенчәлекле мөнәсәбәте турында әйтергә кирәк. Әстерханга сәүдә эше белән килеп, шунда төпләнеп калган индусларның күбесе, С.Разин восстаниесе вакытында җан һәм малларын саклап калыр өчен, җирле татар гаиләләренә сыенган, ислам динен кабул итәргә мәҗбүр булган, татар кызларына да өйләнгәннәр. XVIII гасыр-XIX гасыр башында Россиягә хатынсыз килгән һинд сәүдәгәрләре Әстерхан шәһәрендә сөеклесен юртлар арасыннан бик тиз табу бәхетенә ирешкән. И.Г.Георги күп һиндларның татар хатыннары белән яшәве турында яза. Н.Я.Озерецковский искәртүенчә, еш кына юрт татарлары, һиндларга зур суммага бурычлы булып, финанс коллыгыннан хатыннарын һәм кызларын биреп котылган. 1740 елларга кадәр кайбер юртлар һинд сәүдәгәрләренең Ирандагы приказчигы да булып торган, шул ук вакытта үзләре дә фарсылар белән мөстәкыйль рәвештә сәүдә эшләре алып барган.

Әстерхан татары

Гомумән, Әстерханның тирә-ягында яшәүче юртлар көнчыгыш илләреннән килгән сәүдәгәрләр белән аеруча яхшы мөгамәләдә булган, аеруча алып-сату эшләрендә бергә хезмәттәшлек иткән, аларга хезмәткә кергәннәр, үзара гаилә корганнар, бистәләренә күчеп тә киткәннәр. Бу мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә, юртларның башка төрки халыклар белән туганлык мөнәсәбәте ныгыса, икенчедән, сәүдә белән шөгыльләнү өчен киң мөмкинлек тә ачылган.

Юртлар җирле рус түрәләре тарафыннан даими күзәтү астында яшәгән. Дәүләткә тугры хезмәт иткәне өчен аларга бүләкләр бирелгән. Бу очракта җирле түрәләр юрт морзасының дәрәҗәсен, үз халкына йогынты ясарга сәләтле кеше булуын һәм дәүләт алдында казанышын истә тоткан.

Дөрес, Әстерхан татарлары берничә мәртәбә канәгатьсезлек тә белдерә. 1717 елда Кубань солтаны Бәхетгәрәй Түбән Идел буена һөҗүм иткән вакытта, юрт татарлары, ыгы-зыгыдан файдаланып, баш күтәрә һәм аларның бер өлеше Россиядән китәргә мәҗбүр була. XVIII гасырда юртлар гаиләләре белән гадәттә Төньяк Кавказга аеруча еш качкан, бу күренеш сәяси каршылык белдерү төсмерен алган. 1727 елда бер төркем юртлар качып киткәннән соң, Әстерхан губернаторы И.А.фон Менгден тотылган качакларны халык алдында хөкем итәргә – татар сәүдә сафлары һәм урамнары буенча йөртеп, чыбыркы белән суктырырга, хәтта кемнеңдер качып китәчәген белеп, бу турыда хәбәр итмәүчеләрне җәзаларга да уйлый. Качакларны эзләргә гаскәр һәм җирле төрки халыклар күтәрелгән, аларны сыендырмасын, дип, Төркиягә дипломатик басым ясалган.

Качып китүдән тыш, юртлар үз хокуклары өчен башка ысул белән дә көрәшкән. XVIII гасырда Татар һәм калмык эшләре конторасы мәхкәмәсе җитәкчеләренә карата Әстерхан татарлары тарафыннан булган шикаятьләр берничә мәртәбә вазифаи затларның эштән азат ителүе белән тәмамланган.

Күчмә кабиләләрнең һөҗүме, Әстерхан губернасында төрки кавем киму нәтиҗәсендә иррегуляр гаскәр җитмәү сәбәпле, 1737 елда хакимият йомышлы кешеләрнең яңа категориясен – әстерхан казакларын формалаштыра, аңа иң элек чукынган калмыклар керә. Әстерханда В.Н.Татищев губернатор булган чорда (1741-1745), юрт җәмгыятенең эчке структурасын казак гаскәриләре принцибында үзгәртеп кору буенча тәкъдимнәр карала. Эш азагына кадәр җиткерелмәсә дә, юртлар өстенә шактый күп вазифа йөкләнә. Аларны тышкы – хәрби һәм дипломатик, эчке – талау, җәбер-золымнар белән көрәш, казна йөген ташу, почта тарату, дәүләт файдасына, Мәскәүгә яки армиягә ат бирү кебек эшләргә җәлеп итәләр. Төрле телләрдә камил аралашкан юртларның хезмәте илчеләрне,

Әстерхан татары кызы

Әстерхан аша узучы аеруча мөхтәрәм юлчыларны транспорт белән тәэмин итүдә һәм якындагы крепостька кадәр озатып барганда, чит илләрдә дипломатик бурычларны башкарганда аеруча кирәк булган. Нәтиҗәдә, XVIII гасырда юртларның Әстерханнан Царицын һәм Кизляр арасындагы почта трактларында хезмәт йөкләмәләре арткан. Шул ук гасыр урталарында исә дала табигатен яхшы белгән халыкны сода ясауда кулланылган үлән җыю эшендә дә файда-

ланганнар. Тырыш юртларның хезмәте өчен җирле хакимият һәм Әстерхан бакча конторасы арасында үзара көрәш барган. Бу һәм башка актуаль мәсьәләләр 1767 елда Әби патшаның Уложенная комиссиясенә юрт татарларыннан вәкил итеп җибәрелгән Бәйморза Урысовның наказында чагылыш таба.

Юрт татарлары XVII гасыр башында болгавыр заман вакыйгалары, 1705-1706 елгы Әстерхан восстаниесе, 1670-1671 елларда С.Разин, 1773-1775 елларда Е.Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышларының үзәгендә катнашкан.

Болгавыр чорда юрт татарлары воеводалар Ф.Шереметев һәм И.Салтыков җитәкчелегендәге кораллы сугышларда катнашкан, Олы Нугай Урдасына яу чапкан. 1705-1706 еллардагы Әстерхан восстаниесендә җирле төркиләрнең катнашуына, беренчедән, Әстерхан хакимияте алып барган сәясәткә канәгатьсезлек белдерү сәбәп булса, икенчедән, аларны моңа калмыклар һөҗүменнән саклану ихтыяҗы да этәргән. Юрт татарлары барлык баш күтәрүчеләр белән дә актив хезмәттәшлек иткән, патша хакимияте тарафдары булган калмыкларга каршы да көрәшкән, шулай да, зирәклек күрсәтеп, эзәрлекләүләрдән качып котыла алганнар. С.Разин җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы да юртларның тормышында тирән яра калдыра. Нәтиҗәдә, татарларның күбесе Төньяк Кавказга күченергә мәҗбүр була. Шуңа да карамастан, юрт татарлары, баш күтәрүчеләрдән яшереп кенә, качып китүчеләргә ярдәм күрсәткән, үзәк хакимиятнең Әстерханга патша грамоталарын ташу турындагы йөкләмәсен дә үтәгән. Әстерханга патша гаскәриләре килү белән, төрки халыклар идарә итүче хакимияткә ачыктан-ачык ярдәм иткән һәм воевода И.Б.Милославскийга С.Разин восстаниесен бастырырга булышкан. Е.Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы вакытында исә юрт татарлары түрәләргә үзләрен хакимияткә каршы көчләрне бастыру өчен җитди хәрби куәт түгел икәнлекләрен күрсәтә.

Гомумән, XVII-XVIII гасырларда юрт татарлары баш күтәрүчеләр белән конфликтка кермәскә тырышкан һәм бу аларның күпмедер дәрәҗәдә куркынычсызлыгын да тәэмин иткән. Үзәк һәм җирле хакимият юрт татарларын баш күтәрүчеләргә каршы файдаланырга омтылган. Үлемнән качып котылырга өлгергән патша хакимияте вәкилләре, аеруча хәрби башлык һәм җирле түрәләр еш кына юртларда үзләренә сыену урыны тапкан. Бу очракта әстерхан татарлары баш күтәрүчеләр белән үзара килешүләр дә алып барган. Түбән Идел буендагы хакимият өчен хәлиткеч көрәшләрдә патша гаскәриләре әстерхан татарларының хәрби ярдәменә һәрвакыт өметләнә алган.

Юрт татарларына XVII йөз-XVIII гасырның беренче яртысында Төньяк Кавказ һәм Кырым ханлыгы белән сәяси мөнәсәбәтләрдә төрле дипломатик вазифалар да йөкләнгән. Воевода һәм губернаторлар аларга хатлар йөртү, чик буенда хәрби-сәяси вазгыять турында мәгълүмат җыю эшен ышанып тапшырган. Юртларның аеруча мөхтәрәм вәкилләре тау һәм күчмә халыкларның җитәкчеләре, Кубань сераскерлары һәм кырым ханнары белән сөйләшүләр алып баруда турыдан-туры катнашкан.

Рус-калмык корылтайлары да юртларның актив катнашында уза.

XVIII гасырда М.Булатаев калмык ханы Дондук Омбоны русларга яңадан буйсынырга күндерә. Соңрак Россия хакимияте калмыкларны 1735-1739 елларда Төркия белән сугышларда файдалана.

Россия түрәләре Урта Азияне яулап алганда да юртларның ярдәменнән файдаланган. Хакимият ул төбәккә разведка ясау, сәүдә эшләрен җайга салу эшләрендә, сугыш һәм солых вакытында җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен яхшы белгән юртларга еш мөрәҗәгать иткән. Мисал өчен, 1620 елда Бохарага рус илчесе Иван Хохлов белән берничә юрт татары да җибәрелә. Хәзәр диңгезе буендагы разведка вакытында аларның икесе төрекмәннәргә әсир төшә, ә берсе, әзәрлекләүдән качып, каршы якның планнарын сөйләп, рус илчелеген бәла-казадан коткарып кала. Төрекмәннәр илчеләр белән һөҗүм итешмәү һәм үзара сәүдә эшен җайга салу турында сөйләшә. Әмма, Россиягә таба кайтырга чыккач, төрекмәннәр, килешүне бозып, аларны куып җитеп талый, тоткынлыкта өч ай булганнан соң гына, илчеләр азат ителә.

Юртларның аеруча мөһим вазифасы хәрби хезмәт булган. XVII гасыр-XVIII гасырның беренче чирегендә әстерхан татарлары Россия дәүләте оештырган күп санлы сугышларда катнашкан. 1613-1618 елларда юртлар, рус гаскәриләре составында, Речь Посполитая белән сугышкан. 1615 елда А.Ю.Лисовский отрядының әзәрлекләвенә каршы көрәштә, 1616 елгы Литва походында, 1617-1618 елларда Можайск бәрелешләрендә, 1618 елда Пафнутьев монастыре янындагы һөҗүмнәрдә һәм шул ук елның октябрендә Мәскәү астындагы сугышларда татар каны аеруча күп коелган. 1610-1617 еллардагы рус-швед сугышында да юрт татарлары шведлар тарафыннан камап алынган Псков шәһәренә юл тоткан И.Д.Плещеев отрядында сугышкан.

Украинаны Россиягә кушу максатыннан оештырылган рус-поляк сугышы башлангач, патша Алексей Михайлович әстерхан

татарларына Польшага каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашырга боера. Түбән Идел буенда яшәүче төркиләр 1654 елда Смоленск өчен бәрелешләрдә, шулай ук Беолоруссия территориясендә дә сугыша.

XVII гасыр урталарында булган рус-фарсы сугышлары вакытында Терек елгасы буена, дворян һәм бояр балалары белән бергә, әстерхан морзалары да җибәрелә. Алар фарсы һәм кумык гаскәрләре һөҗүмнәрен туктатуга ирешәләр.

Юрт татарлары Кырым ханнары белән сугышларда берничә мәртәбә катнаша. 1646 елда әстерхан татарлары, нугайлар белән бергә (2350 хәрби), кенәз С.Р.Пожарский җитәкчелегендә кырым һәм азовлыларга каршы сугыша. 1678 елда татарлар рус-төрек сугышына җибәрелә. Алар, кенәз К.М.Черкасский җитәкчелегендәге җыелма полк составында, Чигирин шәһәре янында, төрек һәм кырымлыларга каршы канкойгыч бәрелешләрдә катнаша.

Петр I патшалык иткән дәвердә исә әстерхан татарлары шведларга каршы оештырылган Төньяк сугышта, 1708 елда Терек буе, 1717 елда кенәз А.Бекович-Черкасскийның Хива экспедицияләрендә катнашалар. Соңгы сәфәр уңышсыз тәмамлана: кенәз һәлак була, татарларның да күбесе әсир төшә. Бай татарлар бу әсирлектән берничә елдан соң гына йолым түләп котыла алган.

XVII гасырның беренче яртысында юрт татарлары, рус гаскәре составында мөстәкыйль көч буларак, әмма патша хәрби җитәкчелеге командасында, Мәскәү дәүләте оештырган барлык сугышларда да кан койган. XVII гасырның икенче яртысы-XVIII гасыр башында исә юртлар, патша воеводалары оештырган сугышларда катнашыр өчен, Түбән Идел буенда барлыкка килгән җыелма хәрби отрядлар составына кертеләләр. Дөрес, Әстерхан татарларының сугышларда катнашуы чикләнгән булган. Алар рус армиясенә сугышның башыннан азагына кадәр түгел, ә аерым хәрби бәрелешләргә генә чакырылган. Сугышта катнашканнары өчен бүләк буларак, Мәскәү дәүләте әстерхан татарларына акча һәм калҗа малы, шул исәптән әсирләр белән дә бүлешү хокукы биргән.

XIX гасырда юрт татарлары дәүләт крестьяннары категориясенә кертелә. Замандашлары аларны Түбән Идел буеның иң хәлле, бай кешеләре буларак тасвирлаган. Бу чорда берничә корабка ия юрт байлары барлыкка килә. 1854 елда сәяхәтче **П.Небольсонның:** *«Юртларның хезмәт сөючәнлеге – үрнәк, алар гадел, нык һәм үҗәт характерга ия. Үзләрен тыныч һәм мәһабәт, горур тоталар»*, – дип язып калдыруы – моңа бер дәлил.

Гомумән алганда, юрт татарлары XVI гасырның икенче яртысы-XIX гасырда Россиянең барлык вакыйгаларында да диярлек катнашып, дәүләтнең социаль-икътисади тарихында сизелерлек эз калдырган. Аларның мөселман һәм төрки халыклар белән уртак телне җиңел табуы, тырыш, намуслы һәм яуда батыр булуы аеруча югары бәяләнгән. ■

Безнең мирас №5 май 2017

Югары мәдәниятне саклау юлында: Габделбари хәзрәт Исаев

Әлфрид Бостанов

Габделбари хәзрәтнең гаилә альбомын карасак, Сталин чорында яшәвен күзаллау өчен, ике фоторәсемне чагыштырырга чакыруын күрәбез. Үзгәреш чыннан да зур була. Пролетариат сафына баскан Габделбари Исаев Бөек Ватан сугышыннан бөтенләй икенче кеше булып кайта. 1970 нче елларда министрлыкка җибәргән рәсми хатта, сугыш тәҗрибәсен тәфсилләбрәк сурәтли, үзгәреш сәбәпләре дә аңлашыла: *«Я был призван в 1941 году в июне месяце из города Уфы Башкирии и меня зачислили в 441 саперный батальон, где я кончил курс по подготовке хим.инструкторов, поскольку я в 1939 году был инструктором ПВХО (противовоздушная и противохимическая оборона), подготовил допризывников, за что получил благодарность Башквоенкомата. В лагере Чебаркуль мне присвоили воинское звание старший сержант. Наш батальон со всеми дивизиями был направлен на фронт в октябре или ноябре 1941 года. Мы прибыли в город Лехославль, откуда уже пешком в город Калинин в декабре с участка фронта г.Торжок и Ржев, был ранен под Ржевом. Помню, нас включили в пехотные части, наш капитан был товарищ Плотников. Он погиб под Ржевом. Я его отправил в тыл, но сам в это время был ранен. Лежал в селе, имя которого не помню. После нас окружили, мы – ходячие солдаты сумели вырваться из окружения и за железной дорогой стояли советские войска. Они нас проверяли и отправили в тыл между г.Сычевка и Белым. Мы долго ходили и прибыли в город Неледово, где партизанский отряд, нас несколько человек встретили, кормили и отправили в госпиталь (в монастыре), но нас повторно бомбили. Машина горела, ходячие спасались в лесу, дошли до госпиталя. После обработки, отправили пешком до станции Кукушкино. Оттуда поездом до Москвы, там лежали в госпитале (помню это местечко, Кремлевские санитары). После выздоровления, отправили в часть 1034 Краснознаменного полка Уваровка, Гжацк, Можайск. В лесу нас назначили в часть, а меня оставили в комендантской части, где я охранял Красное Знамя, был разводящим. После меня отправили в пехотное училище, г.Уфа. Это март месяц 1942 года. Там я учился до октября месяца. После отправили на фронт. В ноябре месяце нас отправили на Сталинградский фронт, звания не успели получить. В полку я служил на интендантской службе, по званию был старшиной. После занятия города Калач, в конце ноября я был ранен под деревней Платоновка, оттуда направили в госпиталь, город Зиметчина, где я лежал до марта месяца, где был комиссован. В Приволжском военном округе дали удостоверение инвалида Отечественной войны 3 группы по зрению. После возвращения состоял на учете Ждановского военкомата, поступил на работу в Министерство коммунального хозяйства и заготовки для военных и других материалов. Получил медаль «За Победу» в Уфе, медаль «За трудовую доблесть» в Уфе, медаль «За Победу» (1975 г.) в городе Ленинграде».*

Ахыры. Башы 4 нче санда.

Монда һәм алда күрсәтелгән фоторәсемдә, әлбәттә, ватанпәрвәрлек хисе йөзгә чыгып тора. Ике мәртәбә җәрәхәтләнгән, күрү сәләтен югалта язган мөселман Совет ватанына ихлас мәхәббәт белән карый. Бу күренеш Рәсәйдәге ислам тарихын өйрәнү өчен гаять әһәмиятле. Чөнки сугыш кырында кан койган мөселманнар, кайчандыр муллаларга, мәчет-мәдрәсәләргә каршы көрәшкән Советлар Союзын исламга дошман буларак түгел, ә үз ватаннары итеп кабул итеп, анда дин өчен махсус урын таләп итәләр, Аллаһ йортларын яңадан торгызуны сорый башлыйлар. Бу борылышны «мөселман ватанпәрвәрлеге» дип исемләсәк, һич кенә дә ялгышмабыз һәм аның тамырлары Бөек Ватан сугышы чорында ята.

Габделбари хәзрәт, Уфага кайтканнан соң, үз вазифасын башкарырга мөмкинлек таба: яңа тергезелгән Диния нәзарәтендә эшләп китә һәм 1947 елда Уфада мөселман съездында катнаша. Гади халык сугыштан соң да мәчетләрдә күп җыела. Дин әһелләренең шактые сугыш беткәч, бигрәк тә Сталин үлеп киткәннән соң, шәһәрләргә бара һәм анда еш кына яшерен рәвештә дин сабагын укыта. «Шәһәр», дигәндә, әлбәттә, ул вакытта Уфаның чите гади авылдан бик аерылып тормаган. Фоторәсемнәргә күз салсак, арттагы планда бер катлы агач йортларны, ә алар янында гади кешеләрне генә күрәбез. Шулай да халыкта ул чор шәһәр мәдәниятенең киң таралган бер билгесен – эшләпәләр киюне искәртергә кирәк. Тәкъдим ителгән ике фотосурәт профессиональ фотограф тарафыннан төшерелгән. Күргәнебезчә, фотографның эше күпләрне кызыктыра: халык камерага караган. Гади кешеләр рәсемгә төшәчәкләрен алдан белмәгән, дип уйлыйбыз, шуңа күрә дә алар махсус киенеп тормаган. Фотода этнографик реализм сизелә: кешеләрнең киемнәре, йөзгә чыккан хис-кичереш, хәтта ничек утыру рәвешләре дә табигый. Бу рәсемнең инкыйлабка кадәр төшерелгәннәреннән аермасы зур. Беренчеләре күбрәк театр сәхнәсенә охшаш булса, икенчеләрендә исә кешеләр йөзендә тормыш кайгысы чагыла, ачы чынбарлык алгы планга чыга.

Габделбари хәзрәт, 1952 елда беренче тапкыр хаҗга барып, берничә ел Уфа шәһәрендәге икенче зират мәчетендә имам-хатыйп вазифасын үтәгәннән соң, 1956 елда Ленинград шәһәренә җибәрелә. Андагы мәчет сугыш вакытыннан соң бик авыр хәлдә калган була. Шуңа күрә яңа мөфти Шакир Хыялетдинов (1890-1974), шәһәргә махсус килеп, мәхәлләгә яңа имамны тәкъдим итә. Габделбари хәзрәт өстенә мәчетне ремонтлау, дин эшләрен җайга салу вазифасы йөкләнә. Ул вакытта мәхәлләдә халык күп һәм, кагыйдә буларак, бер генә милләт кешеләре – татарлардан гына торган. Мәхәлләдәгеләрнең бер өлеше яңа имамга зур ышаныч белдерсә, икенчеләре, киресенчә, хәзрәтне өнәми, аңа зыян китерергә тырыша.

Габделбари хәзрәтнең 50 яшьлек юбилеена багышланган мәҗлестә укылган тәбрикнамәдә мәхәлләдә булган кыенлыклар да искә алына[1]. Анда Г.Исаевның дошманнары булуына ишарә бар. Моны ул үзе дә 1959 елда Диния нәзарәтенә адресланган хатында ачык белдерә. Истәлекләрендә: *«Беренче көннән башлап ук совет вәкиле уполномоченный иптәш Васильев тарафыннан катгый каршылыкны күрә башладым»,* – дип яза. Моннан аңлашылганча, Ленинград мәхәлләсендә 1950 нче елларда башланган ызгышлар дәүләт вәкилләре тарафыннан махсус куертыла, төгәлрәк әйткәндә, аны уполномоченный Васильев оештыра. Бу хәлне мөфти Шакир Хыялетдинов та яшерми. Габделбари Исаевның ачулы хатларына җавап язганда, ул үз мөмкинлегенең бик чикләнгән икәнен күрсәтә: *«Имамлыктан сезне төшереп ташлау минем хакым түгелдер. Царь-хөкүмәт заманы түгел, бәлки демократия әсасенә корылган Совет*

[1] Тәбрикнамә хатын www.beznenmiras.ru сайтыннан укый аласыз.

дәүләтендә яшибез. Бу берәү халык кулында, бездә түгел, Габделбари әфәнде». Халык теләкләрен, гадәттә, дәүләт оешмалары яхшы беләә.

Васильев мәхәллә эчендә низагларны нигә оештырган? Ни өчен Габделбари Исаевтан котылырга тырышкан соң? Безнеңчә, бу сорауларга җавап бик гади. Үзенең булдыклылыгын күрсәткән Габделбари хәзрәт, шәһәр мөселманнарын тиз арада берләштереп, мәхәлләдә мәшһүрлек казана һәм һәр эштә дә үзен мөстәкыйль тота. Нәтиҗә озак көттерми: 1967 нче елда Габделбари Исаев Ленинград мәчетенең имамы вазифасыннан азат ителә.

Габделбари Исаев «ыстахановец». 1938 ел



Габделбари Исаев әтисе белән. Фото фронттан кайткач төшерелгән

***

Габделбари хәзрәт үз гомерендә күп хезмәтләр язарга өлгерә. Аларның шактые Коръән белән бәйле. Без, хәзрәт эшчәнлегенең бу юнәлешен тирәнтен аңлар өчен, тарихи контекстка күз салдык.

Диннең беренчел чыганаклары – Коръән белән хәдискә турыдан-туры мөрәҗәгать итү совет дәверендә прогрессив риториканы үз иткән чорга туры килә. Дин белгечләре Коръәнне никадәр совет чынбарлыгына якынлаштырып тәрҗемә итәргә омтылсалар да, дәүләт түрәләре, катгый чикләр куеп, хәтта советлаштырылган ислам әдәбиятын да күпләп нәшер итүгә юл куймый. Совет-

Уфа мөселманнары

лар Союзында рәсми ислам дискурсының яшәвенә өмет, дингә каршы пропагандага очрап, сүнә. Бу инкыйлабка кадәр белем алган соңгы буын дин әһелләрендә тулы өметсезлек тудыра. Алар торгынлык чорында, ахырзаман якынлашты, дигән фикер белән бакый дөньяга китә бара. Фәкать берничә ел үткәннән соң гына, ил буенча яңадан мәчетләр ачыла башлый...

Совет чорында ислам тәгълиматы репрессияләр, рәхимсез атеистик сәясәт аркасында яшәүдән туктый, дигән фикерне фәнни әдәбиятта еш очратырга була. Дөрестән дә, бу чордагы ислам мәдәниятенең фаҗигале югалтуларын инкяр итү дөрес булмас иде. Минем фикеремчә, совет заманында дини тәгълимат традицияләре бөтенләй юкка чыкмый, еш кына алар башка бер форма ала. Мәсәлән, мин җомга вәгазьләрен, дини мәсьәләләргә ачыклык керткән шәхси хатлар кебек ислам әдәбияты жанрларының үсүен совет илендәге вазгыять белән турыдан-туры бәйлим. Гомумән, аларның кайберләре инкыйлабка кадәрге юнәлешне дәвам итә.

Коръәнне ундүрт яшендә тулысынча ятлап бетергән Габделбари Исаев, остазларының үрнәгендә, бар гомерен ислам гыйлеменә багышлый. Шулай итеп, Габделбари хәзрәттә, Коръәнне югары дәрәҗәдә кайгырту белән бергә, җәдитчеләргә хас булган пуританлык берләшә. Г.Исаев, Уфа, Ленинградта яшәгән чорда совет җәмгыяте эченә шактый уңышлы кереп, чын совет кешесе кыяфәтен ала: авыр кул эшеннән дә баш тартмый, күкрәге дә сугыш медальләре белән тулы... Әмма, шул ук вакытта, безнең фикеребезчә, аның самими ихласлыгы, Советлар Союзында шәригать буенча яши алу мөмкинлегенә инануы рәхимсез чынбарлык белән каршылыкка керә. Бу чынбарлыкта, Коръәнне аңлатутәфсирли белүдән бигрәк, «большевикларча сөйли белү» кыйммәткә ия, ягъни торгынлык чорында, җәмгыяви төрлелек шартларында, совет тормышының иң ихлас кешеләре дә кичә алмаслык кысалар һәм чикләр була.

Г.Исаевка үз гомерендә ислам оешма-институтларын ике тапкыр калдырырга туры килә. Беренче тапкыр ул, әйткәнемчә, имам буларак, Ленинград

Габделбари хәзрәт Уфадагы икенче мәчеттә гает намазын алып бара

мәчетен яхшы хәлгә китереп ремонтлап чыккач, 1967 елда үз вазифасыннан китәргә мәҗбүр була. Сәбәбе – җирле («уполномоченный» юллаган) провокаторлар белән низаглашуы. Габделбари хәзрәт 1975 елда үз карьерасының чәчәк аткан чорын Уфада, мөфти урынында башлап җибәрә. Анда ул, атеистик пропагандага колак салмыйча, мәгърифәт эшен җәелдереп, дини әсәрләр, җомга вәгазьләрен нәшер итәргә ниятли.

Г.Исаевның совет тормышын идеаллаштыру дәрәҗәсе Ленинград кешесе Хәнифә Җамалиева белән язышкан низаглы хатларында ачык күренә. Х.Җамалиева аңа, дәүләт милкен талаучы, әхлаксыз кеше, дип яла яга. Ханымның максаты хәзрәтне хур итү булса кирәк: хатның икенче нөсхәсен «махсус оешмалар»га да җибәрә. Мөфти җавабы табигый: административ чаралар куллану урынына, ул Коръән һәм хәдисләрдән өзекләр китереп, күп битле хат юллый. Г.Исаев, бар гаепне кире кагып, менә болай яза: *«Хәнифә, әлбәттә, мин сезне белмим. Сезнең белән аралашкан кеше түгел. Шулай ук безнең хәлебездән бер тиенлек кенә хәбәрегез дә юк, ләкин сезнең ахмаклыгыгызга исем китә. Һәм, вакытым булмаса да, ошбу язуны сезгә язуны зур бурычларымнан саныйм, чөнки «мин динле» дип юлдан чыккан кешеләрне, мөфти булу мөнәсәбәте белән, юлга төшерү бөек һәм тиешле бурычлардан. Аллаһ Коръән-Кәримдә һәрбер адашкан кешене юлга төшерү һәр мөэминнең бурычы итеп куйган, чөнки әгәр дә мин сезгә аңлатмасам, моның өчен мин Аллаһ хозурында җавап бирәчәкмен»*.

Совет җәмгыятендә низагларны чишүгә мондый караш, мөгаен, уңышка юлыга алмыйдыр. Шунлыктан, нәтиҗәсе дә билгеле. Г.Исаев, вазифасын калдырып китәр алдыннан, махсус тикшерү оешмаларына мөрәҗәгать итәргә карар кыла. Бастырып чыгару үтенече белән үзенең төп хезмәтләрен, Коръән, хәдис тәрҗемәләрен, вәгазьләр җыентыгын җибәрә. Мөфтинең мондый активлыгы хөкүмәткә хуш килми: 1980 елда Г.Исаев Диния нәзарәтеннән китәргә мәҗбүр була.

Габделбари Исаевның шәхси архивында гаять күп санда кулъязма мирас саклана. Алар буенча хәзрәтнең иҗади остаханәсе, Коръәнне күпьеллык өйрәнү

тәҗрибәсе турында мәгълүмат алып була. Г.Исаевның язма мирасы Коръән белән бәйле, хәтта дусларына юлланган шәхси хатлары да изге китаптан өзекләр, шуларның тәфсирләре белән тулган. Аның Коръәнне тәрҗемә иткән беренче каралалмалары 1950 нче елларга – Ленинград, йә тагын да иртәрәк – Уфадагы имамлык чорына карый.

Хәзрәтнең архивында Коръән аятьләре язылган карточкалар да шактый. Соңрак, карточкаларны классификацияләп, татар теленә тәрҗемә итү эшен дә башлап җибәрә. Г.Исаев, шуларга нигезләнеп, Коръән, пәйгамбәрләр, христиан, яһүд дине һәм космос турында хезмәт яза. Барлык бу материалларны да ул иң элек җомга вәгазьләрендә халыкка җиткереп, сөйләп карый. Нәтиҗәдә, вәгазь жанры сугыштан соңгы чорда дини фикер матрицасы буларак яши. Имам Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп, русчасын булдыруны да күз уңында тота.

Габделбари хәзрәт татар теленә тәрҗемә иткән Коръәннең бердәнбер нөсхәсе кызы Фәя ханымның шәхси архивында, Дүшәнбе шәһәрендә саклана. Кульъязманың күләме – 1289 бит. Бу китап киң җәмәгатьчелеккә атап тәрҗемә ителгәнгә күрә, аны Габделбари Исаев кирилл хәрефләре белән яза.

Болар белән бергә, Габделбари хәзрәт совет мөселманнарына ислам фәлсәфәсен җиткерергә ниятли, төп хезмәте – «Ислам дине»нең дә берничә вариантын булдыра. Коръәнне Мөхәммәд Габдүһ тәфсиренә таянып тәрҗемә итсә, бу хезмәте исә остазы Зыяэддин Камали хезмәтләренә сылтамалар белән чуарланган. Шулай итеп, әлеге мисалга таянып, Брежнев «торгынлыгы»ндагы ислам реформациясен күзәтергә була.

Шуны да әйтергә кирәк: Г.Исаев Коръәннең рус теленә тәрҗемә ителгән басмаларына да, миссионер-шәркыятьчеләр тәкъдим иткәненә дә тәнкыйди карашта була. «Ислам дине» хезмәтендә ул болай яза: *«Коръән переводлары да күбесе куркыныч, ислам диненең катгый дошманнарыдыр. Бигрәк куркыныч: хәзерге вакытта балалар рус хәрефе белән русча гына укый беләләр. Шулай булгач, Саблуков тарафыннан русча тәрҗемә ителгән Коръәнне укып, шуннан мәгълүмат алган кеше ничек итеп ислам диненең хакыйкатен дөрес аңлап, дөрес хөкем итә алсын?! Саблуковның переводы баштан азагына кадәр меңнәрчә хата, бозык, ислам диненә пычраклык белән тутырылган. Шулай ук Казимирский переводы да хата, ифтира, истиһзадыр. Инде Крачковский переводы булса, дөрес, ул – гарәп телен чын белүче, ләкин Коръәнне тәрҗемә итү өчен тел белү генә җитмидер. Тел белү берлән генә Аллаһның хөкемен дөрес аңлап булмыйдыр. Коръәнне дөрес аңлау өчен ислам динен тәмам белүче булу ләземдер»*.

Игътибарны җәлеп иткән тагын бер мәсьәлә: «чын», «саф» исламны күрсәтергә теләүче Г.Исаев текстлары совет космонавтикасы терминнарына гаять бай. Бу темага бәйле лексиканың, гарәп язуында язылса да, рус алынмаларыннан гына торуы гаҗәп түгел. Мәсәлән, Габделбари хәзрәт Коръәндәге «күк»не аңлаткан «сәмәвәт» сүзен «планета» дип тәрҗемә итә, аның фикеренчә, «күк»тә бушлыкка, ягъни космоска ишарә бар.

Г.Исаев галәм төзелеше белән бик кызыксына. «Ислам дине» хезмәтенең шактый битендә Коръән һәм хәдисләрдән галәмнең космик төзелешенә кагылышлы дәлилләр дә китерә. Мөгаен, ул аларны совет космонавтикасы уңышларыннан рухланып язадыр. Аның Коръәнне аңлатуга «төгәл фәнни» якын килүенең сәбәбе – классик тәфсирләрдән тыш, Европа галимнәре тәрҗемәләрен дә актив куллануы. Димәк, Габделбари хәзрәт ориенталистикада шәрык халыкларының артта калуы хакындагы әүвәлге фикерне кабатлый: мөселманнар Коръән хикмәтен кулланмый, техник яктан аларның европалылардан артта калуы шуның белән аңлатыла. Коръәнне дөрес аңлау җитә: мөселманнар алдында да, европалылар кебек үк, мәгърифәт, хаклык ишекләре ачылачак.

Бу караш XIX гасыр ахыры – XX

йөз башы Якын Көнчыгыш, Рәсәй империясендәге ислам реформаторлары тәкъдиме белән тулысынча туры килә: Коръәнгә мөрәҗәгать итеп, технологияләрне Европадан үзләштерү. Карашларның бу рәвешле туры килүе бер дә гаҗәп түгел, чөнки Г.Исаев – әлеге интеллектуаль традициянең турыдан-туры варисы. Күңелне боза торган бердәнбер әйбер – Советлар Союзында дингә мөрәҗәгать итү берничек тә киләчәк прогресс белән күзалланмый, ә киресенчә, ислам артталык, борынгылык, дип тәнкыйтьләнә. Габделбари хәзрәт хезмәтләрендә чишелеше булмаган төп каршылык та шул: инкыйлабка кадәрге реформизмнан калган күзаллаулар Брежнев торгынлыгы чорында архаик булып күренә. Г.Исаев ничек кенә тырышса да, ислам белән прогресс төшенчәләре ул чорда капма-каршы мәгънәдә йөри.

Прогрессив, алдынгы карашлар юлыннан ул хатын-кызларның исламдагы роле темасына кагылганда да бара. Әлеге мәсьәләгә «Ислам дине» китабында тулы бер бүлек багышлап, бу юнәлештәге Коръән аятьләрен дә тәкъдим итә. Анда хатын-кыз – җәмгыятьнең тигез хокуклы бер өлеше.

Г.Исаев хезмәтләрендә калдырылган намаз, аларны каза кылу темасы аерым игътибарга лаек. Монда совет җәмгыятенә хас хезмәт культы ачык күренә. Габделбари хәзрәт, Киевтагы хезмәттәше Мөхәммәт-Парса Әхәтовка җавап хаты язганда, эшче һәм эшсез кешеләрнең аермасын төгәл күрсәтә. Эшсезләр, лаеклы ялдагылар ***фаиза-тманәнтум*** хәлендә булганга, намазны үз вакытында кылырга тиеш. Ә эшчеләр исә үзләренә яраган вакытта гына түгел, хәтта кылу ысулын үзгәртеп – басып, хәрәкәттә, уй-фикердә намаз кыла алалар икән. Чөнки намазның максаты – ***тәзкият ән-нәфс*** – йөрәк, күңел сафлыгы. Болай фикер йөртүнең сәбәбе дә билгеле: бер яктан совет чынбарлыгын күз уңында тоту зарурлыгы булса, икенче яктан ритуаль-гыйбадәтсез дә мөселман булып санала алу ихтыяҗы. Габделбари хәзрәт бу бәхәсле карашны да Коръән тәфсире белән исбатлый.

Г.Исаев хезмәтләрендә ислам дискурсының советлаштырылуы дини тәгълимат дәлилләренең катгыйлыгы белән каршылыкка керми. Аның барлык шәрехләүләре дә йә Коръәнгә, йә хәдискә, яисә элекке дин белгечләре хезмәтенә нигезләнә. Моннан тыш, Габделбари хәзрәт кайвакыт совет кануннарына сыя алмый торган катгыйлыкны да күрсәтә: Мөхәммәд-Парса дустының каракка бирелергә тиешле җәзасы турындагы соравына ул Коръәннән кулны кисү турындагы аятьне дәлил итеп җавап бирә. Бу җавап барып җиткәч тә, Киевта, әлбәттә, каракларның кулын кисәргә тотындылар, дигән сүз түгел. Болардан Габделбари хәзрәттә исламны советлаштыруга карата ике төрле караш булганы ачык күренә. Моның нигезендә, һичшиксез, «ислам асылына кайту» өндәмәсе, совет космонавтикасы һәм ислам җәмгыяте реформасына җәдиди карашларның гаҗәеп катнашмасы ята.

***

Ленинград шәһәренә кайтканнан соң, Габделбари Исаевның бөтенләй яшисе килми башлый. Гомер буе ислам дине өчен көрәшкән хәзрәт үз гамәлләренең файдасызлыгын ачык күрә, Совет дәүләтендә шәригать буенча яшәргә ирек бирмәячәкләренә төшенә. Көне-төне язган унлап хезмәтенең берсе генә дә дөнья күрми. 1982 елның 3 августында Габделбари хәзрәтнең 54 ел бергә яшәгән хәләл җефете вафат була. Хатынына багышлап, ул шигырьләр иҗат итә, аларны магнитофон тасмасына да яздырып калдыра. Соңгы шигырьләре исә өметсезлек белән тулы: аның өчен бар дөньяның яме югала. Нәтиҗәдә, Габделбари хәзрәт башыннан кичкән кайгыларга түзми: 1983 елның 13 ноябрендә иртәнге сәгать биштә фани дөньяны калдырып китә. ■

«ИДЕЛ» ГАЗЕТАСЫНА 110 ЕЛ

«Идел» газетасы хезмәткәрләре. Икенче рәт, уртада баш мөхәррир Г.Гомәри. 1910 ел

«ИДЕЛ»ДӘ КАЮМ КУЛАТКЫ МӘКАЛӘЛӘРЕ

*Матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев «Идел» газетасы хакында менә ниләр яза: «1907 нче елның сентябрендә Әстерханда чыга башлады. Бу гәзит үзе турында: «Әдәби, икътисади, сәяси, милли төрекчә гәзитәдер. Хаҗитарханда җомга һәм шимбә көннәрендә чыгадыр. Елга – 4 сум, берәмләп – 5 тиен», – ди. Милли буржуазный гәзитәләрнең берсе, башка гәзит-журналлар белән бик күп репликага кермәсә дә, ике тәкә бер казанга сыймый, дигәндәй, «Борһан тәрәккый» белән бертуктаусыз бәрелешеп тордылар. Әстерханда нәшер ителгән гәзитәләр арасында иң дәвамлысы, тәртипле чыгарылганы һәм күбрәк таралганы шушы гәзит булды. Урта кулда, дүрт битлек булып, атнага 2-3 номер чыкты. Беренче, дүртенче битләре игълан белән тулы булып, татар гәзитәләре арасында, «Бәян әл-хак»тан кала, игъланга бай гәзитләрнең берсе шушы гәзит исәпләнде. Моның нәшриятыннан төрле календарь, справочниклар, әдәби әсәрләр дә чыккалады. Хәрефләре матур гына, техникасы уртача гына булып, басылуы Әстерханда Г.Гомәров вә уртаклары тиҗарәтханә матбагасында. Гәзит 1914 нче ел, 27 нче гыйнварда туктала. Мөхәррире Гомәров, администрациянең карары белән, Әстерханнан сөрелә. Башта җаваплы мөхәррире – Заһидулла Шәрифуллин, нашире – Габдерахман мулла Гомәров. 1911 нче ел, 19 апрельдән башлап мөхәррирлегә дә Гомәров исеменә күчә. Язышучылары – Сәгыйть Рәмиев, К.Кулаткы, Г.Басыйри һәм башкалар».**

*Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: альбом (1905–1925). – Казан: Гажур, 1926.

«Идел» газетасында дөнья, Русия хәбәрләре белән бергә, Хаҗитархан шәһәре, аның тирә-ягында яшәүче төрки халыкларның, азәрбайҗан белән нугайларның һәм, әлбәттә, татарларның милли яшәеше яктыртыла. Мәгариф, уку-укыту, милли бәйрәмнәр, әдәбият, концерт-театрлар, кәсеп-сәүдә эшләре, хәйрия җәмгыятьләре һәм вак бурыч ширкәтләре эшчәнлеге, бакчачылык турында языла, бу өлкәләрдәге кимчелекләр тәнкыйтьләнә, уңышлар исә хуплана. Хәтта татар, мөселман байлары берләшеп, Әстерханда милли банк ачу мәсьәләләре дә тикшерелә.

Игътибарыгызга «Идел» газетасының иң актив авторларыннан берсе булган журналист Каюм Кулаткының ике мәкаләсен (1913. – №584. – 3 сент.; 1913. – №600. – 5 нояб.) тәкъдим итәбез.

ӘСТЕРХАН МӨСЕЛМАННАРЫНДА СӘҮДӘГӘРЛЕК

Хәзерге гасырда милләт вә кавемнәрнең алга китүләре, милләт вә кавемнәрнең шан вә шәрәфләрен саклый алулары ялгыз байлык вә мал аркасында гына мөмкиндер. Малсыз фәкыйрь вә икътисади җәһәттән җиңелгән милләт исә үзенең барлыгын, мәмләкәт вә падишаһлыклар үзләренең бәйсезлекләрен саклый алмыйлар. Инсан тормышы су илә һавага никадәр мохтаҗ булса, милләт вә кавемнәрнең алга китүләре, хокук миллия вә хокук диния вә хокук сәясияләре саклану өчен дә байлык вә акчага шулкадәр ихтыяҗ бардыр. Байлык вә акча хәзерге гасырда дөньяның иманы саналадыр. Имансыз адәмнәр ахирәттә изгелек күрмәдекләре кеби, фәкыйрь вә икътисади бөлгенлеккә дучар булган милләтләр дә дөньяда һичбер рәхәт күрә алмыйлар. Милләт вә кавемнәрне, хөкүмәт вә мәмләкәтләрне алга җибәргән нәрсә байлык илә акча булган шикелле, аларны аяктан еккан, хурлык вә түбәнлеккә төшергән нәрсә дә – фәкыйрьлек вә икътисади бөлгенлектер. Болар һәркемгә мәгълүм булган хакыйкатьләрдер. Әхвәл галәмнән вә тарихтан хәбәрдар адәмнәр, байлык илә акчаның милләтләрнең алга китүләрендә, мәмләкәтләрнең көч вә куәт хасил итүләрендә никадәр зур роль уйнадыкларын белеп вә күреп торалар. Шулай булгач, бу хакта озын сүз сөйләмәкне дә артык, дип беләбез. Һәм Әстерхан мөселманнарының хәзерге сәүдәгәрлекләре хакында гына бер-ике сүз язып китәбез.

Әстерхан мөселманнары сәүдәгәрлек бабында Волга буендагы башка шәһәрләрдә булган мөселманнарга нисбәттә күп артта вә киредән иделәр. Әстерхан мөселманнарының сәүдәгәрлеге тире-яры, иске-москы кием-салым вә бераз нугай бакчаларында җитешкән яшелчәләр сатудан үтми иде. Яһүди вә әрмәннәрне баеткан балык сәүдәсе, ширкәт ясап яки хосусый адәмнәр тарафыннан вак пароход вә баркаслар йөртү Әстерхан мөселманнарына насыйп түгел иде. Кием-салым магазиннары, мануфактур вә аптекарский магазиннар, сәгать, келәм вә палас магазиннары – һәммәсе яһүди вә әрмәннәр кулында иде. Өй әсбаплары вә мебель магазиннары да читләр кулында булып килде. Кыскасы, бөтен сәүдә читләр кулында булып, без ялгыз читләргә акча ташуны гына белә идек. Хәтта бүрек, кәләпүш вә читек-кәвеш сәүдәсе күбрәк читләр кулында иде. Ләкин заманнар үтте. Халыкның куәте аз гына булса да ачылды. Һәрбер кимчелегебезне күзебезгә картина шикелле күрсәтеп килгән гәзитә вә журналларыбыз, безнең болай читләрне баетып, үзебезне фәкыйрьләндереп тору ярамаганлыгын бер түгел, йөз түгел, мең, бәлки миллион мәртәбә яздылар. Укыдык вә укыганнарыбызның йөздән берсе генә булса да колакларыбызга кереп калды.

Менә шулай итеп, сәүдәгәрлектә энә буе кадәр генә булса да алга атлый башладык. Арабыздан Шәйхетдин әфәнде дигән берәү чыгып, «Исламия» вә «Тукаев» исемендә ике кечкенә пароход

йөртә башлады. Нугай бакчаларында җитешкән җимешләребез, «Иванов», «Максимов» дигән пароходлар өстендә йөрүдән тукталып, «Исламия», «Тукаев» исемле пароходлар өстендә йөри башладылар. Бу – безнең өчен бик зур шатлык. Бу безнең сәүдәгәрлектә аз гына булса да алга китә башлаганлыгыбызны күрсәтәдер. Әле киләсе навигация вакытында Шәйхетдин әфәнде, Кызан, Каргалык вә Майлы Күл шикелле мөселман авылларына йөри торган янә бер-ике пароход арендага алу ниятендә йөри, дип ишетәбез. Алла «Акмулла» вә «Мәрҗани» исемле пароходларны да күрергә насыйп итсен. Фәкать мондый зур вә файдалы эшләр ширкәт берлә эшләнсә, тагын да файдалырак булыр иде төсле күренә.

Безнең сәүдәгәрлектә аз гына булса да алга киткәнлегебезне күрсәтү өчен, фельдшер Исмәгыйль Таһирзадә вә зыялы Һади Кәримовлар тарафыннан ачылган ике аптекарский магазинны да язарга туры киләдер. Чөнки Әстерхан мөселманнарыннан бу көнгә кадәр аптекарский магазин ачучы түгел, ачарга уйлап кына караган кеше дә булмагандыр. Бары исемнәре әйтелгән ике әфәнде исә, халыкның ихтыяҗын аңлап, икесе бердән ике аптекарский магазин ачып җибәрделәр. Бу ике әфәнденең медицина вә аптека гыйлемен белүләрен дә игътибарга алсак, мөселманнар өчен әллә никадәр күп матди вә мәгънәви файда китерәчәк хәерле эшнең мөселманнар кулына керүенә һәркем куанырлыктыр. Алла бу ике әфәнденең эшләренә уңыш биреп, үзләренә дә озын гомер бирсен, дибез.

Мөселманнардан ике-өч кеше береген, мануфактура сәүдәсе ачучылар да булды. Кондитерский вә пекарнялар да мөселманнар тарафыннан ачылып торадыр. Димәк, Әстерхан мөселманнарында сәүдәгәрлек әүвәлгегә караганда шактый тәрәккый иткәнлеге күренәдер. Әмма, шулай булса да, сәүдәгәрлегебез башка милләтләрнең вә күршеләребезнең сәүдәгәрлегенә нисбәттә әле бик артта. Шулай булгач, моңарга разый булмыйча, ширкәтләр ясап, мөселманнар өчен файдалы булган һәммә сәүдәләрне кулыбызга алырга тырышыйк.

ТАТАРЧА ТЕАТР ҺӘМ МУЗЫКА КИЧӘСЕ

Ошбу үткән Корбан бәйрәменең икенче көнендә, 27 нче октябрьдә Хаҗитарханыбызның «Зимний» театрында татарча театр, җыр һәм музыка кичәсе булган иде. Театр бүлемендә сәхнәгә берәр пәрдәлек «Игълан бәласе»[1] илә азәрбайҗан шивәсендә «Дурсунәли вә баллы бады»[2] исемле көлке әсәрләр куелган иде. Театр сөюче артистларыбыз рольләрен гүзәл башкардылар. Аеруча «Игълан бәласе»ндәге Сәлимҗан Чулкаев ролен уйнаган Саратовский әфәнде илә «Баллы бады»дагы Дурсунәли ролен уйнаган Мөхәррәмзадә вә Җәгъфәр ролен алган Нугаев әфәнделәр рольләрен аеруча оста башкардылар. Саратовский әфәнде, Хаҗитархан театр сөючеләре арасында сәхнәдә яңа гына күренгән кеше булып, җирле артистларыбыз тормышы эчендә ачык күренерлек мөһим зур бер көчтер. Ул ролендә чакта үзен тәмам онытып, нинди каһарманны уйнаса – шул каһарманның үзе булып китеп уйный икән. Бу сыйфат артист өчен бик кирәк сыйфат һәм шул сыйфатлы артистны карау тамашачы, җәмәгать өчен дә күңелле вә тәэсирле буладыр.

Шуның өчен, Саратовский әфәндене шәһәребезнең театр сөючеләребез арасында күреп, самими күңелебездән алкышлыйбыз. Һәм аны тагы яхшырак пьесаларда, үз тормышыбызның каһарманнары ролендә күрергә телибез. Мөхәррәмзадә, Нугаев, Гыйсметдин, Рузә ханымнарга да, өсләренә алган хезмәтләрен – рольләрен гүзәл башкарганнары өчен, җәмәгать исеменнән рәхмәт укыйбыз.

Кичәнең мөһим һәм халык өчен яңа

[1] «Кияү эзләү, яхуд Игълан бәласе» – русчадан тәрҗемә ителгән 1 пәрдәлек көлке.
[2] «Дурсунәли вә баллы бады» – С.Ганизадәнең 1 пәрдәлек комедия-водевиле.

һәм күңелле өлеше – музыка, шигырь вә җыр бүлемнәре булды. Бу бүлемдә музыка сөюче яшьләребез тарафыннан мандолина вә скрипка илә татарның борынгы вә яңа көйләре уйналды. Боларны тыңлаудан халык гаять мәмнүн калып, яшьләребезне бертуктамый алкышлап тордылар. Хөснетдин әфәнде Кәримов яшь балалардан хор тәшкил итеп, алар «Аппагым», «Алмагач» көйләрен гаять матур итеп җырлап күргәзделәр. Хөснетдин әфәнде Кәримовка, матур көйләребезне матур итеп башкарганы өчен, халкыбыз күп рәхмәтләр укып, бик күп алкышладылар һәм Хөснетдин әфәнде бу рәхмәт вә алкышларны бик шатланып алды. Аның җыр вә көйләренең матурлыкларын күргәзү юлындагы бу хидмәтләренә дәвам телибез.

Тагын матур тавышлы вә татар һәм хаҗитарханлы нугай көйләрен матур җырлый белгән, затына ихтирам вә мәхәббәтебезне казанган кешебез Нугаев әфәнде булды. Нугаев әфәнде шагыйребез Дәрдемәнднең «Бүзләрем маналмадым» дигән матур шигырен бигрәк тә матур итеп, гаҗәеп бер матур көй белән җырлады. Тыңлап туя алмадык. Тагын ишетәсебез, тагы бик күп тыңлыйсыбыз килә. Афәрин, Нугаев!

Кичәнең программасындагы әдәбият номерларыннан халыкның дикъкатен җәлеп иткәне Сәгыйть Рәмиев шигырьләреннән «Таң вакыты» дигән шигырен уку булды. Моны югарыда исеме әйтелгән Саратовский әфәнде укыды һәм бу шигырь электрик яктылыгы илә таң ату, кояш чыгу манзараларын күргәзелеп укылды. Укучы әфәнде борынгы татар киемнәрен киенгән ак сакаллы бер карт кыяфәтендә иде. Шигырь вә манзара бик матур булып чыкты. Тамашачыларның калебләрендә тирән бер хис вә озак бер уй калдырды. «Таң вакыты»ның тәкърар укылуын үтенделәр.

Җыр вә уку бүлемен язганда Кәрим әфәнде Яналиевның җиде яшьлек кенә кызының – Зөһрә туташның алты-җиде йөздән артык җәмәгать алдында сәхнәгә

«Идел» газетасының ТР Милли китапханәсендә саклана торган 1913 елгы 8 ноябрь саны

чыгып, Тукаев әфәндәнең «Бәйрәм бүген» шигыре илә «Эш» исемле шигырен укуын язмый китү ярамыйдыр. Бу кечкенә туташның шулкадәр халык алдында бер дә ялгышмый, аптырамый шигырьнең вә зан, вә матурлыкларын китереп укып чыга алуы тамашачыларны гаҗәпләндерде һәм халыкны гадәттән тыш шатландырып, кечкенә генә артык бер күңеллелек бирде. Кичә бик күңелле вә бик уңышлы бер кичә булып чыкты. Җәмәгать гаять мәмнүн вә разый калды. Шимас[3], Сәгыйть Рәмиев, Хөснетдин Кәримов әфәнделәргә, җәмәгать эчендә бирәү, өстенә мәдхия шигырьләре язылган ленталар тәкъдим вә ихтирам белдереп һәм мәхәббәт итте. Димәк, Хаҗитархан мөселманнары, үзләренең милли театр вә күңел ачар кичәләрен ясаучы кешеләрне тәкъдир итә башладылар. Без дә моның кебек күңелле вә бик файдалы кичәләрне ясаучы әфәнделәргә җәмәгать исеменнән рәхмәт укыйбыз.

*Текстны **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[3] Шимас – Әстерхан мөселманнарының хәйрия җәмгыяте рәисе Фатих Шимас.

Безнең мирас №5 май 2017

Ачык һавадагы «Итил» музей комплексы

ИТИЛ, САКСИН, ХАҖИТАРХАН, ӘСТЕРХАН...

Фәнзилә Җәүһәрова

Бүген Татарстанда һәм Россиядәге татарлар яшәгән төбәкләрдә барган милли хәрәкәт-үзгәрешләр күп яктан милләтнең 1917 елга кадәр булган хәл-халәтен хәтерләтә. Территориаль һәм милли-мәдәни автономия, халыкның үзбилгеләнү хокукы, милли үзаң формалаштыру һәм башка кайбер мәсьәләләр татар җәмгыятендә кызу бәхәсләр туууга сәбәп булды. Таралып яшәгән татарлар арасында үз тарихы-тамырлары белән кызыксыну, мәдәни үзенчәлекләрне эзләү, милләтен-нәселен юллау күзәтелә.

Әстерхан ягы – нәкъ менә шундый борын-борыннан татарлар яшәгән, үзендә гомумтөрки традицияләрне саклап, XIX йөз ахыры – XX йөз башына гомумтатар мәдәни, әдәби процессларына кушыла алган төбәкләрнең берсе.

Үзенчәлекле тарихи-географик төбәк буларак, Әстерхан элек-электән, сәяхәтчеләр игътибарын да җәлеп итеп, тарихчыларны да кызыксындырып килгән. Флоренция сәүдәгәре Франческо Пеголотти үзенең «Сәүдә эше» (1340 еллар тирәсе) исемле китабында «Дженторхан»ны Түбән Иделдәге Урта диңгез белән көнчыгышны тоташтыручы бөек кәрван юлына урнашкан сәүдә алып бару шәһәрләре арасында иң мөһиме дип атый. Хаҗитарханның, Күфә, Судак, Азак (Тана) шәһәрләре кебек, диңгез артында алып барылган сәүдә эшләрендә тоташтыру ноктасы вазифасын башкаруы билгеле. Истанбул, Италия сәүдәгәрләренең чөгә балыгын, урыс кнәзләренең тоз сатып алу үзәге дә Хаҗитархан була. Монда Дәһли солтанлыгына (Һиндстанга) атлар белән сату итү барганлыгы мәгълүм.

Әстерхан җиренең төрки-татар та-

мырлары бик ерактан килә. Археологлар әйтүенчә, б.э. кадәр VII гасырда биредә скифлар, аннары сарматлар – фарсы телле кабиләләр яшәгән. Безнең эраның IV-VII гасырларында фарсы һәм төрки телле күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләрнең берләшүе нәтиҗәсендә, яңа этник берлек – үзләрен һуннар дип атаучылар төркеме барлыкка килә. Галимнәр аларның төрки телле, язулы кабиләләр булуын билгели.

VII гасырда Хәзәр каһанлыгы формалашып, аның башкаласы – легендар Итил сәүдә һәм мәдәни үзәккә әйләнә. Итил Әстерхан тирәсендә булган, дип фараз ителә .

XIII-XIV гасырларда бу җирләрдә Алтын Урда дәүләте оеша, Әстерханнан ерак түгел генә аның башкаласы – Сарай-Бату, 1333 елда Ибн-Батута язып калдырганча, «искиткеч зур, иң гүзәл шәһәрнең берсе» пәйда була.

Урда хакимнәре, Сарай-Бату, Сарай-Бәркә кебек шәһәрләргә шул заман әдипләрен, шагыйрьләрен, галимнәрен чакырып, гыйльми-мәдәни берлек – Алтын Урда культурасы тудыруга этәргеч ясыйлар. Монда исә татарлар да катнаша. Мәсәлән, Мәхмүд Болгари 1358 елны Сарай-Бәркәдә болгар-татар әдәбиятының күренекле ядкяре «Нәһҗел-фәрадис», Котб «Хөсрәү вә Ширин», Хисам Кятиб «Җөмҗөмә солтан» әсәрләрен яза. Алтын Урда заманында «Кыйссаи Авык», «Бәдәвам», «Кисекбаш китабы», «Нәсихәтес-салихин» кебек китаплар иҗат ителә. Төбәк кенә түгел, Әстерхан шәһәре үзе дә иҗатчылар, галимнәр өчен хаҗ юлында туктала торган очрашу-күрешү урыны вазифасын башкара. Мәсәлән, монда 1414 елны Фәрганәдән чыккан, Болгарда күп вакытлар яшәгән галим һәм шагыйрь Госман бине Мәлик әл-Мәргыйниянинең үлеп калу факты билгеле.

Алтын Урда ханнарына буйсыну төбәкне сугыш-афәтләрдән саклап кала алмый: 1395 елны Әстерхан яндырыла, ләкин XV гасырның 60 нчы елларыннан яңадан тергезелә һәм Әстерхан ханлыгының үзәгенә әверелә. Ләкин бу ханлык та озак яшәми: 1554 елны А.Вяземский һәм М.Головин җитәкләгән рус армиясе тарафыннан яулап алына. 1556 елны хан Дәрбиш-Гали баш күтәреп караса да, бу омтылыш максатына ирешми.

Мәшһүр тарихчы Г.Гобәйдуллин, Әстерханның Алтын Урдадагы иң зур шәһәрләрдән берсе булуын ассызыклап: *«Хәзерге Сарытау белән Әстерхан арасында бик күп шәһәрләр салынды. Бату хан заманасыннан алып Мәңгү Тимергә кадәр заманда акча сугыла торган пайтәхет Болгар хисапланса да, Бату хан заманасында ук Иделнең сул ягында Хәзәр диңгезеннән ике көнлек юлда (Әстерханнан 100-120 чакрым югары) Сарай шәһәре салынды. Моннан башка, Үзбәк хан заманында Җаек елгасының диңгезгә коя торган урынында Сарайчык, Иделнең Хәзәр диңгезенә агып төшә торган әүвәлге Итил шәһәре урынында XVI гасырларда Әстерхан заһир булды.*

Алтын Урда бүленә башлаганда, бу шәһәрне һәм аның әтрафын мәркәз итеп, Җүчи нәселеннән булган бер хан баласы бу шәһәрдә мөстәкыйль ханлык ясады. Дәүләтнең төп әһалисе татарлардан гыйбарәт булса да, пайтәхет булып Әстерхан шәһәрендә чит халыклардан әрмәннәр, иранлылар, һиндиләр дә торалар», – дип язып калдырган.

Әстерхан ханлыгы рус дәүләтенә буйсындырылганнан соң, яңа хакимият Әстерханның халыкара сәүдә эшләрен шактый киметә, ләкин Рәсәйнең эчке базарында төбәк балыгын, тозын, терлеген сату зур урын били башлый. XVII гасыр ахырына Әстерхан шәһәре Рәсәйнең халыкара сәүдә үзәгенә әверелә . Нәтиҗәдә, Әстерхан төбәге төрле диннәр – ислам, православие, буддизм, төрле телләр һәм мәдәниятләр кисешкән, бәрелешкән, бәйләнешкә кергән үзенчәлекле урынга әйләнә. ■

Безнең мирас №5 май 2017

Финляндиядә татар әсирләре

(Кышкы һәм Дәвам сугышлары вакытында финнәргә тоткынлыкка эләккән татарлар язмышы)

Чыңгыз Сафиулла

Качкын урыс үз телендә һәм тәрҗемәче, Финляндия татары Садри Арифулла татар телендә репродуктор аша хәбәр тапшыра. 1941 ел

ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ ПРОПАГАНДА

Сугыш вакытында, табигый, ике тарафтан да пропаганда булган. Бу эш дошман ягына өч-дүрт рәвештә башкарылган:

1. Радиотапшырулар ярдәмендә. Тапшырулар әүвәл тасмага язылып, аларны берничә мәртәбә тыңларга мөмкин булган. Мондый программаларны тыңлау, әлбәттә, тыелган. Совет кануннары буенча, тыңлап тотылганнарга каты җәза бирелгән. Бер кешенең яшерен рәвештә тыңлавы турында күрше-күләннең, хәтта гаилә әгъзаларының да әләкләү очраклары теркәлгән. Чит илләрдән җибәрелгән радиотапшыруларны тыңлар өчен кыска яки озын дулкынлы радиоалгычлар табу авыр булган. Ә Совет илендә киң таралган урта дулкынлыларда чит ил тапшырулары бик начар ишетелгән. Каршы якта милләтләр күп булганга, тапшырулар да төрле телләрдә әзерләнгән.

2. Репродуктор аша фронтта турыдан-туры тапшырулар. Дөрес, репродуктор ярдәмендә тавышны әллә ни ерак җиткереп булмаган. Шуның өстенә, дошман як радиотапшыручының урынын тәгаенләгәч, әлеге эш гаять куркынычка әйләнгән.

3. Очкычлардан меңәрләп провокацион язмалар, листовкалар төшерү. Кышкы һәм Дәвам сугышлары вакытын-

Ахыры. Башы 4 нче санда.

да дошманның әхлагын зәгыйфьләндерү өчен, төрле ялган, әрәм теллелек һәм әдәпсез кыланулар да мәйданга чыккан. Фронтның икенче ягындагы төрки-татарларның шактые «күктән яуган» ялган мәгълүматка ышанган.

Мәгълүмат тарату турында көлкеле сюжетлар да бар. Әдип Вайнё Линнаның «Исемсез солдат» әсәрендә болай язылган: *«Фронтта, фин солдаты урыс солдаты белән сөйләшкәндә, урыс каты тавыш белән: «Безнең якка килегез, без сезгә икмәк тәкъдим итәбез», – дип эндәшкән. Шунда фин солдаты җавап кайтарган: «Сез безнең якка килегез. Без икмәк өстенә май да бирәбез», – дигән».*

4. Финнәрнең пропагандасы граммофон тәлинкәләреннән дә сөйләнгән. Алар Финляндия радиостудиясендә әзерләнгән. Максаты – Кызыл Армиядә хезмәт итүче төрле милләт гаскәриләренә вәсвәсә салу.

Игътибарыгызга очкычлар ярдәмендә «яудырылган» листовкаларның берсен хәзерге татар әдәби теленә күчереп тәкъдим итәбез. Кавказлыларга, чиркәс халкына адресланган өндәмәнең тексты урыс һәм гарәп хәрефләре белән иске татар телендә язылган.

«Бөек Шамилнең угыллары!

Кавказия таулылары!

Урыслар сезне меңнәрчә еллардан бирле килгән хөрриятегездән мәхрүм иттеләр. Милли барлыгыгызны, дини мөкатдәсегезне, Коръәнне аяклары астында таптадылар. Йортыгызны, авылларыгызны хәрабә хәленә китерделәр. Хатын-кызларыгызның намусын алдылар.

Инде безне, хөррият сөйгән финнәрне дә, кол итмәк өчен азатлыгыбызны, бөтен барлыкларыбызны җимерер өчен тырышалар. Сезне, сезгә дус булган фин халкына каршы сугышырга мәҗбүр итәләр.

Чиркәс гаскәриләре!

Сез моны телисезме? Кәфер комиссарлар сезгә ялган пропаганда ясыйлар: гүя без Русиягә һөҗүм иткәнбез. Бу – соңсыз большевик ялганнарының берседер. Бу чынлап ялгандыр. Без Русиядән һичбер шәй теләмибез. Без, финнәр, үз туфрагыбызда хөр вә тыныч яшәргә телибез. Сез дә йортыгызда, җәннәт кеби Кавказиягездә ирекле бөркетләр кеби хөр яшәргә телисез.

Безнең белән сугышудан сезгә вә сезнең Кавказиягезгә һичбер файда юктыр. Кызыл Мәскәү сезнең коллыгыгыз, сезнең үлемегез, сезнең җәсәдләрегез, сөякләрегез аркасында яшәмәктәдер. Ул бөтен дөньяны йотырга тели. Шайтани тәдбирләр илә дөньяга иблис хакимиятен корырга омтыла.

Чиркәс гаскәриләре! Кавказның курыкмас бөркетләре!

Иблис ялчылары – комиссарларны үтерегез. Гүзәл Кавказиягездә, авылларыгызда сезне күрергә интизар иткән кара сачле хатыннарыгыз, гөнаһсыз балаларыгыз янына кайтыгыз. Яки сезнең өчен сугышып үлүдән башкасы юктыр.

Бөек Шамилнең уллары!

Кәфер комиссарлардан котылу форсаты килде. Тауларда булганда сезгә фаҗигаләр китергән урыс комиссарларының күкрәгенә үткен хөррият хәнҗәрен кадагыз. Без, финнәр – сезнең дустыгыз. Сезгә ярдәмгә әзер».

МӨСЕЛМАН ҺӘМ БАШКА ДИНДӘГЕ ӘСИРЛӘРНЕ РУХЛАНДЫРУ

Милли архивтагы язмаларга караганда, Финляндия җәмәгате исламиянең вәкилләренә лагерьларга зиярәт кылырга, әсирләр белән намаз укырга рөхсәт ителгән. Бу рухи мәсьәлә, Эчке гаскәр идарәсе тарафыннан игътибарга алынып, махсус рәсмиләштерелгән.

Документта Финляндия мөселман мәхәлләсе имамы Вәлиәхмәт Хәким һәм сәүдәгәр Осман Алига Кеми, Валкеакоски, Настола, Коккола, Каннустагы лагерь һәм хастаханәләргә барырга вәкаләт бирелгән. Аңлашыла ки, анда мөселманнар булуы теркәлгән.

Әдип Рони Смолярның бер әсәрендә

Финляндия яһүде Абрахам Стиллерның тормышы турында языла. Стиллерга, әсирләр лагерьларына барып, милләттәшләренә ярдәм итәргә рөхсәт бирелгән. Автор китабында Стиллерның Финляндия җәмгате исламиясенә барып, Коръәннәр алганлыгы турында да әйтә. Смоляр болай ди: *«Стиллер хәйрия эшендә аеруча лаеклы кешеләрне сайлаган. Мохтаҗ булганнарның һәрберсенә ярдәм иткән. Ул Хельсинки мөселман мәхәлләсеннән Коръәннәр алып, татар әсирләренә илтеп биргән. Әсирләр аңа, бу ярдәме өчен, лагерьның сары кәгазенә язып, урыс һәм татар телләрендә рәхмәт юллаган»*.

ХӘСӘН ХӘМИДУЛЛА КОРЪӘННӘРЕ

Финляндия татары Х.Хәмидулла үз хисабына 6000 данә Коръән бастырып, шундагы татарларга һәм Германиядә тотқынлыкта булган мөселман әсирләренә тараткан.

Күпләр Хәсән Хәмидулланы сәүдәгәр буларак белә иде. Ул, озак еллар Кемидә яшәгәннән соң, 1940 нчы елларда Хельсинкига күченде. Сәүдә эшеннән башка, мөхәррир, татар тарихын туплаучы һәм журналист булды. Финляндия мөселман мәхәлләсендә вакытлыча ярдәмче имам вазифасын да башкарды. Х.Хәмидулланың унлап китабы дөнья күрде. Китапларын Хельсинкидагы үз басмаханәсендә чыгарды. Хезмәтләренең күбесе гарәп хәрефләре белән татар телендә басылган.

ӘСИРЛӘРНЕ СОВЕТ ИЛЕНӘ КАЙТАРУ ТАЛӘП ИТЕЛӘ

Вакытлы солых килешүе бер яктан Совет иле, Бөекбритания, Төньяк Ирландиянең берләшкән патшалыгы, икенче яктан Финляндия хөкүмәте арасында 1944 нче елның сентябрендә имзаланды.

Килешүнең 10 нчы маддәсендә Совет иленә кайтарылачак кешеләр турында: *«Финляндия хөкүмәте, вакыт уздырмыйча, Совет иленең югары хәрби җитәкчелегенә кулында булган барлык тоткыннарны, Финляндиягә көчләп китерелгән, иректән мәхрүм ителгән гражданнарны үз илләренә кайтаруны өстенә ала»*, – дип язылган.

Шушы документ имзаланган мизгелдән, Финляндия хөкүмәте Совет иле әсирләренең ашау-эчү, киемсалым, исәнлек-саулыгын кайгыртып, үз илләренә кайту өчен чыгымнарны да өстенә ала.

Совет иленнән әсир ителгән сугыш тоткыннары 1944 нче елның октябрь-ноябрендә һәм 1945 нче елның гыйнварында туган илләренә кире кайтарыла. Җамбакты татарларының да күбесе 1945 нче елның урталарында Совет иленә тапшырыла.

Кире кайтарылган әсирләр 5-25 елга тотык ителгән булган. Боларның бер өлеше фин гаскәренә кергән һәм аларны Выборгта ук җәзалап үтергәннәр.

РӘХИЛӘ АБДУЛЛИНА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

Миңа финнарга әсир төшкән татарлар һәм аларның балалары белән Финляндиядә, Казан һәм Болгар шәһәрләрендә очрашу насыйп булды. 80 яшенә җиткән Рәхилә Абдуллина белән исә телефон аша әңгәмә кордык.

Рәхилә ханым әңгәмәнең башында ук Тааветтига зиярәт итәргә теләвен, татар әсирләренә истәлек буларак, һәйкәл кую чарасында да катнашырга ниятләвен белдерде.

***

– Мин Финляндиядә булган татар әсирләре турында китап язам. Сез Җамбакты исемле авылда яшәгәнсез. Хәтерлисезме, ничәнче елда һәм ни сәбәп белән сезне аннан күчерделәр?

– Беренче Фин сугышы беткәч, безне көзен 1940 нчы елны Карелиягә күчерделәр, ул елны Финляндиянең бер өлеше безнең кулга *(Совет иленә)* керде. Андагы җирләрне багарга кешеләр кирәк

Казан татары әсире һәм аның янында тәрҗемәче, Финляндия татары Хәйдәр Асис. Әңгәмә иркен генә татар телендә бара. 1941 ел

булды. Татарстаннан анда 19 гаиләне җибәрделәр[1]. Без дә алар арасында идек. Үз ихтыярыбыздан китмәдек. Үзебез белән сыерларыбызны, куйларыбызны алдык, колхоздан безгә атлар бирделәр. Безне йөк вагоннарына керттеләр һәм Карелиягә илттеләр. 1940 нчы елда анда иген үстердек. Шулай тормышыбызны Карелиянең Куркижоки исемле авылында башладык. Бу җирләр әүвәл финнәр кулында булган, алар торган урыннарын үз хәлендә калдырганнар. Бездән дәүләт чигенә бер километр гына иде.

– Белүемчә, Миехиккялядә балалар белән 90га якын татар булган. Алар барысы да Җамбактыдан идеме?

– Күп өлеше аннан иде. Совет иленең башка төбәкләреннән күчерелгәннәр дә бар. Лагерьда балалар да бар иде. Берничә бала анда туды.

– Әтием Габделхак Сафиулла миңа бу вакыйгалар турында күп сөйләгән иде, әмма сезнең концлагерьга ничек эләгүегез турында мәгълүматым юк.

– Фин солдатлары безне әсир иткәннән соң *(1941 елның 7 августы)*, Куркижокидан Миехиккяля лагерена алып киттеләр, әни-әтиләрне сарайларга ябып куйдылар. Лагерьда әтиәниләребез арба белән кырга икмәк җыярга чыгалар иде. Ә безне – балаларны сарайга бикләп куялар. Без ул сарайларда егерме көн тордык. Көннәрдән беркөнне безне урамга чыгардылар. Өч малай, ә мин аларның артыннан йөгерәм... Юл аша чыканда Солтан исемле малайны солдатлар төягән зур машина таптады, ул үлде. Мин аның каны ничек акканын күрдем. Аннары ул малайны юып-нитеп күмгәннәр. Шулвакытта мин бик каты елаганмын. «Мин үлсәм, мине җиргә күммәгез, карават астына гына куегыз», – диеп әйтәм икән. Әйберләребез юк иде, малайның

[1]Кемнәр әсир төшкәнлеге һәм күченгәнлеге, ягъни гаилә әгъзаларының исемлеге белән www.beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

өстендәге киемен юганнар да миңа кигезгәннәр. Шуннан соң мин сөйләшми башлаганмын. Бер сүз сөйләшмәгәнмен, алар нәрсә әйткәннәрен мин аңлыйм: утыр, дисәләр – утырам, бар, дисәләр – барам, аша, дисәләр – ашыйм. Ә алар әйткән сүзгә каршы берни әйтә алмыйм. Концлагерьда булганда да сөйләшә алмаганмын.

– Бу хәл Миехиккяля лагеренда булдымы?

– Әйе, сөйләшмәвем озакка сузылды. Аннары, Ярвенпяага килгәчтен, Фатима тутай мине Хельсинкига табиб янына алып барды. Минем исемдә юк, ничектер гипнозлаганнар, күрәсең. Шуннан башлап мин бераз сүзләр әйтә башладым. Фатима тутай белән әни, дус булгачтын, бер-берсенә баралар иде. Әнинең бер таныш фин хатыны бар, ул рак белән авырый иде, әни аны карады.

– Әтием Габделхак Сафиулла һәм Гани Хәсәнгә Миехиккялядәге лагерьда булган мөселманнарны килеп алырга, аларны Хельсинки белән Ярвенпяага күчерергә рөхсәт ителгәнлеге турында документ бар. Әтиемне искә төшергәнсез, дип уйлыймын. Ул 1942 елның май аенда Гани Хәсән белән Миехиккялядә булды. Аңарга «Озын Габделхак» дигән кушамат биргәннәр, чөнки буе 190 см.га якын иде. Бу вакыйгаларны хәтерлисезме?

– Мин «Озын Габделхак»ны, мулла хәзрәтне (Вәлиәхмәт Хәким) хәтерлим. Аннары Ярвенпяада мәчет ачтылар, аның рәсемнәре миндә бар.

– Миехиккяля лагеренда, белүемчә, 3500 тоткын булган.

– Әйе, тоткыннар күп, анда койма белән аерылган ике өлеш бар иде. Берсендә – сугыш тоткыннары, ә икенчесендә – безнең кебек әсирләр: ирләр, хатыннар, балалар. Күп күрдек, әмма, бәхеткә каршы, сәламәт яшәп калдык.

– Ярвенпяа мәчете ачылганга 2014 елда 70 ел булды. Мәчетне төзегәндә әти-әниегез, лагерьдан килгән башка татарлар катнаштымы?

– Хәтерләмим. Әмма шуны беләм: әтием Ярвенпяада агач кисә торган фабрикада эшләде.

– Сезне 1945 елның гыйнвар аенда Совет иленә кайтардылар. Моңардан нинди хатирәләрең бар?

–1944 нче елның декабрь аенда, безне кайтаралар, дип хәбәр иттеләр.

– Сез поезд белән киттегезме?

– Әйе, Ярвенпяадан Хювинкяага киттек. Хювинкяада булганда Фатима тутай безне озатырга килгән иде, мине кочаклый, үбә. Минем энә бар иде, ул мине кочаклаганда, энә аның битенә эләкте дә, битеннән кан чыкты. «Синең белән тагын да күрешербез, – ди, – чөнки битемнән кан да ага...» Аннан соң күп күрешергә туры килмәде. Финляндиягә килгәч, мин аның кабере янында дога кылдым.

– Кире кайтканда сезне иң әүвәле кая илттеләр?

Безгә, өйгә кайтаралар, дип вәгъдә кылдылар, әмма беркем дә өенә кайтарылмады. Урыслар, юлда табиб һәм башкалар булыр, дип тә вәгъдә кылды. Выборгта поездга теләнчеләр керде, шулардан Русиядә тормыш ничек икәнлеген аңладык. Тоткыннар төрмәсендә бик салкын иде, бөтен тәрәзәләр ватык. Сөйләтүләр төнлә барды. Йокыга китәр алдыннан, чакырып: «Кемнәр белән гаскәрдә булдың?» – дип сорадылар. Кечкенә мәсьәләләрне дә сөйләргә мәҗбүр идек, бөтенләй тынган булсак, безне куәтле җәзалаган булырлар иде. Хәлләр авыр булды. Аннан икенче урынга күчерделәр. Анда без 15-20 көн тордык. Әти-әниемне яңадан сөйләттеләр: «Ни өчен анда бардыгыз? Анда кая бардыгыз?..» – дип сорадылар. Безне Казанга җибәрмәделәр, 1947 нче елдан әүвәл бер авылга илтеп ташладылар. Бу авылда берничә ел яшәдек.

– Сез анда урнашкан урын нинди дә булса концлагерь идеме?

– ... юк, ул концлагерь түгел иде. Андагы тормыш хәлләре авыр иде, үлә яздык. 1947 нче елда гына безгә Казанга

Татар әсирләре һәм Ярвенпяа татарлары. Соданкюля авылында ике яшь әсирнең йөзек алышу мәҗлесендә төшерелгән рәсем. Уң якта ак яулыклы ханым – Рәхилә Абдуллинаның әнисе Бәдерниса Габделхакова. 1943 ел

кайтырга рөхсәт бирелде. Кая барырга да урын юк. Башта кардәшләр янында яшәдек. Тормыш хәлләре вакыт узу белән яхшырды. Хәзер барысы да яхшы, әмма бик картайдык инде.

– Белүемчә, Татарстанда фашист концлагерьларының элеккеге кечкенә тоткыннары иҗтимагый оешмасы эшли. Ул оешманың максаты нидән гыйбарәт?

– Аның максаты – концлагерьга эләккән һәрбер балага ярдәм итү. Мин бу оешманың Татарстандагы бүлекчәсе рәисе. Әнием миңа хатирәләрен сөйләде. Ул вакыйгаларның күп өлеше миңа таныш. Бездә күп материал бар...

Беренче Президент Минтимер Шәймиев белән очрашу вакытында 79 татарның Финляндия концлагеренда яшәве, без авыр хәлдә булганда фин татарларының ярдәм итүе турында сөйләдем. Безгә, соң булса да, Финляндия татарларына, аларның безгә күрсәткән яхшылыклары өчен, рәхмәтебезне белгертергә кирәклеге турында әйттем, Татарстанда әле дә фин лагеренда булган 28 әсир яшәвен белдердем. Лагерьда булган вакытыбыз турында элек сөйләргә мөмкин түгел иде, әмма хәзер вазгыять башка, дидем. М.Шәймиев миңа карады да: «Татарстан әсирләренә күрсәткән ярдәмнәре өчен, әлбәттә, Финляндия татарларына рәхмәтебезне укырга кирәк», – диде, лагерьда булганнарга Финляндиядәге милләттәшләребез белән очрашу мөмкинлеген дә әйтте. Кызганыч, йөрәккә авыр операция ясатуым сәбәпле, бу мәсьәлә хәл ителмәде. Финляндия концлагерьларында әсир булган татарларның исемнәрен күрсәтеп истәлек ташы да куелса, яхшы булыр иде.

– Тарихи әңгәмә өчен рәхмәтемне белдерәм! ■

Безнең мирас №5 май 2017

ТОРМЫШ ЯМЕ

(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе ФӘРИТ ХӘЙРУЛЛА улы МӨХӘММӘТШИН белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Фәрит Хәйруллович, мөмкин булса, сәясәт һәм ил-көндәге вазгыять турында сөйләшүне бүтән бер вакытка калдырып, тормыш-яшәеш, халкыбыз мирасы, ата хакы, гаилә, милли тәрбия, гомумән, рухи кыйммәтләр һәм кадерле ядкярләр хакында сөйләшик әле. Беренче соравым мондый: Сезнеңчә – нәрсә ул Тормыш яме?

– Тормыш яме... Кеше бу дөньяга кунак булып кына килә. Санаулы еллар... Шул кыска гына гомергә дөньяга килгәнсең икән, үзеңнән соң нинди мирас калдырасың? Традиция, гореф-гадәтләр – халык тормышының аерылгысыз мөһим өлеше. Аның иң күркәмнәрен бөртекләп саклап, балаларга тәрбия аша биреп калдыру – яшәүнең олы бер мәгънәсе.

СССР заманында ук: «Гаилә – җәмгыятьнең нигезе», – дип әйтә идек. Җәмгыять гаилә корып, балалар тудырып, үстереп, тәрбияләп яшәүгә, аларга картлыгыңны ышанып тапшыруга корылган. Балаларның, оныкларның тормышы безнекеннән матуррак, баерак, күңеллерәк булсын иде, дип өметләнәсең.

Гаилә тәрбиясе дигәндә, мин үземнең

әти-әниемне, әби-бабамнарны, тормыш иптәшем Луизаның әти-әнисен искә алам. Матур яшәделәр алар! Без – балаларына, оныкларына матур итеп яшәү үрнәген калдырып киттеләр.

Әтием Хәйрулла – Әлмәт төбәгендә билгеле, хөрмәтле кеше иде. Фронттан коммунист булып кайткан солдат, партия кая кушса – шунда барды, намус белән хезмәт итте. Мин үземне белә башлаганда без Акташ авылында (кечкенә генә район үзәге) яши идек. Урыс авылы. Без райком йортында торабыз. Әти көне-төне эштә, әнием Маһинур без – өч баланы тәрбияли. Мин – өлкән бала, ике сеңелне карау минем өстә. Рәйсә әле кечкенә иде, Әлфия миннән бер дә калмый, гел ияреп йөри. Яз җитеп чирәм күренүгә, яланаяк йөри башлыйбыз, аяклар чебиләп бетә. Аны уйлаган кеше юк инде, әни кушкан вак-төяк эшләрне үтибез дә урамга чабабыз. Без авылда берләнбер татар гаиләсе идек, рус балалары белән уйнап үстек. Шуңа күрә телебез дә күбрәк русча иде.

Әти белән әни бик тату яшәделәр, бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар иде. Әти көннәр буе өйдә булмаса да без аны янда тоя идек. Әни һәрвакыт: «Әтиегезгә әйтәм!», «Әтиегез кайткач...», «Әтиегез белән киңәшербез», – кебек сүзләрне әйтеп, өйдә әтинең төп кеше – хуҗа икәнен сиздереп тора иде. Әти гомер буе минем өчен зур авторитет булды. Әти, әнинең кадерен белеп, аның белән һәрвакыт киңәшеп яшәде. Ул әнигә, ягымлы итеп, «карчык», дип эндәшә иде. Ышанырсызмы-юкмы, берзаман бу сүз минем дә телгә керде бит. Ниндидер командировкадан йөреп кайткач, Луизага «карчык» дип эндәштем. Башта аптырап калды. Аннан соң аңлады бу сүзнең хикмәтен. Хатыныңа болай эндәшү күп мәгънәне аңлата... Аны икәү генә белә.

Әтием миңа һәрвакыт: «Улым, шулай эшлә — эшеңдә дә, тормышыңда да йөзгә кызыллык китерерлек булма», – дип еш әйтә торган иде. Иң олы бәхет шул: син, күп кенә еллар эшләп, синең белән янәшә булган һәм сине белгән кешеләр: «Әнә, теге кеше шундый яхшы иде, кешегә авыр сүз дә әйтмәде, ярдәмчел булды», – дип искә алсыннар. Һәр кешегә шулай яшәргә насыйп булсын. Шулай булса гына, җәмгыятебез, күпмилләтле республикабыз матур яшәячәк.

Гомумән, республикабызда яшәгән һәр милләтнең гореф-гадәтләрен, йолаларын сакларга, аларны үстерергә кирәк. Гасырдан-гасырга килә торган күркәм гореф-гадәтләр, мәсәлән, олыны – олылау, кечене – кече итү буыннан-буынга күчәргә тиеш. Шул очракта гына ышанычлы, нык һәм камил җәмгыять төзи алачакбыз. Шулай ук үз авылыңны, туган җиреңне, шәһәреңне, дәүләтеңне яратып, аның уңышлары белән горурланып, авыр чагында да, җиңел чагында да ватанпарвәрлек хисен алга куеп яшәсәк, яхшы булыр иде.

– Әйе шул, юкка гына, гаиләң нинди – дәүләтең шундый, димиләр бит.

– Кыска гына гомеребездә шушы байлыкларны күз алдында тотмыйча яшәсәк, бу — бушка үткән гомер була.

Әйткәнемчә, һәр милләт үз телен, йолаларын, гореф-гадәтләрен саклап, аларны киләчәк буыннарга тапшырып калдырырга тиеш. Мин Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе вазифасын үтим. Татарстанда 173 милләт вәкиле яши. Аларның һәммәсенең үз теле, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, милли ашлары, киемнәре... Татарстанда яшәүче халыклар барлыгы 36 милли-мәдәни автономиягә берләшкән. Бу милләтләр бергә җыелган вакытларда Халыклар дуслыгы йорты кырмыска оясын хәтерләтә, мыжлап тора. Әлеге күренеш миңа шулкадәр ошый, төрле телләрдә сөйләшүче, төрле дин тотучы кешеләрнең шулай бергә җыелып җитди чаралар үткәрүләре, яисә бәйрәм итүләре күңелдә шатлык, горурлык хисләрен уята. Без Татарстанда аларга үз телләрен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау өчен мөмкин булганны эшли алдык: автономияләргә берләштердек, якшәмбе мәктәпләре ачтык, аерым бәйрәмнәрен республика күләмендә билгеләп үтәбез. Удмуртларның Гырон Быдтон, чувашларның Уяв, мордваларның Балтай, керәшеннәрнең Питрау, төрки халыкларның Нәүрүз бәйрәмнәре го-

мумхалык бәйрәменә әверелде, аларга башка өлкәләрдән, хәтта чит илләрдән дә кунаклар килә, милләттәшләре җыйнала. Шушы көннәрдә генә Татарстан халыкларының III съездын уздырдык. Бу – бездә яшәүче халыклар белән эшләүнең бер ысулы. Съездның беренчесе 1992 елда үткәрелде. Ул чагында ил үзенең киләчәген билгели иде. Без исә, җыелып, ул замандагы актуаль мәсьәләләр, Татарстанның киләчәге хакында ачыктан-ачык сөйләштек. 22 апрельдә узган съездда без, башкарган эшләребезгә йомгак ясап, милләтләрне киләчәктә тагын да үстерү өчен өстенлекле юнәлешләрне билгеләдек.

– Күп кенә күренекле шәхесләребез белән соңгы көннәре, минутлары якынлашканда аралашырга туры килде. Алар: «Гомерем, вакытым заяга узды», – дип, еш кына уфтану, үкенү хисләрен белдерә иде. Күп очракта гомеребезнең кадерен белмибез шул.

– Дөрес, тормышның кадерен, аның фәлсәфәсен азрак тәҗрибә җыйгач кына аңлый башлыйсың. Яшь чакта көндәлек тормыш белән яшисең, төрле вак-төякләргә куанасың, ә тирәнрәк уйласаң, тормыш һәрбер көннән җыела. Ни дисәң дә, яшьлек – дәртле вакыт. Бераз яшәп, тәҗрибә туплагач, тормышның яртысы үткәч кенә кеше яшәү яме, аның мәгънәсе, фәлсәфәсе турында уйлана башлыйдыр, мөгаен...

– Дөнья, урыс әдәбиятының бу фани тормыштан яшьли киткән мәшһүрләре, мәсәлән, Лермонтов, Тукай бар. Алар яшәү мәгънәсен, яшәү кадерен аңлап өлгерделәрме икән?

– Андыйлар меңгә бер туа. Кыска гына гомерләрендә даһи әсәрләр калдырганнар икән, димәк, бу турыда уйланганнардыр. Күп кеше арасында яшәгәч, йөргәч, үземнең тәҗрибәмнән чыгып та әйтәсем килә: тормыш турында күбрәк 45-50 яшьләрдән соң, оныкларны үстергәндә генә уйлана башлыйсың.

Тукайлар кебек олуг шәхесләребезнең әйткәннәре – кичә дә, бүген дә, иртәгә дә актуаль, мәңгелек, дөрес сүзләр. Алар даһи кешеләр һәм, әйткәнемчә, мондыйлар сирәк туа.

– Гаилә, тәрбия, буыннар чылбыры... Нәсел-ыруыгыз мисалында бу хакта да әйтеп китсәгез иде?

– Яшь чакта да, хәзерге көндә дә фикерем үзгәрмәде: балага тәрбия бирүдә иң беренче чиратта ата-ана җаваплы. Мин бу хакта әйтә башлаган идем инде. Юкка гына халыкта «оясында ни күрсә, очканында шул булыр» дигән сүзләр мәкаль рәвешен алмагандыр.

ӘТИЕМ ХАКЫНДА

Мин һәрвакыт, якыннарың, бигрәк тә әтиең яки әниең турында сөйләү һәм язу уңайсызрак һәм тыйнаксызлык, дип санадым. Минем карашымча, иптәшләренең, дусларының истәлекләре яңгыраса, табигыйрак һәм дәлиллерәк булыр иде. Бу юллар миңа авырлык белән, озак уйланулардан соң бирелә һәм әтиемне җирләгәндә, кадерле кешемнең кабере янында, әлеге авыр минутларда янәшәмдә булган кешеләр алдында бирелгән вәгъдәм генә мине каләм алырга этәрә. Әтиемне озак еллар буе якыннан белгән дуслары һәм хезмәттәшләре үз истәлекләрен бастырып чыгарырга теләделәр. Һәм тагын бер мөһим сәбәп бар: шәхсән үзем без, яңа буын балаларыбыз һәм оныкларыбыз хәтерендә балачакларында ачлык һәм мохтаҗлык күргән, кырыс сугыш елларын кичергән, сугыштан соңгы җимереклекне бетерүдә актив хезмәт куйган XX гасыр башында туган кешеләр хакында чын дөреслекне калдырырга тиешбез, дип саныйм... Алар, бу авырлыкларга карамастан, актив һәм яңарыш тудыручы иҗади гомер кичерделәр.

Әтием, Хәйрулла Динкәй улы Мөхәммәтшин ТАССРның Сарман районы Иске Кәшер авылында 1918 елның 9 сентябрендә туган. Бик иртә әтисез калып, авылда әнисе белән үскән. Соңрак искә алуынча, балачагы, шул чорның башка кешеләрнеке кебек үк, авыр тормышта, ачлыкта үткән. Аның хәтерендә бигрәк тә ялланып эшләү уелып калган, өстәвенә, яшелчә бакчасы да 10 яшьтән аның өстенә йөкләнгән. Аңа җәй буе 30 сутый (әнисе билгеләгән норма) җир эшкәртергә туры килгән, чөнки әнисе бу вакытта колхозда хезмәт куйган. Шулай гына исән калып булган.

***

Әтиемне җирләгәндә хезмәттәшләре: «Фәрит, әтиең зур эшләр башкарды, әйдә, аның турында китап яз», – диделәр. Озак кына уйланып йөрдем. Ә бер кичне, ул чакта Мәскәүдә командировкада идем, төн утырып, истәлекләремне яздым. Аннан соң әтиемне белгән кешеләрдән хатирәләре белән уртаклашып, мәкаләләр язып җибәрүләрен үтендем. Менә шулай итеп китап барлыкка килде.

Безнең мирас №5 май 2017

«Һәр гаиләдә әби-бабайларны искә алып, балаларына алар хакында сөйләп калырга тиешләр».

Әйткәнемчә, мин – бер-берсен хөрмәтләп яшәгән гаиләдә туып үскән бала. Әби-бабай тәрбиясе дә әләкте. Әнием ягыннан Мирзиян бабам белән Вәсилә әбием үз йортлары белән Әлмәттә яшәде. Каникул җитсә, бөтен бала-чага аларга җыела торган идек. Бабай безне печән чабарга, чалгы кайрарга, башка вак-төякләргә, иң мөһиме – ир-ат эшенә өйрәтте. Әбием – бик нечкә күңелле, бала җанлы карчык иде. Аның Коръән ашыннан кайтканда кесәсеннән алып биргән әчкелтем кәнфитләренең тәмен хәзер дә тоям кебек. Мин – аларның яраткан оныгы идем. Аллага шөкер, алар озын гомер кичерделәр. Улыбыз Дамир тугач та икәүләп килделәр, базарга кереп, шакмаклы күлмәк алганнар. Шул зур күлмәкне кигезеп улыбызга исем кушып китте Мирзиян бабай.

Нәсел төшенчәсе аеруча зур кыйммәткә ия. Элек гаиләдә бала-чага күп була иде. Бер нәселдән булган гаиләләр бер-берсенә ярдәм итеп, ихтирамлы мөнәсәбәттә яшәде. Геннар да мөһим роль уйный. Мәсәлән, минем нindидер яхшы якларым бар икән, тырышлыгым, халык белән аралашу-сөйләшүем, нидер дәлилләвем, укуга тартылуым – болар барысы да әти-әниемнән килгән сыйфат. Әтием гомере буе укыды, белем алды. Мин аның үз өстендә ничек итеп эшләгәнен күреп үстем: төннәр буе КПСС тарихы турында китаплар, газеталар укып, радио тыңлап, чыгыш-докладларын халыкка аңлаешлы итеп язып утыра иде. Әтием һәр очрашуга бик җаваплы итеп әзерләнде. Миңа да: «Улым, әзерлексез булсаң, кеше белән эшләве авыр. Берүк халык алдына алдан әзерләнмичә чыга күрмә, чөнки әйткән сүзеңә ышанмаска мөмкиннәр. Әзерләнеп, аргументлар табып сөйләсәң генә, кешене ышандырырсың һәм, шуның өстенә, әйткәннәреңне үз көндәлек тормышың белән дә дәлилләп күрсәтергә тиеш буласың. Бер төрле сүз сөйләп, икенче тормыш алып барсаң, синнән кешеләр көләчәкләр генә», – дип әйтә торган иде.

Без Луиза белән 1970 елда өйләнештек. Мөхәммәтшиннар һәм Хуҗиннар гаиләсенең тормыш юлы бергә үрелеп китте. Шунысы да куанычлы булды – безнең әти-әниләр элек-электән бер-берсен белгән, аралашкан, бер үк кыйммәтләрне бәяләгән кешеләр булып чыкты. Әтием Луизаның әнисе Рокия Сарим кызы белән бер мәктәптә укыган, ә булачак кодасы белән яшүсмерләр футбол командасында бергә уйнаганнар. Алар яшьтән үк дус булганнар.

Бу гаилә белән танышуга ук үземне биредә «үз кеше» итеп тойдым. Кече Әлмәтнең Мостовая урамында урнашкан әлеге йортта рәхәт бер җылылык, үзгә бер аура бар иде. Җитди кыяфәтле, эшлекле, кирәк вакытта юмор белән сөйләшүче хуҗа – Әкърәм Хаҗи улы. Ул – Бөек Ватан сугышы ветераны, Әлмәт шәһәре типографиясе директоры, гомумән, шәһәрдә билгеле шәхес иде. Тыйнак кына киенгән, чәчләренә чал төшә башлаган Рокия Саримовна укытучыны хәтерләтә. Гаиләдә өч бала, үз йортлары белән яшиләр. Яңгырдан ышыкланып була торган түбәле зур капка аеруча хәтеремдә калган.

Без дус-тату, бер-берсенә ышанучан, булышучан, бердәм зур гаилә идек. Нинди дә булса сәбәп табып, еш очрашырга тырыштык. Бу еллар безнең балаларыбызга әби-бабай тәрбиясе биргән мөһим еллар булган. Үз хуҗалыгың белән яшәгәч, башкача булмыйдыр: йә түбә ямарга кирәк, йә койма тотарга, мунча салырга... Аларның уллары Ринат белән без – Нәҗип белән мин – ике кияү аларга хуҗалык эшләрендә булышырга тырыша идек. Безнең малайлар да янда чуалалар. Рокия Саримовна бик тә уңган хуҗабикә иде. Ул гомере буе дәүләт хезмәтендә булды. Хезмәт кенәгәсендә нибары ике юл язылган: беренчесе – районның социаль тәэминат бүлегенә эшкә кабул螢 ителде; икенчесе – лаеклы ялга чыгу сәбәпле эштән китте. Пенсиягә чыккач та аның яныннан кеше өзелмәде: кемдер ниндидер документ белешә, күпләр пенсиягә, социаль нормаларга кагылышлы законнар, кагыйдәләр турында сорашырга килә. Үзем дә берничә тапкыр шул очрашуларга шаһит булдым.

Без һәр шимбә аларга мунчага бара идек. Өч баласы үз гаиләсе белән килә, кода-кодагыйлар, туганнар... Ничек сыйганбыз без ул өйгә, әле дә аптырыйм. Рокия Саримовнаның мунчасы ягылган, бәлеше пешкән, табыны ризыклар белән тулы булыр иде. Шунда сөйләшеп, җырлашып утыра идек, бала-чагалар да бергә уйныйлар, безгә үз һөнәрләрен күрсәтәләр. Шушы җыелып утырулар

Оныгы Данияр белән

туганлыкны тагын да ныгыта, нәселне берләштерә. Шатлыкта гына түгел, авыр мизгелләрдә дә без бергә булдык – югалтуларны бергә күтәрдек, шатлыкларны бүлештек. Хәзер эти-әниләр арабызда юк инде, ел саен балалар белән зиратка барабыз, ата-бабаларыбызның каберләрен чистартабыз, чардуганнарын буяп кайтабыз. Элек улым Дамир белән эшли идек, хәзер оныгым Данияр да безнең белән! Узган ел оныгым белән 9 майда Җиңү парадына чыктык. Данияр ике бабакаеның да сугышта батырларча көрәшкәнен белә һәм алар белән горурлана. Минә калса, һәр гаиләдә әби-бабайларны искә алып, балаларына алар хакында сөйләп калырга тиешләр. Гаиләләр тарихы ватан тарихына барып тоташа. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге дә бик томанлы.

Нәсел, туган-тумачаның роле хәзерге шартларда, мөгаен, кимегәндер. Ә бит авыр сугыш елларыннан соң, авыл җирендә бер-береңә, туган буларак, ярдәм итешеп яшәү кешеләрнең канына сеңгән иде. Җиде буын туган-тумачаны белү изге төшенчә булды. Үз буыныңны, кардәш-туганыңны белеп, аралашып, бер-береңә кулдан килгәнчә ярдәм итешеп яшәүне авыр тормыш үзе үк таләп итә иде.

Хәзер һәр гаиләдә 2-3 бала, оныклар да шул чама, нәселнең дә куәте, сыйфаты

Гариф Ахунов янәшәсендә

Фикердәшләр, аркадашлар

елдан-ел кими бара. Шулай да туган-тумачага хөрмәт татар халкында әле дә бар. Сабан туйларына, гаилә бәйрәмнәренә кардәш, нәсел-нәсәп кешеләре бергә җыела. Бу – гасырдан-гасырга күчеп килә торган олы традиция. Әлеге күркәм гадәт халыкны берләштерә, бер-берсен тәрбияли, камилләштерә.

– Дус-иптәш, аркадаш, кардәш-карындаш... Дуслык һәм туганлык... Санап үткән әлеге алыштыргысыз рухи кыйммәтләрнең бәясе соңгы елларда шактый төште шикелле. Әхлак һәм намус какшаган, иман ныклыгы чатнаган мәл. Кешенең эчке дөньясы отыры ярлылана, аның күңелен хөсетлек, көнчелек сөреме сара бара... Ил агасы буларак, дуслык, ышанычлы дуслар турындагы фикерегезне ишетәсе килә иде.

– Якын дусларны, хезмәттәшләреңне сайлый алсаң, хата-ялгыш ясамасаң, тормыш юлын үтүе җиңелрәк, ышанычлырак була. Яхшы дуслар... Кемдер, дусларына ияреп, хыянәт юлына баса, аракы эчү белән мавыга башлый, укуга битараф була. Гаиләдә яхшы тәрбия алып, дусларның да яхшыларын сайлап алган кешеләр – иң бәхетлеләр. Дуслар күп булмыйдыр, ләкин таныш-белеш, хезмәттәш, күршекүлән дигән төшенчәләр дә бар. Аларны да хөрмәт итеп, дус-тату яшәсәң – тормышта шулардан да кыйммәтлерәк нәрсә юктыр.

Бүгенге көндә күршеләрдән зарланып язылган дәгъвалар, мөрәҗәгатьләр гаять күп. Юк-бардан ызгышу, килешә алмау шундый хәлгә китерә. Үзләренең дә, күршеләренең дә тормышларының кызыгы бетә. Болар – гыйбрәт. Тормыш тәҗрибәсе туплаган кешеләрдән исә үрнәк алып яшәргә өйрәнергә кирәк.

Без бәләкәйдән үк гел урыслар белән генә аралашып яшәдек. Ә алар яхшы кешеләр иде: тырыш, хезмәттә актив, үзләренең ихатасын, мал-туарын, хуҗалыгын да карарга өлгерәләр, җәй буе малга печән әзерлиләр иде. Балачак күршеләрем менә шундый тырыш, гадел кешеләр булды. Без дә алардан үрнәк алып тәрбияләндек.

Гадәттә, дәрәҗәле эштә эшләсәң, дусларың күп була. Ә инде аннан китү белән, яныңда чын дуслар гына кала. Алар күп булмый. Әлмәт шәһәренең комсомол оешмасында инструктор булып эшләгәндә дуслашкан кешеләр – мөгаен, иң якын дусларымдыр. Алар гаилә дуслары булып киттеләр. Хәзер инде төрлебез төрле якларда яшибез, еш күрешеп тә булмый, әмма элемтәне өзмибез. Җәй

чыкса, шатланып күрешәбез. Туган көн, бәйрәмнәр белән котлашабыз.

Бәхет-шатлыгыңа сөенә белсәләр, авыр көннәрдә килеп, кайгыңны уртаклашсалар, ярдәм итсәләр – болар синең чын дусларың. Һәр гаиләнең, һәр кешенең шундый дуслары күп булсын иде, дип телим. Кайгы-хәсрәт килгән чакта якын, ышанычлы дусларың булу да кирәк.

– Фәрит Хәйруллович, Сезнең белән очрашуга килер алдыннан, интернеттан, төрле матбугат чараларыннан биографиягез белән кабат танышып чыктым. Сезгә нисбәтле үзенчәлекле фотолар арасыннан берсе мине аеруча җәлеп итте. Бильярд уйнаганда төшерелгән фотогыз турында әйтүем. Шушы кадрда Сезнең бөтен холкыгыз чагыла сыман: максатчанлык, җорлык, сабырлык, зирәклек, тәвәккәллек... Ул чагында шарны кертте-гезме?

– Һәр кеше үз тормышында спортның нинди дә булса төре белән шөгыльләнергә тиеш. Мин бүген республикада волейбол федерациясен җитәклим, кайчандыр хоккей федерациясен дә оештырырга туры килде. Ә бильярд – аерым уен: өстәл, уналты шар һәм партнер... Башка берәү дә юк. Үз-үзеңә ышанып, карар кабул итеп, гадел көрәшергә тиешсең! Бу уенны мин бик яратып, рәхәтләнеп уйныйм. Монда уйныйсың да, уйлыйсың да. Еш кына көндәлек проблемалар турында уйлыйсың, ә бильярд уйнаганда аларның чишелешен дә табасың. Сәясәтчеләр, хәрбиләр арасында бильярдны яратучылар гаять күп. Аңлашыла ки, бу – ниндидер авыр мәсьәләләрне ерып чыгу юлын да күрсәтә торган уен. Әлеге шарны кертүкертмәвем исемдә калмаган. Минем белән уйнаган дуслар, Фәрит Хәйруллович, син яхшы уйныйсың, диләр. Чын күңелдән әйтәләрдер дип ышанам...

– Сезне концертларда, театрларда, юбилей кичәләрендә еш күрәбез. Ике дәүләт телендә дә камил чыгыш ясыйсыз, афәрин! Шундый кичәләрнең берсендә халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмнең шигырь укуын сокланып



БЕЗНЕ УЕН БЕРЛӘШТЕРӘ!

Бөтен кешелек уйный! Тугач һәм «тирәякка күз салгач», без уен дөньясына эләгәбез һәм, уйнап, яшәргә өйрәнәбез. Өлкәнәябез һәм уйнауны дәвам итәбез. Музыка уен коралларында уйныйбыз, спорт уеннарын уйныйбыз, «кызыкка» һәм гаять зур акчаларга уйныйбыз. Кызып китеп, мавыгып уйныйбыз, кайчакта хәтта – дәүләт белән дә... Театрларда һәм кинода махсус өйрәтелгән кешеләр «чын» яки уйлап чыгарылган тормышны уйныйлар. Ә без – моңа ышанабыз. Һәм кайчак кайда тормыш, кайда уен икәнлеге дә аңлашылмый башлый...

Чынлап та, бөтен тормыш – уенмы икәнни?! Моны, кире кагып булмаган кебек, дәлилләп тә булмый, әмма шунысын истә тотарга кирәк: уеннан чыгарга һәм яңадан башларга мөмкин, ә тормыш белән моны эшләргә ярамый. Һәрвакыт... Исеңдә тот моны, Дустым!

Бильярд өстәле янында дошманнар юк, дуслар гына – бу уендагы көндәшләр генә бар. Бильярд якынайта һәм берләштерә, ул тынычландыра, көндәлек һәм һәр сәгатьлек проблемалардан һәм рухи авырлыклардан «бушандыра».

Бильярд – күңел һәм тән өчен иң әдәпле уен...

Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев белән

тыңлап утырганыгызны да хәтерлим әле…

– Мин кечкенәдән шигырь укырга бик яраттым. Авыл китапханәсендә укучылар конференцияләрен еш үткәрәләр иде, мин дә анда катнашам, шигырь сөйли идем – русча.

Татарстан Югары Советына депутат булып узып, парламент рәисе итеп сайлангач, татар телен камил белмәвем мине уйланырга мәҗбүр итте. Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова һәм тагын берничә депутат татарча сораулар бирә, ә мин урыс телендә җавап кайтарырга мәҗбүрмен. Мин бу хәлне үзгәртергә тиеш идем, дөресрәге, үз өстемдә эшли башларга. Максатчан рәвештә татар әдәби телен өйрәнә башладым. Бәхетемә, ул заманда парламентта татар язучышагыйрьләре шактый иде: Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллин, Туфан Миңнуллин… Ренат Харис исә минем урынбасарым булды. Өйгә кайткач, алар язган әсәрләрне, шигырьләрне кычкырып укыйм, икенче көнне алардан үзем төшенеп җитмәгән сүзләрнең мәгънәләрен сорый идем. Алар миңа бик ярдәм итте. Татар теленең матурлыгын, байлыгын шул рәвешле тойдым һәм милли әдәбият, мәдәният белән кызыксына башладым.

Мөдәррис Әгъләмнең иҗат кичәсен хәзер дә хәтерлим. Аның язганнары белән элек тә кызыксына идем. Иҗат кичәсенә барыр алдыннан китапларын алып, махсус укып чыктым. Баксаң, аның иҗатында гаять тирән, фәлсәфи фикерләр ята икән… Аның авыруы турында хәбәрдар идем. Бөек шәхесебезгә исән чагында «Халык шагыйре» исемен биреп өлгергәнебезгә шатланам. Ул вакытта мин Мөдәррис Әгъләмгә «Халык шагыйре» исемен бирү турында Президент Указын укыгач, халык бик озак кул чапкан иде.

Гомумән, шәхесләрнең иҗат кичәләренә барганда һәрчак әзерләнеп барам. Әсәрләрен укып чыгарга тырышам, башкарган эшләре турында мәгълүмат алам. Шунсыз ярамый – миңа бит ул шәхесне хөрмәт итеп килгән халык алдына чыгып чыгыш ясарга, ул кешенең хезмәтләрен дәүләт тарафыннан бәяләргә кирәк.

Эшкә җаваплы һәм җитди карарга мине Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә өйрәтте. 1990 еллар – авыр заман. Атнага икешәр мәртәбә Мәскәүгә йөрүләр, татар халкы, Татарстаныбызның киләчәге турында сөйләшүләр… Күп әйберләрне якларга, дәлилләп чыгыш ясарга туры

«Узган ел оныгым белән 9 майда Җиңү парадына чыктык»

килде. Минтимер Шәймиев: «Кинәт кенә барып, анда оттырып кайта күрмәгез! Башыгызны тыкканчы, иң элек аны кире алу Җиңүче булып чыгу турында уйлагыз!» – дип әйтә иде. Заманында без күпмилләтле Россиядә дәүләт оештырырга сәләтле халык икәнлегебезне расларга тиеш идек һәм моңа ирештек тә...

– ***Мәгълүм ки, мирас күптөрле: тарихи һәм тарихи-мәдәни, дини һәм фәнни, әдәби һәм сәнгати, табигый һәм рухи... Ата-баба мирасы, дип тә әйтәбез. Менә шул ата-баба мирасы, гореф-гадәтләребез һәм аларны саклап калу турында Сез ни-нәрсә әйтер идегез?***

– Мирасны саклап калсак кына киләчәгебез булачагын яхшы аңлыйбыз. Мирасыбызны саклау юллары, ысуллары күптөрле. Дәүләт оешмалары, халык үзе дә бу эш белән даими шөгыльләнергә тиеш.

Беренчедән, телебезне саклап калырга кирәк. Гомумән, күпмилләтле Татарстанда һәр милләтнең телен саклау актуаль. Тел – халыкның зур мирасы. Бу юнәлештә без берничә адым ясадык. Татар телен дәүләт теле иттек, мәктәпләрдә милли телләрне укытабыз, татар теле укытучыларына да ярдәм итәбез, төрле чаралар оештырыла... Әмма татар гаиләсендә бала туган телдә сөйләшми икән, мәктәптә биргән белем генә мәсьәләне хәл итми. Мәктәп белән гаилә бергә эшләргә тиеш! Бу – минем катгый фикерем.

Мирасны сакларга кирәк, дибез. Минем уйлавымча, мирасны югалта башлагач кына аның кыйммәтен, әһәмиятен тоя, аңлый башлаучы кешеләр саны арта. «Тукта әле, безнең менә мондый йолабыз бар иде, бүген инде ул бетеп бара, нинди зур рухи байлыгыбызны югалтабыз бит», – дип, галимнәр генә түгел, гади халык та уйлана башлый. Зур ышаныч белән әйтә алам: республикабызда матди һәм матди булмаган мирасның әһәмиятен аңлаучы кешеләрнең саны көннән-көн арта бара.

Татарстанда матди мәдәни мирас закон нигезендә саклана. Моңа һәртөрле корылмалар, музей экспонатлары, борынгы язмалар, гомумән, кул белән тотып, күз белән күреп була торган мирас керә. Узган утырышта парламент «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» дигән закон проектын икенче укылышта кабул итте. Ул закон тулаем кабул ителеп эшли башлагач, матди булмаган мәдәни мирасыбызны саклау мәсьәләсе җайга салынып, халкыбызның мирас сандыгында изге ядкярләр артыр дип ышанам. ■

АВЫЛ – МИЛЛӘТНЕҢ БИШЕГЕ

Агач корымый –
куккә тамыр җәя бары...

Без кискәнбез
ябалдаш дип
тамырларны:
җир асларын гөрселдәтеп,
күмер шауга,
бабамнарны кочаклаган
кәүсә ава...

Ләис Зөлкарнәй
«Авыл урынында».

«Туган авыл». Гариф Ахунов рәсеме*

*6 апрель көнне редакциябездә «Юкка чыккан татар авыллары: тарих, проблемалар» дигән темага «Түгәрәк өстәл» оештырылды. Чарада Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев**, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре **Альберт Борһанов**, **Дамир Исхаков**, **Эльмира Сәлахова** һәм **Рөстәм Әминов**, Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты галиме **Рафаил Шәйдуллин**, Бөек Ватан сугышы музее мөдире **Михаил Черепанов**, Алтай Республикасы халык шагыйре **Бронтой Бедюров**, Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары **Нәҗәт Нәгыймов**, тарихчы-эзтабар **Таһир Габдрахманов**, Лениногорск районы фермеры **Фәрит Нәбиуллин**, Бөгелмәнең Аксакаллар шурасы рәисе **Рабит Хәсәнов**, редакциябез хезмәткәрләре **Марат Закир** һәм **Ленар Гобәйдуллин**, төбәк тарихы белән кызыксынучылар катнашты. Чараны «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** алып барды.*

* Арча районында Гариф Ахунов туган, XX гасыр азагында юкка чыккан Кечкенә Өчиле авылы.
«Түгәрәк өстәл»дәге фикер-тәкъдимнәр белән тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

Ләбиб Лерон.

Мин үскән Олыймән авылы янәшәсендә генә Бишкүмәч авылы бар иде. Хәзерге көндә бу авыл урынында сыңар агач та юк, булганын да яшен суккан. Олыймәннән ерак түгел генә икенче бер авыл Мәчти – мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов, музыка галиме, флейтачы Мансур Солтанов туган авыл. Җир йөзеннән юкка чыккан авыллар проблемасы минем күңелемә дә бик якын.

Альберт Борһанов.

XX йөздә юкка чыккан авыллардан аермалы буларак, урта гасырдагы авыл урыны – археологик ядкяр. Төрле вакыйга, яулап алу, һөҗүмнәр нәтиҗәсендә халык аннан күчеп киткән. Соңгы чорда яңа бистәләр барлыкка килү, шәһәрләрнең үсеше якын-тирәдәге авылларның юкка чыгуына сәбәп булды. Мәсәлән, Азнакай, Сарман, Әлмәт районнарындагы кайбер авылларның халкы Җәлил поселогына китте. Миграция, ГЭСлар төзелеше, янгыннар нәтиҗәсендә дә күп авыллар бетте.

Разил Вәлиев.

Авылларның акрынлап юкка чыга баруы – илкүләмендә күзәтелгән кискен мәсьәлә. Без бу проблеманы депутатлар белән комитет утырышында ике мәртәбә тикшердек, Татарстанда авылларны комплекслы үстерү программасын кабул итәргә кирәклеген аңлаттык. Авылларны саклар өчен, мәктәп, клуб, медпункт, кибет кирәк, диләр. Әгәр төзек юл, кешегә эш юк икән, халыкны авылда мәҗбүри калдырып булмый. Яшьләр авылда төпләнмәсә, балалар тумаса, мәктәпнең дә, клубның да кирәге юк.

Милли шәһәрләре булмаган халык өчен моннан да зуррак проблема булырга мөмкин түгел, чөнки татар халкының язмышы турыдан-туры авыл белән бәйле. Татар авылының бик тә әһәмиятле үзенчәлеге бар. Казан яулап алынганнан соң, башкалабыздан китәргә мәҗбүр булган кешеләр авылларга килеп урнашкан. Авыл мәдәнияте белән шәһәр мәдәнияте бергә кушылган. Шуңа күрә авылларыбыздан шактый мәгърифәтле, зур, бөек шәхесләр чыккан.

«Мирас» дигән романымның төп темасы – юкка чыккан авыллар. Чаллы шәһәренә барып яши башлагач, автозавод, ГЭС төзелеше чорында күп авылларның юкка чыгуын үзем күрдем. Бу авылларда туган-үскән кешеләр белән аралаштым. Миңа сусаклагыч астында калган бер авыл халкының, һәр елны Сабан туе вакытында элек мәйдан булган урынга көймәдә барып, шунда гармун белән җырлап йөзүләре аеруча нык тәэсир итте.

Чаллының ул вакыттагы хакиме Рәис Кыямович Беляев, юкка чыга торган авыл кешеләрен, таркалмасын, нәселләре югалмасын өчен, уртак бер йортка урнаштыру кирәклеген әйтте. Казанда Татар бистәсе җимерелә башлагач, кешеләрне бер йортка күчерергә кирәклеген мин дә белдергән идем, әмма шәһәр җитәкчеләре, депутатлар бу тәкъдимемне хупламады.

Беткән авылларга мөнәсәбәт нинди булырга тиеш? Юкка чыкканны тиз генә торгызып булмас. Бу авылларның зираты койма белән уратып алынган булырга тиеш. Андагы борынгы кабер ташлары хуҗасыз. Һәрбер тарихи кабер ташы хисапта булырга, җирле үзидарә аны кайгыртырга, югалган очракта җавап бирергә тиеш. Әтрәч авылында гына да күпме кабер ташы юкка чыккан...

Һичшиксез, юкка чыккан авыллар-

ның урыннарында истәлек билгесе куярга кирәк. Шунда ук авыл турында тарихи мәгълүмат язылсын, анда туган мәшһүр кешеләрнең исемнәре теркәлсен иде. Бу ни өчен кирәк? Дөнья хәлен белеп булмый: әгәр дә Европа илләренә барып карасаң, халыкның шәһәрдән авылга күчү хәрәкәте бара. Кеше барыбер зур шәһәрдән туячак, халык яңадан авылларга йөз тотачак. Авыл халкы мең яки биш йөз еллар элек бу урынны очраклы гына сайламаган. Ул – яшәр өчен иң кулай урын, аның суы, чишмәсе, урманы булган.

Рафаил Шәйдуллин. Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институтында юкка чыккан авылларны максатчан өйрәнү 2015 елда башланды. Татарстанда 1300-1400 авыл юкка чыккан. Хәзерге вакытта 300гә якын авыл юкка чыгу алдында тора. Аларда яшәүчеләрнең саны уннан ким. «Татарстанның югалган торак пунктлары» исемле җыентык – юкка чыккан авылларны барлауда беренче тәҗрибә. Бу авылларны өйрәнү аеруча авыр. Заманында Татарстанда 30 район була. Кайбер елларда 70кә җитә, аннан яңадан эреләндерәләр. Әгәр дә финанс күзлегеннән карасак, авыл советларын эреләндерүгә тотылган акчага күпме авылны саклап калып булыр иде.

Күмәкләштерү чорында бик күп татар авыллары барлыкка килә. 1950 нче елларда шул авылларны берләштерә башлыйлар. Н.Хрущев чорында перспективасыз булган авылларны бетерү сәясәтенә керешәләр. Аның бер максаты – авыл тормышын шәһәрнекенә якынлаштыру. Авыл кешесе үз җирен яхшы белә, кайда, нинди болын, аның сыйфаты – бар да аңа мәгълүм. Зур авыл барлыкка килсә, җирне белүче белгечләр азая, җиргә игътибар да кими.

Юкка чыккан бик күп авылларны «Татарстан Швейцариясе» дип әйтергә мөмкин. Әлбәттә, кечкенә авылларны «перспективасыз» дип санарга буладыр, әмма икътисади яктан караганда гына перспектива юк. Әгәр мәдәни, рухи яктан карасак... Авыллар – һәр кешенең, милләтнең бишеге. Милли мәдәниятне авылларсыз саклап кала алырбызмы?

Татарстанда шәһәр биләмәсенә кереп юкка чыккан авыллар программасы да кирәк. Россиядә 2012 елда кабул ителгән андый программа бар. Күпме авылларыбыз Казан эчендә калды?!

Без укыган вакытта, авыл мәктәбеннән 3-4 бала югары уку йортына керсә, бик әйбәт иде. Ә хәзер 99 %ы керә. Эшче һөнәрен сайлаучылар аз, техникумнар бетеп бара. Югары уку йортлары гына калды. Игенче, сыер савучы хезмәтенең дәрәҗәсе елдан-ел төшә бара.

Михаил Черепанов. Авыл юкка чыгу нәтиҗәсендә документлар, гаилә ядкярләре, музей предметлары тарала. Алар якындагы авыл яки район музейларына тапшырылмый.

Эзтабарлар фронтта хәбәрсез югалганнар, госпитальләрдә вафат булганнар турында шактый мәгълүмат таба. Әмма фронтовикның авылы юкка чыгу сәбәпле, бу турыда беркая да хәбәр итеп булмый. Күрше-тирә авыллар, район үзәгеннән аларның туган-тумачасын ничек табарга?

«Алар илгә Җиңү белән кайтты» исемле китапта исән калган орденлы батырларыбызның барысы да юк. Бу нәрсә дигән сүз? Безнең шактый каһарманнарыбызның авылы юкка чыгу, районнар эреләндерелеп, хәрби комиссариатларны кыскарту сәбәпле, аларның туган җирен күпләр белми.

Л.Лерон. Гариф Ахунов, Рөстәм Мингалим, Әзһәр Шакиров, Мансур

Вәлиев кебек мөхтәрәм шәхесләребезнең туган авылы бүген юк. Алар моңа бик сызландылар, авылым яңарыр, аңа яшәүчеләр кайтыр, дип гомер буе өметләнделәр, туктый торган бердәнбер урыннары, юанычы – чишмә иде.

Бронтой Бедюров. Авыл – безнең мирасыбыз. Авыл ул – тамырлар. Мегаполис, ягъни агач никадәр генә зур булмасын, аның тамыры корый икән, ул үлә. Үзәк Россиядәге рус авыллары совет чорында ук җимерелә башлады. Безне, студент, аспирант вакытта, Мәскәү яны авылларына эшкә җибәрәләр иде. Доцент, профессорлар, шәркыятьчеләр бәрәңге чүпләде, эшләргә колхозчы юк...

Татар авылына юкка чыгу куркынычы яный, дип уйламый идем. Кайда гына булсам да, Башкортстандамы, Оренбургтамы – кош-корты, терлек-туары булган авыл – татарныкы.

Агломерацияләр төзү, авыл халкын анда күчерү – акылсызлык. Киресенчә, миңа калса, кешелекнең киләчәге – авылда. Әйтерсең, безгә Япониядәге кебек җир җитми, авылларны юкка чыгарабыз...

Алтай Республикасында бер генә шәһәр дә юк. Башкалабыз Таулы Алтайны да зур авыл дияргә була. Соңгы елларда бер генә алтай авылы да юкка чыкмады, киресенчә, төзелә. Моңа В.В.Путин да гаҗәпләнде: күрше Алтай краенда авыллар үлә, ә бездә яңа йортлар төзелә, гаилә коралар. Дөрес, миллионер колхоз-совхозлар җимерелде, шулай да кешеләр югалып калмады. Хәзер шәхси хуҗалыкларда ат, мөгезле эре терлекнең саны арта.

Татарстанда буш җирләрдә нәселле атлар үрчетергә кирәк. Холестеринсыз ат итенә, казыга киләчәктә ихтыяҗ артачак. Мишәрләр – французларга яу белән барган халык, бик яхшы ат үрчетүчеләр.

Авыл проблемасы – социаль-икътисади проблема гына түгел. Бу – этник һәм милли проблема. Авылны саклау – туган телне, милли яшәү рәвешен, мәдәниятне саклау дигән сүз.

Мине рус халкының зәгыйфьләнүе бик борчый. Патша заманыннан ук берничә этапта булган индустриализация нәтиҗәсендә яшьләр авылдан китте. Шәһәрнең барак һәм фатирларында икедән артык бала үстереп булмый. Бүген үзбәк саны арта, дибез. Ә революциягә кадәр рус крестьяны гаиләсендә балалар саны үзбәкнекеннән күбрәк булган. Дөрес, Себердә рус авыллары бар, ә Үзәк Россиядә бетте, диярлек. Бу – фаҗига.

Татар авылындагы үрдәк-каз, малтуар – анда яшәүчеләрнең тырышлыгын күрсәтә. Татар халкының бу сыйфатын саклап калырга кирәк. Татарстанда татар авылының юкка чыгуы нормаль күренеш түгел.

Дамир Исхаков. Татарстан авылларында халыкның ¼ өлеше калды. Аларның да яртысы – пенсионерлар. 15 елдан соң, тууычылар аз булу сәбәпле, бу сан тагын да кимиячәк.

Без мәсьәләгә геосәясәт күзлегеннән карарга тиеш. Милли республика каркасын халыкның таралып утыру системасы хасил итә. Авыллар юк икән, республика була алмый, син шәһәр чыпчыгына әвереләсең. Яһүдләр, барысы да шәһәргә күчеп беткәч, җирсез яшәп булмаячагын аңлады. Һәр юкка чыккан бер авыл татар территориясен тарайта.

Соңгы елларда Мәскәүдәге зур олигарх балалары азык-төлекне Кытайга ташый башлады. Аларга киләчәктә җир кирәк булачак. Бүген Татарстан җирләре 7-8 аграр корпорация кулында. Аллага шөкер, җитәкчеләре – татар байлары.

Әмма алга таба татар җирендә башка хуҗалар да барлыкка килергә мөмкин. Мәскәү байлары Башкортстан белән кызыксына башлады инде.

Авыллар юкка чыгу, халык көчеше яңа күренеш түгел. Рязань янындагы Кадом өязендә XVIII гасыр башында 20гә якын татар авылы булган, XIX йөздә өч кенә авыл калган. 1983 елда Касыйм шәһәре янында шактый эре татар авылларын күрдем. Хәзер алар юк, күбесе дача булып тора. Ә юкка чыккан һәр авыл тарихи әһәмияткә ия. Шырын авылында Касыйм ханнарының карачы бәкләре Шириннәр урнашкан була. Алар шунда җәен ял иткән, игенчеләре яшәгән.

Биектауда Татар Алаты һәм Рус Алаты, Татар Әйшәсе һәм Рус Әйшәсе авыллары бар. Боларның «рус» дигәне кемнеке икән? Руслар элекке татар авылына килеп утырган булырга мөмкин. Ул бит эшкәртелгән, әзер җир, ә татарлар күчеп китәргә мәҗбүр булган. Заманында болар бик кызыклы тарихка ия татар авыллары булган.

Әйшә авылына бәйле янмый торган кыз турында дастан бар. Гали бәк һәм Алтын бәкнең сеңлесе Гайшә, Аксак Тимер тарафыннан әсир ителеп, Урта Азиягә киткән. Аксак Тимер улына хезмәт иткәннән соң, Гайшә бу якка кире кайтарыла, Иске Казанга, туганнары янына юл тота һәм аларның хәрби җитәкчесенә кияүгә чыга. Бүген дә, Гайшәбикәнең кабере изге урын дип санала. Димәк, хәзерге рус авылларын өйрәнә башласаң, күп очракта татар тарихы килеп чыга.

Казан тирәсендә дин әһелләренең, сәетләрнең җәй көне яши торган авыллары булган. Дәрвишләр, Кол Сәет – шундыйлардан. «Козья слобода» – бу һич кенә дә «Кәҗә бистәсе» түгел, ә «Хуҗалар авылы» дигән сүз. Хуҗа – сәетнең икенче варианты. Шәһәр эчендә калып юкка чыккан авылларны да тарихи җәһәттән өйрәнергә кирәк.

Эльмира Сәлахова. Авылларның юкка чыгуы экологик проблеманы да китереп чыгара. Чулман һәм башка сусаклагычлар астында калган авылларның зиратын һәм үләт каберлекләрен берәү дә исәпкә алмады. Бүген шул суны Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләре халкы эчә.

Арча районының атаклы Курса, Пошалым, Масра, Казиле, Мәтәскә кебек авылларында XX гасыр башына кадәр халык саны үсә. Мисал өчен, Югары Мәтәскәдә халыкның табигый үсеше 3,8% тәшкил итә. Совет чорында халык саны кимү процессы башлана.

Кәсеп-шөгыль, җитештерелгән продукциягә гадел ихтыяҗ булса, авылда халык яши, шунда мәктәбе, клубы да төзелә. Казан артындагы Күшәр, Оры авылларында кайчандыр эре сәнәгать оешмалары булган, халык шунда тупланган, авыллар гөрләп яшәгән. Ә хәзер аларның хәле мөшкел.

Татарның язылмаган кануннары бар. Бу да икътисад, милек белән бәйле. Һәр гаиләдә төпчек бала, телиме-теләмиме, ата-баба нигезен саклап калырга тиеш.

Р.Вәлиев. Без сигез бала үстек, төпчегебез туган нигездә калды.

Э.Сәлахова. Җыеннар күрше-тирә авылларның халкын бергә туплаган. Шунда кешеләр аралашкан, кызлар кияү йортына төшкән.

Бер авылда халык гөрләп яши. Ә күршедәге авылда кеше саны кими, хатын-кызлары хәмер эчә. Сәбәп нидә? Тикшерә башласак, бу авылларның килеп чыгышы төрле җирдән икәнлеге ачыклана.

Туган авылым Чәчкаптан дин тыелган вакытта да китмәделәр, качып-посып булса да намаз укыдылар, ураза тоттылар. Заманында күрше авыл ике мәртәбә зуррак булган, ул хәзер кечкенә, ә безнең Чәчкап – киресенчә, хәтта совет чорын-

да колхоз үзәге булып та торды. Халык саны кимүдән тамырны, нәселне таркатмау дигән нәрсә саклап калды.

Чукынырга мәҗбүр ителгән авыллар да шактый – һәр төбәкнең үз язмышы. Формаль чукындырылганнары да бар. Безнең авылда унлап гаилә чукындырылган, ләкин бу хакта беркем дә авыз ачып сүз әйтмәде, аларны берәү дә кимсетмәде. Әгәр дә без чукынганнарны кире каксак, гаепләсәк, таркату тактикасына күчәр идек. Кызганыч, шундыйларның ата-бабалары исеме мулла язган метрикаларга теркәлмәгән. Бу нәсел шәҗәрәсен өйрәнгәндә зур кыенлык тудыра.

А.Борһанов. Җыен үткәрү хәзер традициягә әйләнеп бара. Искер, Әтрәч, Чатыр-Тау җыеннары...

Марат Закир.

Безнең якларда исә – Мамадыш-Тәкәнеш-Кукмара якларында – элек Тукташ җыены булган. Әлеге җыенга егермеләп авыл халкы килеп, июнь аенда бәйрәм иткәннәр.

Э.Сәлахова. Традиция дип без гасырдан-гасырга күчкән күренешне атыйбыз. Ясалма булдырылганны халык бик кабул итеп бетерми, ләкин бу да кирәк. Хәзерге вакытта ясалма тудырылып, аның киләчәктә дәвамы булса – яхшы хәл.

Д.Исхаков. Җыеннар – халыкны туплау механизмы. Татар авылларында халык саны кимесә, күп авылларда бер-ике гаилә генә калырга мөмкин. Әмма аларны кирәк вакытта бергә туплый торган механизм булырга тиеш. Элекке җыеннар моделендә безгә таралган халыкны җыю юлларын эзләргә кирәк булачак. Татар гомер буе җәй айларында җәйләүгә чыккан. Бу – татарның канында. Шундый ук ысул белән җыеннарны кире кайтара алабыз. Моны ясалма рәвештә гамәлгә кертеп җибәрергә кирәк булачак.

Нәҗәт Нәгыймов.

Азнакайда юкка чыккан 36 авыл турында «Хәтер түрендәге авыллар» исемле китап чыгардык. Районның 70 еллыгына әзерләнгәндә, Азнакайдан сугышка ун меңгә якын ир-ат киткән, дип белә идек, эзләнүләр нәтиҗәсендә 15 мең кеше икәнлеге ачыкланды.

Фермер хуҗалыклары барлыкка килү белән, безнең өч авылда тормыш яңадан җанланды. Бетүгә дучар ителгән Кызыл Сукачы, Чалтаймас, Фрунзе кебек авыллар хәзер зураеп, үсеп килә. Аларда мәчетләр дә төзелде.

Зиратларны саклау, аларны койма белән әйләндереп алу, 124 чишмәне төзекләндерү кебек изге гамәлләрдә ярдәм иткәне өчен, форсаттан файдаланып, «Татнефть» ААҖнә зур рәхмәтемне белдерәм.

А.Борһанов. Дөрестән дә, Азнакай күп эшләрдә алда бара. Анда берничә экспедиция, конференция оештырылды, затлы музей ачылды. Район хакимияте башлыгы Марсель Шәйдуллин һәм аның командасы галимнәр белән бик актив эш алып бара. Биредә борынгы зиратларны, һәйкәлләрне саклауга игътибар гаять зур. Без Азнакай төбәгендә Алтын Урда чоры шәһәрчекләренең урынын таптык, Урсай авылында Нугай Урдасы заманыннан калган каберлекләр дә саклана. Чалпы авылында нугайбәкләр белән бәйле ядкярләр өйрәнелде.

Д.Исхаков. Татарстанның көнчыгыш районнарына халык XVIII гасырда гына күчкән, дип язарга яраталар, ә чынбарлыкта бу җирләр Нугай Урдасы территориясенә кергән. Нугайлар ярым күчмә тормышта көн күреп, көннәр җылыткач, җәйләүгә чыккан. Әгәр дә кайбер төбәкләрдә утрак авылны шунда ук тапмасак, биредә татар яшәмәгән, дигән сүз түгел. Ул күчмә яки ярым

кучмә тормыш алып барган булырга мөмкин. Һәрбер татар да утрак булмаган.

Рабит Хәсәнов. Авылларны күтәрү өчен халык санын арттыру кирәк. Кичә Әлмәтнең онкология хастаханәсендә булдым. Шунда бер-ике авыру карт утыра, ә калганнары – яшьләр. Яшьләрнең тудыру сәләте елдан-ел начарая. Авыл, халык саны турында уйлыйбыз икән, азык-төлекнең сыйфаты беренче планда булырга тиеш. Ризык аша халыкны яшерен рәвештә бетерү процессы бара. Әгәр дә ашый торган азыгыбызның сыйфатын катгый контрольгә алмасак, бернинди программа да ярдәм итмәячәк.

Фәрит Нәбиуллин. Татар халкы дөньяга атлары белән танылган. Дөрестән дә, җәйләүгә чыгулар, җыеннар безнең Бөгелмә якларында да булган. Әмма совет чорында бер җыенга кергән авылларны өч районга бүлделәр: Бөгелмә, Зәй һәм Әлмәт. Административ үзәкләр төрле булгач, алар хәзер тиз генә җыела алмаячак.

Без һәр җәйне кымыз бәйрәме оештыра башладык, ә язын татар атлары бәйгесен уздырабыз. Шундый бәйгеләрне һәр елны бер районда үткәрсәк, яхшы булыр иде. Татар токымлы ат гарәп атыннан һич кенә дә ким түгел. Ул – аңа караганда кечерәк, чыдамрак, кулга да яхшырак иярләшә, дала шартларында азыкны да тибенеп табарга сәләтле. Шунлыктан, авыл балалары татар аты белән ныграк кызыксына алыр иде. Хәрәкәт тәнне ныгытса, төрле бәйгеләрдә җиңү горурлык хисен тәрбияли.

Рөстәм Әминов. Дайверлар сусаклагыч астында калган авыллардагы чиркәү һәм мәчет урыннарын билгеләп, ярга стелалар куя. Без дә, бу авылларның урынын билгеләп, яр буена тамгалар куйсак, яхшы булыр иде.

Татар казак авыллары Яңа Әбләз, Яңа Зубачи, Югары Зубачи халкы рус авылларына күчерелде. Оренбург һәм Чиләбе өлкәләрендә шундый авыллар бихисап.

М.Закир. Заманында Каюм Галимулла улы Галимуллин (классик шагыйребез Шәйхи Маннурның якын туганы) юкка чыккан авыл, басу-кыр, әрәмә, елга, күл һәм чишмә исемнәрен (86 атама!) теркәп калдырган. Бу исемлек тә, истәлекләре дә гаҗәеп кызыклы, гыйбрәтле. Кульязма китапны миңа аның кызы Наилә апа тапшырды.

Таһир Габдрахманов. Һәр авылда хөкүмәт дәрәҗәсендә шәҗәрә бәйрәмнәрен үткәрергә кирәк. Мондый чараларда шул авылның «ревизская сказка» һәм метрика кенәгәләренең күчерелмәләре таратылса, һәркем үз нәсел-нәсәбе белән кызыксына башларга мөмкин.

Л.Лерон. Максатыбыз – изге. Мондагы фикер-тәкъдимнәр, хыял гына булып калмыйча, чынбарлыкка әйләнсен иде. Авылларыбыз исән-сау булсын! Авыл булса, милләт яши.

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2017

МУСА АВЫЛЫ ТАРИХЫ

«Тарихыбыз ул – халык, ата-бабаларыбызның тормыш күренеше, ил, туган як язмышы. Без – тарихны ясаучылар, ә тарих, үз чиратында, иҗтимагый үсешнең һәр этабында, социаль-икътисади формация буларак, киләчәкнең көзгесе, безнең нигезебез булып санала. Шуңа да без тарихка аеруча сак, төгәл мөнәсәбәттә булырга тиеш. Оныкларыбыз каршындагы җаваплылык ул – үткәнебезне, бүгенгебезне киләсе буынга тапшыра алуда».

Кулаткы муниципаль районы җитәкчесе, академик Эдуард Ганеев

«Гомумән алганда, Муса (Мосеевка) авылы кебек торак пунктлар Россия җирендә йөз меңләгән. Аларның тарихы да берникадәр охшаш, чөнки һәркайсы бер үк җәмгыятьтә яшәп, бер үк эволюция юлын үткән. Ләкин Муса авылы хәтта Иске Кулаткы районы җирлегендә генә дә үзенчәлекле авыл: биредә яшәүче халыкның тормыш корышы, күзаллавы башкачарак, төплерәк. Монда XX гасыр башында инде гончар трубалар көйләп, махсус коелар булдырып, агымсу белән сууткәргеч ясаганнар, монда әллә ничә дистә ел уңдырышсыз җирләрдә дә сокланырлык уңыш алганнар. Биредә беренче булып һәр өйгә табигый газ кертәләр. Бу авылның үз герое, үз галиме, сокланырлык хезмәт батырлары бар. Элек гөрләп торган Киров исемендәге колхоз рәисе К.М.Әхтәмов коммунистлар партиясенең (ул вакытта җитәкче партия) XXVI съезды делегаты итеп сайланган. Муса (Мосеевка) егете Фатих Юныс улы Динеев Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен I, II, III дәрәҗәдә Дан орденнары белән бүләкләнеп, аның тулы кавалеры булган, дөньялар үзгәреп, ил экономикасы яңа рельсларга бастырылгач, авылда Ришат Хәбибуллин беренче булып крестьян-фермер хуҗалыгы оештырган. Нинди генә тормышны алма, аның үз батырын, танылган кешесен атарга мөмкин. Иң

авыр вакытларда да, төрле үзгәрешләр чорында да мусалылар сынып төшмәде, югалып калмады. Биредә авыл гөрләп яши, кырлар чәчелә, фермада сыерлар мөгрәве ишетелә, балалар мәктәпкә шау-гөр килеп йөри, күңелләргә илаһи нур өстәп, яңа мәчеттән азан тавышы яңгырый. Тормыш дәвам итә. Киләчәге аның тагын да матуррак, тагын да сокландыргычрак булсын иде», – дип язып үтә академик Эдуард Әнвәр улы Ганеев «Муса авылы тарихы»дигән китапка кереш сүзендә. (Басманың авторы – Нурҗиһан Әхмәтша кызы Арсланова. Ул – үз авылы, аның кешеләре турында күп санлы мәкаләләр, очерклар язган шәхес. Әлеге китап 2012 елда дөнья күрә.)

Алдагы сүземнең агышы да ошбу китаптагы белешмәләргә таянып дәвам итәчәк. Чөнки мин бу төбәкнең кешеләрен барып күргән, алар белән аралашып йөргән кеше.

«Нәсел тамырларын, яшәгән төбәгеңнең тарихын белү, аларны буыннар өчен тарихка кертеп калдыру – изге эш ул... Авылымның үткәне, бүгенгесе, шәхесләре белән кызыксына торгач, аның тарихын язарга алындым. Кайбер сакланып калган архив материалларын, авыздан-авызга сөйләнеп сакланып килгән мәгълүматларны, олы яшьтәге картларның истәлекләрен дә җыеп кулландым. Әлеге мәгълүматларны туплаганда, истәлекләрне саклаган укымышлы картларның кайберләре исән иде әле, алар бик нык ярдәм иттеләр. Авылымның аксакаллары – Алиулла Шәмсетдин улы Мөхәммәтов (1883-1967); Усман Бакый улы Хисаметдинов (Суфи бабай дияләр иде), (1890-1981); Исхак Абдрахман улы Мәһдиев (Кара Исхак, 1889-1970); Искәндәр Усман улы Алиев (Кафтай, 1895-1981); Якуб Идрис улы Кузахметов (1897-1980); Кузахметов Җиһанша Хәбибулла улы (1899-1979); Мөбин Әббәс улы Аввәсов (1899-1975). Югарыда күрсәтелгән авыл картларының сөйләүләре буенча, Муса авылына нигез салынуга 450 еллар чамасы булырга тиеш. Исхак бабай Мәһдиев үзенең борынгы бабалары

1973-1975 елларда Муса сигезьеллык мәктәбе директоры булып эшләгән Әнвәр Исхак улы Ганеев шушы авыл кызы Сафия ханым белән тормыш кора

Мәгди кавеме турында, Алатырь ягыннан күчеп килгәннәр, дия иде. Беренче төпләнгән урыннары Әмәләктә булган (Муса юлына чыгып китә торган урам). Беренче төзелгән өйләрнең берсе – без белгән Закир Мөхәммәтҗан улы Мәһдиевнең йорты (Рахметова Саерфур апаларга каршы якта) Әмәләк урамында 1925-1930 елларда 18 йорт булса, 1967 елда 3кә генә кала. Муса авылына нигез салыну вакыты турында төгәл генә мәгълүматлар юк. Гомумән, бу якларга күчеп утыру Казан, Әстерхан ханлыклары басып алынгач башлана. Патшаның комсыз түрәләренең талауларына, милли-дини кысрыклауларга түзә алмыйча, бирегә Казан губернасында элек-электән яшәгән мордвалар, татарлар, чуашлар, марилар качып килгән. Авылга нигез салучылар арасында татарлар да, чуашлар да бик күп булган. Чөнки чуаш төпләре дә авыл җирлегендә сакланып калган. Аббас Кәмалләре (чуаш төпләре буларак, «Сава»кушаматын йөрткәннәр), шулай ук Хәсәнов Фазыллар да шул халыктан. Авылга нигез салучыларның берсе Муса бабабыз да чуаш төпкеленнән булган, имеш. Барысын да Алиулла ба-

бай Мөхәммәтов сөйләгәннәргә таянып яздым.

...Атлаш юлы авылга керүгә югарырак һәм һәрвакыт сазлы, баткаклырак булган, ат белән йөрүчеләргә бу җирлекләр яңгырлы вакытта бер газапка әйләнгән. Соңыннан, бу сазлы урынга 1,5 км аралыкта таш түшәп юл салганнар. Юлны ясаганда чуаш каберлекләре дә чыккан, дип, телдән-телгә сөйләнеп килә. Татарлар күбәеп, нишләп чуашлар азая барган соң? Чөнки алар, бер диндә, бер үк телдә аралаша торгач, татарлар белән кушылып бер халыкка әйләнеп беткәннәр, күрәсең. Элек, без яши торган урыннар котырып үскән катнаш урманнар белән капланган була. Биредәге урыннар биләүсез саналганлыктан, беркемгә дә буйсынмаганнар. Бу урынга килеп урнашкан кешеләрне дә куе урманнар үз куенына яшергән, уңдырышсыз җирләр күп булса да, яшәргә мөмкинлек биргән. Налог түләмәгәч, терлек, умартачылык, игенчелек белән шөгыльләнеп тернәкләнеп киткәннәр. Әйтүләре буенча, Муса бабай җитәкчелегендә пар атларда Избалык елгасы буендагы үзәнлеккә башта 7 ир-ат килеп төшкән. Муса шунда урман уртасындагы агачлыкка межа сызып, җир бүлеп алганнар. Урман күп булгач, тырыш татар халкы өйләрен дә бик тиз торгызган. Алар нинди булгандыр, күп еллар үтү сәбәпле, билгесез. Үзләренең качкыннар (казаклар) икәнлекләрен исәпкә алсак, җиргә сеңдеребрәк, яшеренебрәк салынганнардыр. Бу тирәдәге башка салалар да качаклардан (казаклар) торганга «ирекле» берләшмә булып гомер сөргәннәр. 1700 елларда гына башлап 30 хуҗалыкның ясак түләгәнлеге билгеле. Салымны Андреевка авылыннан рус кешесе килеп җыйган. Бу чорларда җирләр, димәк, исәпкә алынган, хөкүмәт тарафыннан ревизия ясала башлаган. Авыллар арасында җиргә кытлык булу сәбәпле, бәрелешләр, гаугалар да чыккалаган. Үзәктәге закон нигезендә, барлыгы 3 ревизия ясалган. Шуларның иң беренчесе 1718-1724 елларда оештырылган. Ир-атларның саны да исәпкә алына, чөнки җирләрне ирләргә генә бүлеп биргәннәр. Соңрак, 1861 елдан (крепостное право) бетерелгәч, җирләр җәмәгать милкенә күчә, авыл халкы үзе бүлә башлый. Бу хәл 12 ел саен кабатланган. Саратов дәүләт архивында да сакланган материаллар нигезендә, безнең җирләр Хвалын өязенә кергән, «кыргый кырлар» дип аталган. Петр I патша 1703-1714 елларда, Россиянең көньяк чикләрен ныгыту максатыннан чыгып, Хвалын өязендәге буш җирләргә кешеләрне, төрле вәгъдәләр биреп, күчереп утырта. Аларның да күпчелеге Төмән, Тамбов, Казан якларында яшәүче «служилый»татар кешеләре була. Шулай ук крепостной, дини изелүдән дә качкан мордва, чуаш, татар халыклары да бу төркемнәрне хасил итә. 1804 елда инде Хвалын өязендә барлыгы 95 авыл саналган, шуларның 25е – чип-чиста татар авыллары. Барысы да Саратов өлкәсенә кергән.

МӘЧЕТЛӘР

XVIII гасырның икенче яртысында (1766), Екатерина II указы нигезендә, мөселманнарга мәчетләр һәм алар каршында мәдрәсәләр төзергә рөхсәт бирелә. 1789 елның 4 декабреннән, ислам динендәгеләргә олуг шатлык китереп, Уфа шәһәрендә мөселманнарның Дини идарәсе эшли башлый. Муса җирлегенә килгәндә, беренче мәчет урталыкта, хәзерге яңа мәчет урынында 1789-1790 елларда ук төзелгән булырга тиеш. Манарасы әллә ни биек булмаган зур гыйбадәтханә салынган. Иң беренчеләрдән Сөләйман, Аббәс, соңрак аның кияве Җани муллалар иман биргән. 1813 елда Мусада мәдрәсәгә хәтле эшли башлаган. Аббас хәзрәт үзәктә дә 3 мәдрәсә төзеткән. Бабасы Юныс хәзрәттән калган байлыгын уку йортлары салдырырга кулланган. Заманына күрә бик галим кеше булган Аббас хәзрәт, шул ук мәдрәсәләрдә шәкертләр укыткан. Чит төбәкләрдән дә укырга килгәннәр, димәк, торып белем алыр өчен бөтен мөмкинлекләр дә булган

биредә. Алиулла бабайның сөйләве буенча, 1821 елны Пенза өлкәсендә булганда, Евлашево авылында 75 яшьлек карт белән очраша. Ул бабасының Муса авылы мәдрәсәсендә белем алганын әйтә. Мәдрәсә артында зур күл булган, шәкертләр яз көнендә госелләнергә, тәһарәт алырга чыга торган булалар. Зимницадагы ишан Хәбибулла Хансаеров хәзрәт тә (1805-1897) безнең авылда Аббәс хәзрәт мәдрәсәсендә 3 ел белем эстәгән. Хәбибулла башлангыч сабакны туган авылында алган булса да, төплерәк белем бирүче уку йортына этисе Хансөяр илтеп тапшыра. Укуны дәвам итәр өчен, Аббәс хәзрәт талантлы шәкертен үзе укыган Чистай өязе мәдрәсәсенә бирергә киңәш итә. Ризаэддин хәзрәт Фәхреддинов үзенең «Асар»ендә бу шәхеснең тулы исемен Аббәс бин Абдер-Рафига бин Юнес бин Кучар дип күрсәтә. Аббәс хәзрәтнең үз кулы белән язылган атамасында этисенең исеме, мөнәҗәтендә әйтелгәнчә, Рафик дип язылган. 3 мәдрәсә тоткан, анда бик күп шәкертләр тәрбияләгән олуг мөгаллимне дәмулла (зур, олы мулла) дип, зурлап йөрткәннәр. Аббәс дәмулла бик таләпчән була, шәкертләренә хәтта ашаганда да иркенләп, җәелеп утырырга бирми. Бу олы затның атасы, хәлле кеше буларак, һәр җомга, ат арбасына төяп, шәкертләргә ризык китереп өләшә, ашата. Мөфти Риза казыйның билгеләп үтүенчә, Аббәс мулланың бай китапханәсе һәм анда үзе язган әсәрләре дә бик күп булган, ни кызганыч, болар барысы да янгында калып юкка чыккан. Аббәс хәзрәтнең гомере озын булмый. Ул 49 яшендә бакыйлыкка күчә. Җәсәде югары очтагы каберлектә саклана. Мәрхүмнең кабере өстенә, хөрмәт йөзеннән, шәкертләре 7 чакрым ераклыктан носилка белән күтәреп зур таш китереп куйганнар. Мәрхүм Искәндәр Усман улы Алиевка (Кафтай бабайга) һәм мәрхүм Искәндәр Идрис улы Кузахметовка бик зур рәхмәт! Алар 1971 елда Аббәс хәзрәтнең кабере өстенә зур тимер челтәр ясатып куйганнар. Бу бабайлар Дәүләтша Шәрибҗан улы Кузаевка (1927-2007), Аббәс хәзрәтнең каберен онытма, дип, әйтеп калдырганнар. Дәүләтша бабайның сөйләве буенча, шул ук мәрхәмәтле картлар Атлаш юлындагы мәрхүм Яхъя каберенә һәм Павловка юлындагы Әүлия каберенә дә тимердән челтәрләр ясатып куйдырган булганнар икән. Зур рәхмәт аларга!

1790 елда төзелгән мәчет урынында, 1863 елда биек манаралы бик зур мәчет – урталык мәчете аякка баса. Элеккеге бина мәдрәсә булып кала. Икенче – Түбән оч мәчете 1894 елда төзелә. Янәшәсендә 30-35 урынлы зур тәрәзәләре балкып торган тагын бер мәдрәсә күтәртелә. Өченче – Югары оч мәчете 1898 елда торгызыла һәм, әлбәттә, янәшәсендә тагын бер мәдрәсә калка.

Хатын-кызларга килгәндә, алар дин гыйлемен белүче абыстайларның өйләренә йөреп, Коръән сүрәләрен һәм намаз укырга өйрәнгәннәр. Әниемнең әйтүенчә, Түбән очта яшәүче Шәрәй әбигә һәм Мәликә Әхмәт кызы Әхтәмовага укырга йөргәннәр. 1912 елда дини мәктәп-мәдрәсә кызлар төркеме өчен дә төзелгән. 35-40 урынлы, бик зур, якты, түбәсе калай белән ябылган, затлы бина була ул. Бу мәктәпне Сафа мулла Мәхмүтовның каенатасы Хәсән бай төзеткән, үзе ул Уральскида яшәгән. Мәдрәсә Сафа мулланың өе каршында күтәрелгән. Кызларны бу чорда Муса авылының Саҗи бай кызлары Камилә белән Хәдичә, яшь абыстайлар укыткан. Әнием Әминә Үмәр кызы Арсланова (Насыйрова, 1899-1993) сөйләвенчә, мәктәпкә чит салалардан килүчеләр биредә торып сабак алганнар. Алар өйләренә ял көннәрендә генә кайтып йөргәннәр. Яшәр өчен мәдрәсә-интернатта бөтен мөмкинлекләр дә булган. Әнием 1913-1915 елларда биредә белем ала, 2 сыйныфны Мактау кәгазе белән тәмамласа да, укуын дәвам итәргә эти-әнисе риза булмый. Бу чакта мәдрәсә укуына арифметика, география, татар телләре дә керә башлаган. 1918-1919 елларда кызлар мәдрәсәсе беренче совет мәктәбенә әйләнә. 1935-1936 ел-

ларда гына яңа мәктәп салынып, үзенең ишекләрен ача.

Инкыйлабка кадәр һәр мәхәллә, һәр мәчет балалар тууын, никахлашуны һәм вафат булучыларны да терки барган. ЗАГСларда ул китаплар бүген дә саклана. Ахырдагы авылым муллаларының исем-фамилияләрен атап үтәм:

– Түбән оч мәчете мулласы – Зариф Усман улы Мәхмүдов, 1858 елда туган, 1930 елда раскулачивать ителеп, 5 елга төньякка сөрелгән, өе колхозга калган, мал-мөлкәте конфисковать ителгән. 1937 елда срогын тутырып исән-сау кайтса да, озак тормый вафат була, авылда җирләнгән.

– Түбән оч азанчысы – Хәзән Атаула улы Диниев, 1863 елда туган, 1937дә, «тройка» карары белән гаепләнеп, атып үтерелә.

– Урталык мәчете мулласы – Сафа Усман улы Мәхмүдов, 1862 елда дөньяга килә, раскулачивать ителеп, авылдан куыла. Аның өендә 1930-1954 елларда Муса (Мосеевка) авыл советы урнашкан булса, 1955 елдан алып 1970 елга кадәр – авыл китапханәсе. Ахырда колхоз, фатир иттереп, Ирек Тәүфыйк улы Әхтәмовка бирәләр.

– Урталык мәчете азанчысы – Мәхмүдов Шакир Усман улы, 1860 елда туган, авылдан куыла, мал-мөлкәте, өе тартып алына, колхозга бирелә, фатир булып тора. 1946 елда бу өй Советлар Союзы Герое хатыны Таибә апа Хөсәеновага бушлай бирелә. Ул берничә ел торганнан соң, өйне сатып, туган авылы Евлейкага күчеп китә.

– Югары оч мәчете мулласы –Мәҗит Хәбибулла улы Мәхмүдов, 1874 елда туган. Авылдан куыла, өе колхозга бирелә, Закир Шабеев гаиләсе шунда тора.

– Бу мәчеттә азанчы булып Рамазан Камалетдин ага торган. Ул 1860 елда туган. 30 нчы елларда, гаиләсен алып, Чатыртауга күчеп китә.

Революциядән соң дини укытулар тыелуга карамастан, авылыбыз кешеләре, яшерен рәвештә булса да, дин буенча укуларын дәвам итәргә тырышалар. Шундыйларның берсе – безнең якташыбыз – электро-механика фәннәре докторы, хәйрияче Эдуард Әнвәр улы Ганеевнең әбисе дәресләр биргән. Мәликә әби 1894 елда туган, беренче дини сабакларны Хәсән әбидә алган. Абыстай ул чактагы үсмер кызларга гарәп хәрефләре белән укырга-язарга, догалар, намаз укырга өйрәткән. Мәликә әби дә шыпырт кына кызларга өендә белем биргән. Абыстайны эзәрлекли башлыйлар, 1933 елда өенә берничә мәртәбә тентү белән киләләр. Мәликә апа укучы кызларын мич астына, идән астына качыра торган була. Аны авыл советына чакыртып, озак кына ябып та тотканнар. «Дин буенча укытуыңны ташламасаң, сөргенгә озатабыз», – дип тә куркытканнар».

Кулаткыда яшәүче татар халкы бүгенге көндә дә яңа бер дини, милли күтәрелеш кичерә. Үткән 2016 елны без бер төркем язучылар Ленар Гобәйдуллин, Хәбир Ибраһимов һәм мин Кулаткы районы белән танышып йөрдек. Район җитәкчесе безгә, үзенең машинасын биреп, изгеләр каберләрен, кайбер авылларны күреп, аларның кешеләре белән дә аралышып кайттык! Район җитәкчесе Эдуард Әнвәр улы белән дә әңгәмә кордык. Аның кайбер фикерләрен сезгә дә җиткерәм: «Татар милләтен саклап калуда ике төп фактор – дин һәм мәгариф төп рольне уйный. Милли аңны уятуда тарихыңны, мәдәният-сәнгатеңне, мирасыңны яшь буынга тапшыра бару, балаларны ана телендә укыту ул – зур роль уйный, иң зур тәрбия чараларының берсе». Шуны да искәртеп китәсем килә: Эдуард Әнвәр улы – үз төбәгендәге мәчетләрне аякка бастырган шәхес.

Материал Нурҗиһан Арслановaның «Муса авылы тарихы» дигән китабына нигезләнеп әзерләнде. ■

ГАЛӘМИ УЙЛЫ ТАТАР УЛЫ

Айдар Хәмзин

Безнең Ташлык авылыннан (Түбән Кама районы) бик күп танылган шәхесләр чыккан. Алар арасында Дәүләт Советы депутаты, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, җырчы, язучы, мәзәкче, композитор, конферансье Алмаз Хәмзин, ветераннар арасында самбо буенча күп мәртәбә дөнья чемпионы Кираметдин Кәлимуллин, шагыйрьләр Мөслах Таҗи, Рафис Хисами, Татарстанның атказанган терлекчеләре Гиная Хәкимова, Мәнүсә Бәдретдинова, Зәки Шакиров, Әхмәдулла Насыйбуллин, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гаиф Хәкимов, Татарстанның атказанган механизаторы Миңнефаяз Борһанов, Татарстанның атказанган икътисадчысы Габделбәр Фәйзуллин, Татарстанның атказанган химигы Гамил Гайфетдинов, Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре Финә Хәмзина, Россиянең атказанган укытучысы Рәкыя Һадиуллина, унике бала тәрбияләп үстергән «Каһарман-ана» Нәзиһә Мөхәммәтшина, гер күтәрү буенча ике тапкыр дөнья чемпионы Фаил Хәсәнҗанов кебек затларны телгә алмый мөмкин түгел, ә орден-медаль ияләрен санап чыгар өчен генә дә берничә бит кәгазь кирәк булыр иде.

Ташлык авылы күренеше

Ләкин алда санап кителгән шәхесләр арасына кермәгән, исеме киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган тагын бер бик данлыклы авылдашыбыз бар әле безнең, ул – галәми эзләнүләр өлкәсендәге эшләре өчен СССР Дәүләт премиясе лауреаты булган Рәфкать Нури улы Вәлиев. Гаҗәп: аның турында без – авылдашлары да – һични белми идек. Беренче хәбәр бу елның гыйнвар аенда гына килеп иреште. Ни өчен шундый зур дәрәҗәләре була торып та, аның турында беркайда мәгълүмат юк соң?

Авыл тарихы белән кызыксынучы кеше буларак, бу сорау җаныма тынгылык бирмәде һәм мин ныклап торып Рәфкать Вәлиев язмышы белән кызыксына башладым. Иң элек Рәфкать абый турында тәүге сүзне ирештергән Рамил абый Нурмөхәммәтов белән очрашып сөйләштем. Аның сүзләренә караганда, Рәфкать абыйны белмәвебез һич шаккатырлык түгел, чөнки ул – үтә тыйнак, тыныч кеше икән. Үзе өчен беркайчан да берни дә сорап йөрмәгән, беркемгә дә ялына белмәгән... Бүгенге көндә дә җәмәгате белән бергә Уфада, бер бүлмәле фатирда гомер кичерә. Телефон аша элемтәгә чыктым. Чыннан да, үзе, бигрәк тә заводта эшләгән еллары турында сөйләргә ашыкмады, киресенчә, күбрәк авыл хәлләре белән кызыксынды. Минем «Наил малае» икәнлегемне белгәч, Рәфкать абый:

– Наил абый авылыбызның яме иде, аның белән бер сөйләшеп утыру үзе бер гомер иде, – дип куйды. Авылда күренекле якташыбыз белән очрашу оештырырга теләк барын ишеткәч, табибларның ерак юлга чыгарга киңәш итмәвен әйтте.

Шулай да, кем соң ул – күренекле якташыбыз? Нәрсәләр эшләгән?

***

Рәфкать Нури улы Вәлиев 1931 елның 15 октябрендә Татарстан Республикасының Ширәмәт районы Ташлык авылында туган. Бирелә – башлангыч, аннары Шәңгәлче җидееллык мәктәбендә урта белем алган. Мәктәптә укыганда ук математика, физика фәннәрен үз иткән. Сугыш чоры баласы буларак, кечкенәдән тормышның бөтен ачысын-төчесен татыган; яшьтәшләре сыман, ул да колхоз эшенә йөргән, хуҗалыкта әти-әнисенә булышкан.

Рәфкать Вәлиев

Балачакта кызыклы да, кызганыч та хәлләр баштан аз узамыни?!

Бер елны печән әзерләгән вакытта Түбән оч әртиле күлгә тап була. Күл, дип... Зәй елгасы ташып ярларына кире кайткан арада иңкүлекләрдә «качып» калган сулыклар инде ул, дөресе. Шунда балыклар бихисап. Әртил малайлары күлгә кереп суны болгаталар, ә миңгерәүләнгән балык өскә күтәрелүгә, аны җәт кенә тотып, коры җиргә аталар. Зурракларына сәнәк кадыйлар, балта белән сугалар. Малай-шалай арасында сугыш ветераны Сәхби абый Әхмәдиев тә бар. Оста балыкчы буларак, ул сай гына бер урында бик зур сазанны эләктереп ала:

– Балтаңны тотып, чап җәтрәк, Рәфкать җаный, – ди ул янәшәдәге малайга. Тегесе балтаны күтәреп сазанга кизәнә. Әмма... әллә аягы таеп китә, әллә сазан кузгала, Рәфкатьнең балтасы Сәхби абыйның су эчендәге кулына килеп төшә. Авыртудан, балыкчы кычкырып җибәрә. Ләкин барыбер сазанны ычкындырмый. Бу вакыйганың шаһитлары Сәхби абыйның шактый вакыт кулын бәйләп, муенына асып йөргәнен сөйлиләр.

...1945 елда Шәңгәлче мәктәбен тәмамлаган җиде укучы белән бергә Рәфкать тә Алабуга педагогика көллиятенә юнәлә. Имтихан алган Иванов фамилияле укытучы Рәфкать Вәлиев белән Динә Хәмзинаның укырга керүен әйтә, аннары: «Ә калганнар таякка таянып өйләренә кайтып китәчәк», – дип өсти. Баксаң, болары имтиханны «берле»гә тапшырган икән.

Ул елны көллияткә кырыгышар укучыдан торган дүрт төркем җыела. Сугыштан соңгы авыр еллар, ачлык-ялангачлык, бик күпләр, мондый шартларга чыдый алмыйча, укуны ташларга мәҗбүр була. Чыгарылышка егермешәр укучыдан торган ике генә төркем барып җитә.

Көллиятне уңышлы тәмамлаган Рәфкать исә Алабуга институтының физика-математика факультетына укырга керә.

Соңыннан, 1950-1951 елларда, Мамадыш районының бер мәктәбендә физика-математика укытучысы булып эшли.

Армиядән кайткач, Казан авиация институтының приборлар төзү факультетына укырга керә, 1962 елда аны да тәмамлый. Шуннан алып, 1992 елга кадәр Уфа авиация приборлары төзү заводында инженер, инженер-конструктор, конструкторлык бюросы җитәкчесе, баш конструктор ярдәмчесе, баш конструктор булып эшли. Аның җитәкчелегендә заводта «Восток», «Восход», «Союз» галәм кораблары, «Салют», «Мир» орбита станцияләре һәм «Прогресс» йөк-транспорт кораблары өчен исәп җайланмалары җитештерелә.

Галәми эзләнүләр өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Рәфкать Нури улы Вәлиевкә 1981 елда СССР Дәүләт премиясе бирелә.

Рәфкать абый ике малай үстерә: икесе дә югары белемле, зурысы Уфа авиация институтын тәмамлаган. Кечесе Уфа вертолет көллиятендә укып хәрби очучы булган. Икесе дә гаиләле, икесе дә кыз бала үстерә.

Авылдашыбыз 1993 елда лаеклы ялга чыга.

***

Уфа приборлар төзү заводы турындагы китапта (2006 елда дөнья күргән) Рәфкать Вәлиевнең дә истәлекләре урын алган: «1962 елның 15 апрелендә мин, Казан авиация институтын тәмамлап, заводка килдем. Мине «Ритм», «Гранит» приборлары һәм вакыт исәпләү җайланмасы өчен җаваплы итеп куйдылар. Космос җиһазларының сыйфатына карата таләпләр катгый иде. Көйләүче гаебе белән яраксызга чыккан деталь өчен эшчене шунда ук башка төр эшләнмәләр җитештерү бүлегенә күчерәләр. Гади хезмәткәрләрдән алып директорга кадәр һәркем үз эшенә җитди, җаваплы карады. Чөнки кечкенә җитешсезлек тә куелган мөһим максатларны үтәүгә киртә булырга, зур һәлакәтләргә китерергә мөмкин иде».

Шушы ук елны «Энергия» ракета-галәм предприятиесе, Уфа заводының «Восход» корабларына «ЗКВ» һәм «ЗКД» блокларын җитештерүдә ярдәм итүен сорап, СССР Авиация министрлыгына мөрәҗәгать итә. Министрлык бик авырлык белән генә ризалаша, чөнки заводның заказы болай да гаять күп була. Ләкин каршы килү дә мөмкин түгел: галәм техникасы җитештерүне СССР Министрлар Советы рәисе урынбасары, булачак СССР Оборона министры Д.Ф.Устинов үзе җитәкли.

Җитештереләсе комплектларга ун-

ПОСТАНОВЛЕНИЕМ ЦЕНТРАЛЬНОГО КОМИТЕТА КПСС
И СОВЕТА МИНИСТРОВ СОЮЗА ССР
от 29 декабря 1981 года
ПРИСУЖДЕНА
ГОСУДАРСТВЕННАЯ ПРЕМИЯ СССР
ВАЛЕЕВУ
Рафкату Нуриевичу —
за работу в области космических исследований.

№ 11240

Председатель Комитета по Ленинским и Государственным премиям СССР в области науки и техники при Совете Министров СССР
(А. АЛЕКСАНДРОВ)

Ученый секретарь Комитета по Ленинским и Государственным премиям СССР в области науки и техники при Совете Министров СССР
(Н. АРЖАНИКОВ)

МОСКВА

биш төр исемдәге җиһаз керә, башлыча алар – өзеп ялгагыч (коммутация) әсбаплары. Завод тиз арада бу заказны үти, элеккеге җиһазлар белән чагыштырганда, болары кечкенә күләмдә булуы белән аерылып тора. Беренче комплект пилотсыз эксперименталь «Восход-3КВ» корабында кулланыла.

...Дүртенче комплектны 1965 елның 18 мартында космонавтлар Павел Беляев һәм Алексей Леонов идарә иткән «Восход-3КД» корабына урнаштыралар. Кораб Җир шарын икенче тапкыр әйләнгәндә Алексей Леонов, тарихта иң беренче кеше булып, ачык галәмгә чыга. «Сәфәр» уналты минут дәвам итә. Корабка кергәндә күңелсезлек туа: скафандрның вакуумда зураюы сәбәпле, космонавт озак вакыт корабка керә алмый изалана. Ләкин мәшәкатьләр моның белән генә бетми әле... Җиргә кайтыр алдыннан корабның кояшка карап ориентлаша торган автомат системасы ватыла. Җир шарын тагын ике тапкыр урап чыгарга туры килә. Космонавтлар корабны кояшка карап «кулдан гына» ориентлаштыралар һәм двигательнең тормозын кушалар. Рәфкать Вәлиев бу вакыйганы, космонавтика тарихында иң драматик очыш, дип искә ала.

Алга таба яңа эшләр эшләнә, яңа үрләр алына...

***

Татарлар арасында бер генә космонавтның да булмавы кызганыч, әлбәттә. Әмма галәм кораблары, космонавтлар өчен борт компьютерлары, коммутация җиһазлары, электр кырынгычлары һәм башка бик күптөрле җайланмалар эшләүдә катнашкан Рәфкать Нури улы Вәлиевебез бар! Без аның белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Шушы урында авылдашыбыз, тагын бер асыл егетебез Разил Вәлиевнең сүзләрен искә төшерү дөрес булыр: «Мин еш кына татар теленең абруен күтәрү турында чыгышлар ясыйм. Шунда байтак «акыллы егетләр» миңа: *«Сезнең татар телегез белән бакча артыннан ерак китеп булмый», – дип каршы килергә тырыша. Ә мин: «Була», – дим. Һәм беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевне, хәзерге Президентыбыз Рөстәм Миңнехановны һәм гап-гади татар авылында туып үскән, авыл мәктәпләрендә белем алган, шуңа да карамастан, берничә югары уку йортында укыган, галәми эзләнүләр өлкәсендәге эшләре өчен СССР Дәүләт премиясе лауреаты булган, бик күп орден-медальлар белән бүләкләнгән Рәфкать ага Вәлиевне мисалга китерәм. Яшь буынга менә нинди үрнәкләр бар!»* ■

Безнең мирас №5 май 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Алм-Ата. 1910 еллар

ҖИДЕСУ ӨЛКӘСЕ

Җидесу өлкәсендә яшәгән халыкның күпчелеге күчмә казахлардан гыйбарәт. Бер өлеше – кыргызлар. Тагын бер өлешен исә Русиядән күчеп килеп урнашкан, «ногай» дип аталып йөртелә торган татарлар тәшкил итә. Калганнарын «сарт», ягъни «шәһәр халкы» дип атыйлар. Болары чыгышлары белән Бохара һәм Төркистан кешеләре.

Элекке заманнарда биредә руслар һич булмаган. Бу киң өлкәнең бер ягы «кышлау», ягъни кыш үткәрү урыны, икенче ягы «җәйләү», ягъни җәй үткәрү урыны дип аталган, һәркем теләгәнчә күчеп йөргән. Казах һәм кыргызларның бөтен көнкүрешләре хайван үрчетү белән бәйле. Иң фәкыйрь дигән кеше дә, аз дигәндә, 15-20 ат, 50 куй асраган. Байларның исә 1000-2000, хәтта 5000гә якын елкысы, 10000-20000гә якын куе булган. 200-300 елкысы булган кеше турында, «шактый хәлле», дигәннәр. Бу казахлар белән кыргызларның атамаларында аерма булса да, төп яшәү рәвешләрендә һич аерма юк. Шунысы гына бар: казахлар кыргызларга караганда сан ягыннан күбрәк. Җидесу, Сырдәрья, Төркистан, Оренбург, Урал, Тургай, Акмулла, Семипалат(инск)

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

өлкәләрендә һәм Кытай илендә бик күп санда казах яши. Кыргызлар исә бары тик Җидесу өлкәсендә генә таралган. Руслар боларның һәммәсен дә «кыргыз» дип атап йөртә. Бу халыклар үз эчләрендә кыргыз һәм казах дип аерылып кына калмыйлар, нәселләренең дә төрле булуын исбат итәләр.

Казахларның саны 9-10 миллион кеше дип исәпләнә. Бу халыкның сокландыргыч бер үзенчәлеге бар: алар һәммәсе дә уртак һәм бердәнбер телдә сөйләшәләр. Каспий диңгезе ярларында яшәгән казахлар белән, Алтайда яшәгән казахлар арасында әхлак һәм үз-үзен тотыш, яшәеш һәм гореф-гадәт ягыннан бернинди аерма да юк. Хәтта буй-сын ягыннан да алар һәр җирдә тыгыз, базык гәүдәле.

АЗЫК-ТӨЛЕКЛӘРЕ

Казахларга ашамлыклардан, нигездә, ат ите, эчемлекләрдән исә кымыз хас. Ит мул булганда, аз белән канәгатьләнмичә, күп ашыйлар; булмаса, атналар буе ашамыйлар. Кышын байлар өендә ит һәрвакыт бар. Кайбер байлар кышлык иткә 15-20 елкы суялар. Җәен исә, ит ашау, өйгә кунак килү-килмәүгә бәйле. Кунак килсә, куй суялар. Бер авылда бер кешегә кунак килсә, ул көнне кунак төшкән өй кешеләре дә, авыл халкы да сыйлана, туклана. Кунак килмәгән көннәрдә тустаган-тустаган кымыз эчәләр. Ул бетеп китсә, атка атланалар, авылдан авылга йөреп, ничек тә бер тустаган кымыз табалар; аны эчкәннән соң инде башкага кирәк тә калмый. Казахлар ачлыкка искиткеч түземлеләр, атналар буе берни ашамыйча тора алалар, ләкин ит булганда аларга 3-4 кило ит ашау берни тормый.

КАЗАХ ХАННАРЫ

Бу халыкның, Русия идарәсе астына кергәнгә кадәр, үз ханнары, солтаннары, әле 50-60 еллап кына элек үзләренең хөкүмәтләре бар иде. Бу көнгә кадәр Җиһангир хан һәм Кәйнисар солтанның оныклары исән-саулар. Русия белән иң соңгы тапкыр сугышкан Садыйк Тур әле исән, Сырдәрья өлкәсендә, Чимкәнтнең көнбатышындагы Карабулак дигән җирдә яши. Бу мөхтәрәм зат бүген дәрвиш тормышы белән көн күреп ята.

Җиһангир ханның оныгы Чыңгыз Гобәйдулла солтан моннан ике ел элек Петербургта вафат булды. Аның абыйсы Әхмәт солтан исә Кырымда Ялта шәһәрендә яши. Болардан башка тагын Кәйнисар хан оныклары да исән, аларның Акмулла өлкәсендә Күкчәтау тирәсендә яшәүче бер гаиләсе барлыгы мәгълүм, ләкин боларның һичберендә инде хөкемдарлыкның, солтанатның әсәре дә калмаган.

КАЗАХЛАРНЫҢ ТАРИХЫ

Казахлар да, кыргызлар да борынгы заманнардан бирле күчмә халыклар булганга, аларда уку-язу таралмаган, шуңа күрә тарихлары да язылмаган. Ләкин шулай булса да, алар тарихи хәлләрне шигырьләренә теркәп саклаганнар. Әһәмиятле вакыйгалар шагыйрьләр тарафыннан тасвир ителә, сөйләнә торган булган, аннары бу шигырьләр телдән-телгә күчә барып, буыннан-буынга тапшырыла килгән. Нәсел-нәсәпләре турындагы мәгълүмат та нәкъ шулай ук саклана килгән. Берара казахларга руслар янап, бәйләнеп торалар. Екатерина II заманыннан башлап, бөтен казах даласына Русиядән татарлар керә башлый. Болар биредә Ислам динен өйрәтеп җәелдергәннәр, шуның белән бергә җирле халыкны уку-язу сәнгате белән дә таныштырганнар. Бүгенге көнгә кадәр татарлар казах иленең бөтен төбәкләрендә мөгаллим хезмәтен башкаралар. Казах кешесе, әгәр аның 40-50 аты һәм 100-200 куе булса, һәр ел өенә махсус бер имам һәм укытучы-мөгаллим китертә. Бу татар-нугай мулла дин өйрәтеп кенә калмый, имамлык вазифасын да башкара. Шул рәвешле бөтен казах даласында Ислам дине җәелү белән бергә, уку-язу сәнгате дә таралган. Хәзерге вакытта исә, уку-язу сәнгате

Безнең мирас №5 май 2017

Ишәккә атланган ике казакъ. Алма-Ата. XX гасыр башы

Казакъ хатыны онықлары белән. XX гасыр башы

җәелә башлагач, казахлар арасыннан чыккан кайбер белемле яшьләр, халык авыз иҗаты буларак яши килгән тарихи мәгълүматларны туплау һәм теркәү эшенә дә керешкәннәр.

Казахлар гаять зирәк халык, бүгенге көндә инде араларында рус югары уку йортларын бетергән кешеләр дә очрый. Укуязу сәнгате җәелгәннән соң, дин дә ныгый барган. Араларында голәмә дә бар, шәехләр дә бар. Дин кушканны үтәүдәге, саклаудагы җитдилекләре нык, тик Русия хөкүмәте генә боларның идари эшләрен татарлардан аерган. Һәм, гомумән: «Казахлар мөселман түгел, бу мөселманлык татарлардан килде», – дип Русия хөкүмәте хәзерге көндә татар мөгаллимнәренең Казахстанда яшәвен, хезмәт итүен катгый рәвештә тыя. Тик барыбер, бу тыюлар нәтиҗәсез кала бирә. Татар-нугай яшьләре Казахстанга үтеп керүдән һәм анда мөгаллимлек итүдән һич туктамый. Моннан тыш, инде казахларның үз араларыннан да мөгаллимнәр җитешкән, гомуми милли уяну барлыкка килгән. Исламият Казахстанда инде тәмам җәелгән һәм ныгыган. Моннан соң инде руслар никадәр генә золым итсәләр дә, казах халкының ныклык күрсәтәчәгендә, кирәк булса, хәтта көрәш мәйданына да чыгачагында шигем юк. Русларга карамастан, 10 миллион казах – мөселман. Руслар тарафыннан килгән басым берара казах кардәшләребезне шактый кайгыга салган һәм әле дә хөкүмәт аларга басым ясый, хәтта утрак тормышка мәҗбүриләп, араларына христианнарны да урнаштыра. Бу хәлләр барыбер нәтиҗәдә казахларның файдасына булачак. Бүген Русиядә тиранлык үз башыннан боерык биреп торган кадәр, бу золым әле дәвам итәр. Әлбәттә, кайбер хәерче тинтәкләр христианлашырлар да, ләкин голәмә һәм халык бу золымга түзеп тора алмас. Бер вакыт җитеп, мөселманнар, әлбәттә, хокукларына ирешәчәкләр, бу – көн кебек ачык.

Руслар казахларның җәйләүләрен, көтүлек болыннарын кулларыннан тартып алганнар, бу сәбәпле хайваннарының саны шактый азайган. Ләкин бу хәлләр һәммәсе дә узгучы, табигать

Алма-Ата. Гимназия. XX гасыр башы

кануны таләбе буенча бер көн килер, руслар ничек килеп казах җирләренә урнашкан булсалар, шулай ул җирләрдән кузгалып китәрләр дә Ярослав, Тула төбәкләрендәге үз җирләрен табарлар. Ассимиляцияләү тәҗрибәсен дә хөкүмәт ничәмә-ничә еллар үткәреп караган, ләкин күчереп утыртулар һич кенә дә нәтиҗә бирмәгән. Иртыш елгасы буйларына моннан 150 еллар элек Дон ярларыннан күчереп утыртылган казак-урыслар*, казахларны руслаштырасы урында, үзләре казахлашканнар. Бүгенге көндә казах далаларына күчереп утыртылган казак-урысларның барысы да дини гыйбадәтләрен дә онытканнар, диннәре буенча тыелган ат итен дә казахларга караганда күбрәк ашыйлар, телләрен дә казах теленә алмаштырганнар.

Менә бу хәл – русларның үз күзләре алдында чынга ашкан тарихи вакыйга. Ислам динендә булганнарның руслашу ихтималы юк һәм булмаячак.

АЛМА-АТА

Җидесу өлкәсенең үзәге – Алма-Ата шәһәре. Руслар аны «Верный» дип атап йөртәләр. Бу шәһәрнең халкы да бөтенләе белән мөселман. Аратирә христиан кешеләре дә очрап куя, алары да, нигездә, дәүләт кешеләре, түрәләр. Биредәге мөселманнар Дунган, Таранчы, Нугай, Казах, Кыргыз, Сарт кабиләләреннән оешкан, тулаем төрки кавем. Шул сәбәпле география белгечләре бу төбәккә карата «Төркистан Кытае» атамасын кулланганнар. Чынлап та, Кашгардан алып Хотанга, Өрүмчидән Алтышәһәр белән Гольҗәгә, Җаркәнттән Себердәге Том һәм Обь елгаларының ярларына кадәрге җирләрнең төп халкы тулысынча төрки кавемнәрдән тора.

Алма-Атаның үзәк һәм әйләнә-тирә төбәкләре тулысынча мөселманнар карамагында булса да, бөтен Җидесу өлкәсенә шул ук Русиянең эчке районнарыннан күчүләрен дәвам итүче славяннар бу җирләргә хөкүмәт тарафыннан мәҗбүри китереп урнаштырылалар.

Ләкин, күчү мәсьәләсе, гомумән алганда, җиңел мәсьәлә түгел. Русиянең эчке төбәкләреннән Себергә, Төркистанга, Җидесу өлкәсенә, казах далаларына һәр ел никадәр кеше күчеп килсә, шуның яртысы, бәлки 60%ы кире кайтып китә.

*Дон буйларыннан Себергә күчереп утыртылган рус гаскәриләре, казаклар.

Чыңгыз Гобәйдулла

Илләре һәм түрәләре үзләренеке, яхшы каршы алыналар, чыгымнарын хөкүмәт үз өстенә ала, шулай булса да яртысы кире кайтып китә икән, димәк, мөселман татар мөһаҗирләренең Төркиядән кире кайтуларын гаеп итәргә урын юк.

Алма-Атаның Җидесу өлкәсе дип аталуының сәбәбе шул: бу җирләрдә җиде елга ага. Җидесу өлкәсенә караган төбәкләр – Пәшпак, Тукмак, Җаркәнт, Капал. Болар үзләре дә өлкә кадәр киң һәм анда күчмә тормыш белән яшәүче халыкның һәммәсе казахлар һәм кыргызлар, ягъни мөселманнар. Тик бу соңгы ун ел эчендә Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килгән руслар бу җирләрдә елдан-ел арта баралар.

Биредә хөкүмәт казахларны шулкадәр җәберли ки, күз алдына китерүе авыр. Пәшпакта ышанычлы кешеләрдән ишеттем: рус түрәләре яки килеп утырган руслар җирле халыктан бер кешене үтерсә дә, һичбер җәза-фәлән юк. Пәшпакка якын гына бер җирдә бер полиция мөдире Мөхетдин Карый исемле бер мөхтәрәм затны, Коръән укып утырган җирендә, мылтыктан атып үтерә. Аннан соң бу үтерүче үзе үк шәһәргә, Мөхетдин Карыйның туганнары янына барып: «Кардәшегезне фәлән җиргә барып алып кайтыгыз да җирләгез, мин аны атып үтердем», – дип хәбәр итә. Мин ул затның шул рәвешле шәһит киткәнен Пәшпак халкыннан бик күп тапкырлар ишеттем, каберен дә барып зиярат кылдым.

Шул рәвешле, Җидесу өлкәсендә мөселманнарны үтерсәләр дә, христианнарга берни булмый. Берничә вакыйгага билгеле, мәсәлән, Пәшпак белән Тукмак арасында бер авылны үтеп барганда, руслар бер мөселманны үтерәләр. Үтерүче үзе барып хәбәр итсә дә, аңа җәза бирелми. Менә шулай итеп, һаман да мөселманнарның каны коела бирә.

Ләкин мөселманнарга корал куллану катгый рәвештә тыела. Утлы корал турында сүз дә була алмый, мөселманның өендә зуррак пычак табылса да хәтта, өй хуҗасы җәзага тартыла, акча түли. Христианнарга исә һәртөрле утлы корал кулланырга рөхсәт ителә. Хәтта корал аларга тәкъдим ителә. Шулай булса да, бөтен кимчелекләр исламияткә сылтап калдырыла.

Җидесу өлкәсе далаларында яшәүче халыкның барысы да күчмә тормыш алып баручы казах һәм кыргызлар, дидек. Болар һәрвакыт таулардан тауларга күчәләр, бөтен табышлары, барлыклары хайван үрчетүгә бәйле. Тик бу соңгы елларда, хөкүмәт кушуы буенча, җирле халык кыш җитүгә авыл булып җыела, кышны шулай үткәрәләр дә, яз җитүгә күчеп китәләр. Моннан соң хөкүмәт бөтен бу күчмә тормыш рәвешен бөтенләй тыярга ниятли, инде кайбер чаралар да күрелгән. Русиянең эчке төбәкләреннән русларны китереп казах җирләренә урнаштыру – боларның беренчесе. Бу халык борынгы заманнардан бирле, ата-бабаларыннан килгән гадәт буенча күчмә тормыш белән яшәгән, бу аларның табигатенә сеңгән, моннан соң утрак тормышка күчү алар өчен үлем белән бер булачак. Дөрес, утрак тормыш күчмә тормышка караганда яхшырак, берәү дә инкяр итә алмас, ләкин гадәтне, табигатьне үзгәртү бик авыр нәрсә.

Безнең мирас №5 май 2017

Алма-Ата (Верный)

КАЗАХЛАРНЫ УТРАК ТОРМЫШКА КҮЧЕРҮ

Русиядә казахларны утрак тормышка күчерү мәсьәләсе моннан 30 ел элек хөкүмәт тарафыннан тикшерелеп, карар кабул ителгән. Ул көннән бу көнгә кадәр әлеге карарның сәбәпләре әзерләнгән һәм әле дә әзерләнә. Шулай булса да казахлар бу үзгәртүләргә ахыргача күнмәгәннәр, әле дә күнмиләр. Халыкның бер өлеше, күчмә тормышны калдырып, утрак тормышка күчкән булса да, форсат чыгуга, кире күчмә тормышка кайтачак. Чөнки күчмә тормыштагы иркенлекне, муллыкны ул утрак тормышта таба алмаячак. Күчмә тормыш белән яшәгәндә берничә мең елкысы булган казах кешесе бүген 700-800 елкы белән торып калган. Куйлар саны да шулай ук ким. Хайваны аз булган кешеләр бүген ач яши, ачлык бәласы аларны христианлашуга этәрә. Хөкүмәт никадәр генә тырышса да, казахлар күчмә тормышны ташлап утрак тормышка күчмәячәкләр. Әле тагын бер ярты гасыр бу күчмә тормыш дәвам итәр. Күчмә тормыш алар өчен рәхәт һәм табигый, җаны-тәне белән бу тормыш рәвешенә бәйләнгән халык аннан баш тарта алмый. Бүгенге көндә иң мәдәни дигән халыкларның да бакча өйләренә китеп яшәүләрендә шул күчмә тормыштан калган эзләр беленә. Затлылык һәм мәдәният моңа «бакча өе, дача, сайфия» исемнәрен биргән, ләкин чынбарлыкта бу да – күчмә тормышның бер төре. Табигый күренеш булганга, моны һәркем тели, яз-җәй җитүгә, һәр өйдән шәһәр читенә күчеп китүләр башлана. Шул рәвешле, казахларны утрак тормышка күчерү – аларны табигый хәлләреннән аерып, мәҗбүри хәлгә кую дигән сүз. Бичара күчмә халыклар утрак тормышка урнашып та җитә алмыйлар, шунда ук үпкә авыруы белән авырый башлыйлар. Берзаман карыйсың: һәр өйдә берничә кеше инде бу авыруга дучар булган. Әлбәттә гомерләрен яшәп бетерә алмаячаклар. Бу көннән башлап, казахларда үпкә авыруы көчәя бара. Башкортларда, бала чакларында утрак тормышка күчкән нәсел инде бүген юкка чыга бара. Руслар боларны белми түгел, беләләр, тик менә хөкүмәтләренең мәнфәгате генә берничек тә күчмә тормыш белән яраша алмый. Чөнки, күчмә халыклар утрак тормышка күчеп бетмичә торып, хөкүмәт иркен сулыш ала алмаячак, дөресрәге, хөкүмәт эчендә тәртип тәэмин ителә алмаячак.

Төрекчәдән

***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК
(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, туган,
Тере кешене чир сагалап тора.

Каһәрләнмә телдән-күңелдән бер дә –
Языкларны юар кичергән чирләр.

Ни дип галим әйткән гали фикерен
(Бу сүзләр китәрә күңелнең керен):

Гөнаһны юарга ауру бирелә.
Языксыз кеше кем – әйтеп бир миңа?!

Кеше чирләсә, бар язык түгелә,
Түгелә дә бетә. Дустым, шул гына.

Бар кеше дә азмы-күпме гөнаһлы,
Гөнаһсыз кешеләр, хәтта, юграктыр.

Авруың төзәлер һәм савыгырсың,
Гөнаһтан арынып, шатлык табырсың.

Телеңдә ниндидер ярамас сүзләр.
Нинди үлем, ди ул, и, күңле төз, ә?

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Тик Уйгырмыш әйтте: – Моның сәбәбе –
Үлемемне төштә әшкәртте Раббе.

Төш күрдем, төшемнән беленде тәмам,
Үләчәгем ачык инде, пәһлеван.

Яхшы яки яман хәл булса, Хода
Мәгълүм итә аны төнге йокыда.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЕ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Бу сүз бер
Җәһәттән дә, кардәш, ипле түгелдер.

Үлә барса һәрбер авырган кеше,
Бу дөньяда калмас иде һичберсе.

Тере бәндә һәрчак чирләргә дучар.
Тамырыңны кисми кулда һәр пычак.

Кеше төшләр күрсә, әгәр, еш кына,
Юраучылар юрый моны яхшыга.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

ТӨШ ЮРАУ ТУРЫНДА ҮГЕДЕЛМЕШ

Төш юрау – белергә тиешле гыйлем.
Төшләрне юрарга кирәк бик белеп.

Төрле-төрле була төшләр шулчаклы!
Махсус өйрәнмәле, и, йөзе яктым.

Төшеңне сөйләмә теләсә кемгә.
Белгечләрдән сора. Һәм көнен-көнгә:

Кичәге төшеңне сөйләмә бүген
Һәм көндезге төшең ул төнге түгел.

Кагыйдәсе күп төш юрау гыйльменең,
Шуларны үзләштер, җитсә зиһенең.

Төшеңне үзеңчә юрап йөремә,
Шулай ук, сөйләмә аны һәркемгә.

Төш, дигәннән, барча төшләр түгел тиң.
Төшнең хикмәтләре күптер, егетем.

Төш күрсәң, шунда ук юрап йөремә.
Кыяс итеп кирәк мәгънә бирергә.

Юраучыга барсын кеше төш күрсә,
Мәгънәсе югала, аның, югыйсә.

Ни ди әнә берәү – белем диңгезе
(Син шатланып тыңла аның һәр сүзен):

«Юратканың яхшы әгәр төш күрсәң,
Төбен, аслын аңлап зирәк фикердән.

Ашыгып, начарга юрама төшне,
Юравың юш килеп, бозмагай эшне».

Ашауга- эчүгә баглы кайбер төш:
Ямьсез төшкә сәбәп – яраксыз җимеш.

Кайбер төшләр баглы ел фасылына –
Кешенең яшенә һәм асылына.

Яз вакыты булса, яшьрәк кешеләр
Төш күрсә кызыл һәм кара төсендә,

Аның каны артып киткәндер яман,
Канын алдырса да, күрәсең, таман

**Төш юрау – белергә тиешле гыйлем.
Төшләрне юрарга кирәк бик белеп.**

Көз фасылы булып, егет кешегә
Кызыл, ал, сары төс керсә төшенә,

Сары суы аның көчәеп киткән,
Бушангач, чык җавы[1] ашарга микән?

Көз фасылы, төштә ир уртасына
Күренсә биек тау, кара – күк сыман.

Аңарда дәрт артык көчәйгән, туган.
Дару эчеп, миен чистартыр шуннан,

Кышын төш күрүче карт кеше булса,
Төшенә агымсу, боз йә кар керсә,

Көчәя бугай, күр, аның бәлгаме[2],
Кайнар аш-су гына моның бар име.

Әгәр төш тәртипсез күптөрле икән,
Аның тәгъбире юк, и, холкы күркәм.

Шулай ук, төшеңдә кич уйлаганың
Күренсә, тәгъбире бер дә юк аның.

Кайчак ир шайтани, җенни төш күрсә,
Андый төш күргәчтен таһәрәт кирәк.

Әгәр кеше төштә күрсә үз эшен,
Юраусыз инде ул, и, оста кешем.

Шуларны кешедән сорап белешсәң,
Нәрсәдер аерып була бер төштән.

Ни ди атаклы төш юраучы хәким:
«Төшнең ниндилеген белү бик мөһим;

Төш күрсәң, белмичә юрама, зинһар,
«Юравың юш килер» дигән сүз дә бар.

Төшеңдә кайгырсаң – бу сөенечкә,
Сөенеч – кайгыга, нәкъ киресенчә.

Бердәй түгел охшаш төшләр юравы,
Моны хәтердә тот, и, холкы ару.

[1] Чык җавы – «агач яфракларында була торган баллы кунык».
[2] Бәлгамь – «какырык».

Төш күрсәң, шунда ук юрап йөремә.
Кыяс итеп кирәк мәгънә бирергә.

Кара халык төше юрала үзгә,
Бәкләр төше кебек юралмый бер дә.

Күрелсә төшеңдә бию-уеннар,
Якында борчулар килү ихтимал.

Төшеңдә кайгырып еласаң, шуннан:
Бу – хәбәр эш уңып, шатлануыңнан.

Тагын шундый төшләр дә, күр, булгалый;
Күрүчегә түгел бүтәнгә карый.

Әйтеп юрыйсың да шул бер кешегә,
Файда килә уртак дуслык эшенә.

Бер төш бий булудан китерсә хәбәр,
Икенче берәүгә шул ук төш – хәтәр.

Боларны белергә кирәктер, туган,
Шуннан соң юрарга мөмкинлек чыга.

Ачык кына сөйләп бир төшеңне син,
Юрап бәйнә-бәйнә мин төшендерим.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ТӨШЕ

Җаваплап, Уйгырмыш юл бирде телгә:
– Ярый, төшне сөйлим, син ал күңелгә.

Аратасы илле бер баскыч күрдем,
Терәтеп куелган, озын, киң үзе.

Һәр арата булды бугай бер адым,
Югарыга кадәр менеп санадым.

Бер атлы зат шунда су бирде. Алдым.
Төбенәчә эчеп бетердем, кандым.

Шуннан соң кинәттән очтым да киттем,
Һәм үзем әллә бар, әллә юк идем.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ТӘГЪБИРЕ

Юравын болай дип әйтте Үгделмеш:
Асылда изге төш – син күргән бу төш.

Нигә син ярашсыз юрыйсың аны?
И, якты күңел, ул юрарга җайлы.

Күтәрелеш шулдыр – кадерең арта,
Дәрәҗәң адымы һәрбер арата.

Күтәрелсәң төштә, бәхетең артыр,
Абруең – йөз суың шуңа тиң артыр.

Баскычка менгәнчә даның киңәер,
Өстеңдә кот кошы канатын җәер.

Ошбу сүзләремә дәлил итәрәк,
Төш юраучы белгеч сүзен китерәм:

Төштә баскыч күрү – күтәрелештер,
Арата – олуглык кимәле инде.

Күтәрелү – малың артуы булыр,
Синең алдыңа ак кот кошы куныр.

Синең савыттан су алып эчкәнең
Белдерә гомерең озын икәнен.

Очып кинәт күккә үрләп китүең –
Тәңре ни теләсәң, шуны бирүе.

ШУЛ УК ТӨШНЕ УЙГЫРМЫШНЫҢ БҮТӘНЧӘ ЮРАГАНЫ

Җавабын Уйгырмыш әйтте: – Сүзем шул:
Юравың бөтенләй дөрес түгел ул.

Бу төшне син үзең күрсәң бер ятып,
Юрар идең шулай – бик дөрес итеп.
Синең һиммәтең бар дөнья бәясе.
Теләгәнең таба җирдә һәммәсе.

Мин үзем теләдем дөньяны ташлап
Яшәргә һәм менә чигәмен азап.

Төгәл юрамадың төшемне минем,
Тыңласаң, мин үзем тәгъбирләп бирим.

Биек яндавырлы баскыч күргәнем,
Минем гомеремдер, шиксез, туганым.

Баскычның башына менеп җиткәнем –
«Иң соңгы яшеңә җиттең», дигәне.

Ашыгып, начарга юрама төшне,
Юравың юш килеп, бозмагай эшне.

Менеп җиткәч килде теге ак атлы,
Аның биргән суын мин эчтем алып.
Ул атлы шундыйдыр – аталыларны
Атасыз калдыра, и, рухи алып.

Ул атлы шундый ки, зәвалы җиткән
Шәһәрне гүр итә, гөлне көл итә.

Савыттагы суны эчкәнлегемне
«Син озак яшисең икән», диденме?

Су – тереклек, яшәү, дип дөрес әйттең.
Савыттагы су ул – яшәү мөддәте.

Әгәр тик яртысын эчсәм чөмереп,
Үткән булыр иде ярты гомерем.

Әмма мин ул суны бетереп эчтем..
Димәк, гомер тәмам. Сау бул, и, изгем.

Ни ди, ишет, бер зур белкә – акылдар
(Белкәләрнең сүзе дөрес асылда):

Савыттагы суның яртысын эчсәң,
Димәк гомереңнең яртысы беткән[3].

Әгәр суын эчсәң төбенә кадәр,
Яшәвең төкәнә, казыла кабер.

Югарыга очып күтәрелгәнем
– Хөкеменә мине котәдер Тәңрем.

Газиз җаның чыгып очса кибеннән[4],
Ничек тә бер кайгы кермәс кирегә.

Ходаем әшкәртә бу төш аркылы
«Әзерлән үлемгә», – дип үк, батырым.

Төшем юралышы шулай ул, ләкин
Миңа син бүтәнчә юрыйсың, хәким.

Син инде күңлемне юатмакчысың,
Тик үлем каршында им юк – инде соң.

**Кайчак ир шайтани, җенни төш күрсә,
Андый төш күргәчтен таһәрәт кирәк.**

**Төштә баскыч күрү – күтәрелештер,
Арата – олуглык кимәле инде.**

Инде кара, үлем нинди җегәрле:
Өем-өем итә тигез җирләрне,

Ничә кирмән, биек, рәешле сәрай
Үлем-кыргын килеп, бум-буш булган, һай.

Ничә, күр, горур һәм бөек бийләрне
Үлем, и, дус, туры юлдан җибәрде.

Ничәмә-ничә көч, дәрт ияләрен
Үлем тотты, екты, алды хәлләрен.

Гаҗәп түгел бу хәл – туган зат үлер,
Һәрбер тын алгучы үлемгә җимдер.

Гаҗәп ки – үләсе ошбу зат, тән-җан
Еш кына тәүбәсез китеп баручан.

Гафил инсан, болай, беләү үләсен,
Гафиллеген җиңә алмый, күрәсең.

Үлем хак, кичү юк инде һич башка,
Ничек булыр икән хәлем ул якта?

Менә шуны уйлыйм, күңелдән, дустым:
Үлемнән соң миңа Тәңре дус булсын.

Көнем тыныч үтсә, канәгать идем,
Рәхәт-кыеннарны ялгыз кичердем.

Кулны кыска тоттым, мал дип көймәдем,
Һаваланууларга күңел бирмәдем.

Бу көнгә җиткерим, дидем, йөгемне,
Теге якта булыр, дидем, җиңеллек.

Миңа тәгълим бирмеш кеше ни диде
(Рәхимле нәсыйхәт ул бирер иде):

«Гафил булма, хич тә, дөньяны оныт,
Юлың кылдан нечкә – буеңны төз тот.

Дәвамы бар ■

[3] Борынгы кыпчак-куман балбаллары ике куллап су савыты тоткан килеш сурәтләнүнең мәгънәсе Уйгырмыш сөйләгән юралыш белән баглы булса кирәк.
[4] К. Себер сөйләшләрендә кәп-кип – «сүрү, кипрән». КБ-тә кәп.

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)



Алдагы паровоз каршыга килүчесенә озын, көчле итеп сызгыртты. Аның гайрәтле гудогы Әбүталипның йөрәген кузгатты. Буранлы станциясенә кадәр барып җитү өчен вакыт беткәннән-бетә бара иде. Лачын күзленең фараз йөртү, гөманлау рәвеше Әбүталипны шөбһәгә салды. Мондый мәкерле көчкә бу илдә каршы торырлык берни дә юктыр. Ләкин шушы мәлдә Әбүталипны хәлдән тайдырган нәрсә – Тансыкбаевның гомер булмаганча теленә салынуы, күп сөйләшергә теләве һәм сорау алуны тиз генә төгәлләргә җыенмавы иде.

– Менә шул, – Тансыкбаев, үз алдындагы кәгазьләрне читкәрәк этеп, Әбүталипка күзләрен күтәрде. – Ышанам, без бер-беребезне аңларбыз, синең бу бәладән котылу юлың шунда гына. Ышанам, Ырынбурдагы күзгә-күз очрашу икенең берсен хәл итәчәк – йә син миңа эшне төгәлләргә булышасың, яисә мин, үкенечкә калмасын өчен, барысын да эшләячәкмен; ә аннан соңгысы – хөкемнән тора: дүртенче тапкыр утырырсыңмы, әллә «вышка» ук алырсыңмы! Бала-чага түгелсең, бөтен ягын да аңлыйсың. Күр дә тор, сез хезмәт иткән Титога кадәр үк барып җитәчәкбез. Бу хәлләрне Иосиф Виссарионович үзе күзәтеп тора. Беркем дә җәзасыз калмаячак, тамырларыгызны рәхимсез куптарып атачакбыз. Шуңа күрә, дустым, язмышыңа рәхмәт укы, – мин сиңа зыян салырга теләмим. Тик син дә, әйткәнемчә, бурычлы булып калмаска тиеш. Ни турында сүз барганына төшендеңме?

Әбүталип җавап кайтармады, бары тик, эсселе-суыклы булып, Буранлы

Ахыры. Башы журналның 2016 елдагы 8 нче санында. Тәрҗемәче – **Мөдәррис Вәлиев**.

станциясенә барып җитәсе минутларны санады. Үзенекеләрне тәрәзәдән генә булса да күрергә язмаган, ахрысы. Аның миен шул фикер бораулады.

– Ник дәшмисең? Синнән сорыйм, нәрсә турында сүз барганын аңладыңмы? – дип төпченде Тансыкбаев.

Әбүталип башын какты. Әлбәттә, аннан ни таләп ителгәнен белә ул.

– Йә, күптән шулай дип әйтергә кирәк иде! – Тансыкбаев баш кагуны ризалык бирү билгесе дип кабул итте, урыныннан торды, Әбүталип янына килде, хәтта аның җилкәсенә кулын салды. – Мин акыллы гына егет икәнлегеңне, дөрес юлга чыгасыңны белә идем. Димәк, шулай килештек. Бернидән дә шикләнмә. Мин ничек әйтсәм, барысын да шулай эшлә. Иң мөһиме – күзгә-күз очраштырганда каушап калма, барысын да ничек булганынча сөйлә. Попов – резидент, кырык дүртенче елдан башлап, Англия разведкасына ялланган, илгә кайтарылыр алдыннан Титоның үзендәге киңәшмәдә катнашкан, баш күтәрү, фетнә кебек хәлләр була калса, дип, озак вакытка исәпләнгән йөкләмәләр алган. Менә шул җитә. Инде теге татар Сәйфуллин турында. Болай булып чыга. Сәйфуллин – Поповның уң кулы. Артык сүз кирәк түгел. Калганын үзебез карарбыз. Кистереп әйт һәм икеләнмә. Сиңа берни дә янамый. Берни дә! Мин сине ташламам, уңайсыз хәлдә калдырмам. Димәк, шулай килештек. Исеңдә тот. Дошман белән озак сөйләшеп тормыйбыз, – аны юк итәбез. Ә дусларга безнең күңелләр хуш. Аннары, онытма, минем белән шаяру яхшыга илтми... Тукта, син нишләп агарындың әле, тирләп тә киттең кебек, хәлең начарландымы әллә? Һава җитмиме?

– Әйе, үземне начар хис итәм, – диде Әбүталип, баш әйләнүен һәм күңеле болганууын җиңәргә тырышып, чыннан да ул бозылган ризык ашап агуланган кеше сыман иде.

– Ярар, алай икән, тоткарламыйм. Бар, Ырынбурга җиткәнче ял итеп ал. Әмма Ырынбурда койрыгың алтатар кебек торсын. Аңладыңмы? Күзгә-күз очраштырган чакта һичнинди уңга-сулга тайпылу юк. Бернинди «хәтерләмим, белмим, оныттым»нар булырга тиеш түгел! Барысын да, ничек сөйләштек, шулай эшлисең. Ә калганына борчылма. Анысын үзебез ерып чыгарбыз... Менә шулай. Хәзер языпсызып маташмыйбыз, бар, ял ит, ә Ырынбурда очрашу нәтиҗәләре буенча кәгазь тутырып, куллар куярбыз, тәртибе шундый. Бар. Синең белән аңлаштык дип саныйм. – Шул сүзләр белән Тансыкбаев Әбүталипны тоткын купесына озатып җибәрде.

Бу мизгелдән, әйтерсең лә яңабаштан, Әбүталип өчен ниндидер аерым тормыш башланды. Поезд да тизлеген арттырган кебек тоелды. Тәрәзә артында яхшы таныш урыннар йөгереп уза. Буранлыга кадәр санаулы минутлар гына калган булырга тиеш. Тынычланырга, үз-үзеңне кулга алырга, теләсә нинди хәлгә әзер булырга, әмма барысыннан да бигрәк ярсып чапкан ат шикелле поездны тыярга кирәк иде. «Поезд әкренрәк барсын», – дип уйлады Әбүталип, ниндидер сихри көчләрне үзенә теләктәшлеккә чакырып, һәм тиздән поезд чыннан да тизлеген киметкән кебек булды, әллә аңа гына шулай тоелдымы, барыбер тәрәзәдәге күзне суырып китә торган күренешләр сабырлана төште. Шунда ул үз-үзенә әйтеп куйды: «Барысы да мин сораганча булыр!» Һәм бераз тынычланды, сулышы иркенәйде; рәшәткәле тәрәзәгә сыланып, көтә башлады.

Поезд, чынлап та, Буранлы станциясенә – кайчандыр Әбүталипны дөнья нужасы читкә кагып, куалап китергән, шунда, балалар үскәнче, тарих түнтәрелешләре авышканчы дип кенә корган оясына җитеп килә иде. Тик боларын ук күрергә насыйп булмады шул. Гаиләсен язмыш кочагына ташларга туры килде, ә үзе менә хәзер бу җирләрне тоткыннар вагонында узып бара.

Әбүталип тәрәзәгә шулкадәр киеренкелек беләнябышты, әйтерсең лә күргәннәрен бөтен гомеренә, ахыргы сулышына кадәр, күзендә соңгы чаткы сүнгәнче хәтерләп калырга тиеш иде. Февраль кышының төш уртасында күргән бар нәрсәсе: кар көртләре,

тимер юл буендагы кары эреп, бераз сары балчык беленә башлаган төшләр, байтак өлеше әле ак юрганы астында яткан, урыны-урыны белән генә ачылган дала – ул аларны изге манзара буларак, табынып дип әйтерлек, дулкынланып, яратып күзәтте. Менә таныш кашлык, менә уйсулык, ә бу – Зарипа белән икәү, җилкәләренә эш кораллары салып, юл төзәтергә йөргән сукмак, менә – җәй көне Буранлы балалары, алар янында аның малайлары Эрмек белән Даул да йөгереп уйный торган кечкенә алан... Ә менә дөяләр төркеме, тегендәрәк тагын бер пар, аларның берсе – Идегәйнең Каранары, – аны ерактан ук аерып була, шундый егәрле мал, каядыр үзалдына ашыкмый гына йөрер; тукта, бу ни булды – тәрәзә артында кар бөртекләре талпынды, кинәт кар яварга кереште, шулай шул, иртәдән үк күктә болытлар куера башлаган иде, һава бозылырга булган икән, тик кар дигәнең аз гына көтеп торса да ярый иде ләбаса, бик аз гына, инде бит киртәләп алынган дөя абзарлары һәм морҗасыннан төтен күтәрелгән беренче түбәләр күренде, ә менә гадәттә вокзалда гына була торган юл чатын – стрелканы да узып барабыз, поезд бер юлдан икенчесенә күчә, рельслар ялганган төш белән тәгәрмәчләр шакып хәбәрләшә һәм паровоз йөртүчеләргә иң элек «юл-чатчы» – стрелкачы оясы-будкасы янында кечкенә флагы белән, һаман да шул, беләгендә, корыган агач шикелле, сеңерләре кабарып торган Казангап күренә; ай Алла, Казангапның «оя»сы да чакма ташын чаккан арада гына күзгә чалынып калды, поезд инде алга таба, торак-поселок яныннан узып бара; уңда – кечкенә өйләр, аларның түбәләре, тәрәзәләре, менә кемдер өенә кереп китте, Әбүталип аның аркасын гына күреп калды, ә менә кемдер киртә-такталар тирәсендә кайнаша, бала-чагалар өчен нәрсәдер кора. Идегәй, – әйе, бу ул, Идегәй, аның өстендә – җиңнәре сызганулы сырма, янында кызлары, алар белән Эрмек тә шунда, әйе, газиз, кадерле улы Эрмек, ул Идегәйгә җирдән нәрсәдер алып-биреп тора, йа Хода, аның йөзе күзгә чалынып кына китте, ә Даул кайда соң, Зарипа кайда? Әнә, зур корсагын күтәреп бер хатын атлый, станция башлыгы Сауленың җәмәгате ул, ә менә Зарипа да килә икән, – яулыгы иңнәренә шуып төшкән, – Зарипа белән Даул икәү бергә, Зарипа кече малаен кулыннан җитәкләгән, башы аңа таба иелгән, – улына нидер сөйли-аңлата иде булса кирәк, – алар Идегәй белән бала-чагалар нәрсәдер ясап яткан төшкә баралар, Әбүталипның: «Зарипа! Бәгырем! Даул! Даул, улым! Бу – мин! Сезне соң мәртәбә күрәм! Бәхил булыгыз! Даул! Эрмек! Бәхил булыгыз! Онытмагыз! Мин сездән башка тора алмыйм! Сездән башка, газиз балаларымнан, яраткан хатынымнан башка миңа тормыш юк! Бәхил булыгыз!» – дип ачыргаланып кычкырганын, өметсез тавышы белән станцияне яңгыратканы ишетелмәсен өчен, кулы белән авызын каплап өлгерүен алар белми.

Ватылган күңел көзгесенең ялтыравык кыйпылчыклары кебек ул мизгелләр, озак көтелгән Буранлы станциясен поезд күптән узып киткәч тә, бербөтен булып җыелды һәм, кабат-кабат, Әбүталипның күз алдына килеп басты. Инде тәрәзә артында ишеп-ишеп кар ява иде, инде күптән барысы да артта, еракта, әмма Әбүталип өчен вакыт әле генә кичергән күренешләр эчендә туктап калды – юлның үзенә бөтен авырту тойгысын һәм бу дөньяда яшәү мәгънәсен сыйдырган кисәгендә...

Гәрчә, тоташ кар яву аркасында, тышка карап баруның инде мәгънәсе булмаса да, ул үзен барыбер тәрәзәдән аерып ала алмады. Менә әле дә тәрәзәгә кадаклап-богаулап куелган кебек хәлдә бара. Аны шунысы тетрәтте: ул, бу дөньяның гаделсезлеге белән килешмәсә дә, барыбер кемнеңдер ихтыярына буйсынырга, шым гына, телсез җан иясе кебек, хатыны һәм балалары яныннан качып-посып узарга мәҗбүр булды, – чөнки башына моңарчы ирегеннән мәхрүм иткән әлеге кара көч басты, – һәм, поездан сикереп каласы, хатынының, балаларының күзенә күренәсе, сагынып-саргайган гаиләсенә таба башын югалтып чабасы урында, кимсетелгән вә мескен кыяфәттә,

кечкенә тәрәзәгә карап катты, бер почмакта утырырга һәм селкенмәскә боерылган эт хәлендә калдырган Тансыкбаевка үзе белән теләсә ничек кыланырга мөмкинлек бирде. Ниһаять, бераз тынычланыр өчен, бу минутларда Әбүталип, ачыргаланып, үз-үзенә сүз беркетте, аны телдән кычкырып әйтмәсә дә, барыбер аң төбенә салып, күңеленә бикләп куйды...

Күз ачып йомганчы булган күрү-күрешүнең ачы ширбәтен ул хәзер төбенә кадәр эчә иде. Инде тик шул гына аның хәленнән килә, тик шул гына аның ихтыярында калды – кабат-кабат барысын да җентекләп, бөтен ваклыклары белән күз алдында яңарту: иң элек һаман да шундый, сеңерләре кабарып торган кулындагы кечкенә флагын тотып, каккан казык кебек, урынын ташламаучы Казангапның таныш чалымнары, – станциянең әле бер, әле икенче башында баскан килеш, ул үз гомерендә ничәмә-ничә поездны уздырып җибәрде икән; аннары Буранлының кечкенә өйләре, терлек-туар өчен каралты-куралары китте, морҗалардан сыек күксел төтен күтәрелгәне күзне иркәләп узды, һәм аннан соң, бала-чага арасында мәш килгән, шулвакытта аларга нидер корып маташкан Буранлы Идегәйне күрде, – өстенә җиңнәре сызганулы сырма, аягына кирза итекләр кигән зур, нык-таза гәүдәле, кара-туткыл йөзле Идегәй... – мондый туры, дөрес кеше, кыя кебек, үз-үзе булып кала алган адәм дөньяда бүтән бар микән, – менә ул балалар белән бик яратып, җанын ярып бирердәй булып, нәрсәдер турында сөйләшә, – аңа такта кисәгеме, әллә бүтән нәрсәме сузып торган улы Эрмек, – анысы иске кечкенә кышкы бүректән һәм киез итекләрдән; шунда ук, Ходайның рәхмәте, – алар янына килеп баручы Даул белән Зарипа... мескен Зарипасы – иңнәренә шуып төшкән яулыгы ачкан кара бөдрә чәчләре, агарынган, шундый үз, кадерле йөзе; төймәләре чишелгән бишмәте, аякларындагы кайчандыр ул сатып алган тупас итекләре... – шулхәтле ачык булып күренде... – Һәммәсе дә чиксез якын, онытылмас бу күренешләр Әбүталипны әле бик озак озата барды, ул үзенә газиз затлар белән күңеленнән генә кат-кат бәхилләште... Мондый югалтуны һичкайчан һәм һични белән дә алыштырып булмый иде...

Юл буе тышта кар яуды, җәяүле буран себерде. Ырынбурга барып җитәрәк булырга тиеш, ниндидер станциядә поезд бер сәгать чамасы туктап торды, – юлларны көрттән арындырдылар... Монысын ул тыштан килгән тавышлардан аңлады, кешеләр, һава торышын һәм дөньядагы бөтен нәрсәне каһәрләп, сукрана-сукрана эшлиләр иде. Аннары поезд яңадан кузгалып китте дә, кар-буран өермәсенә уралып, алга таба тәгәрәде. Ырынбурга озак керделәр, юл буендагы куаклар, кара, кәкре ботаклары белән, ташландык зираттагы корыган агачлар сыман, томан эчендә генә күзгә чалынып бардылар. Кала үзе яхшылап күренми дә иде. Вагоннарны аеру станциясендә төн ката басып тордылар – махсус вагонны озак кына төп составтан аердылар. Әбүталип моны вагоннарның этешү-төртешүеннән, берсен икенчесенә китереп ялгаучыларның тавышыннан, маневр локомотивларының кычкыртуларыннан чамалады. Аннары вагонны тагын каядыр тартып киттеләр, – күрәсең, запас юлгадыр.

Инде төн урталары иде булса кирәк, махсус вагонны үзенә билгеләнгән урынга кертеп куйдылар. Соңгы этелеп алу, астан ишетелгән соңгы команда: «Шәп! Тугар атыңны!» Вагон, җиргәябышып калган кебек, шып туктады.

– Йә, булды! Җыен! Чык, тоткын! –дип, купе ишеген ачып әмер бирде өлкән назир Әбүталипка. – Тоткарлама! Чык! Йокы бастымы? Әнә, саф һава сула!

Әбүталип аңа каршы әкрен генә урыныннан кузгалды һәм, назирга якын ук килеп, салкын тавыш белән:

– Мин әзер. Кая барырга? – диде.

– Әзер икәнсең, ул чакта атлавыңны бел! Ә кая барырга икәнен конвой күрсәтер,

– назир Әбүталипны коридорга уздырды, әмма шунда ук аны туктатты, гаҗәпләнеп һәм җене чыгып җикерде:

– Кая киттең? Ә, синең юл капчыгың каламыни? Нишләп алмадың? Әллә аны мин күтәрешер дип көтәсеңме? Бар, хәзер үк сәләмәләреңне җыеп чыккан бул!

Әбүталип купега борылып керде, зиһене таралганлыктан онытып калдырган юл капчыгын теләмичә генә кулына алды һәм, янә коридорга чыккач та, вагон буйлап ашыгып һәм борчулы кыяфәттә килүче җирле ике погонлы белән бәрелешә язды.

– Тукта! – Әбүталипны назир стенага кысрыклады. – Уздырып җибәр! Күзең чык-канмы әллә, иптәшләр каршы алырга килгән.

Вагоннан тышка атлаганда, Әбүталип теге ике адәмнең Тансыкбаев купесына шакыганнарын ишетте.

– Иптәш Тансыкбаев! – Дулкынлану аларның тавышларына да чыккан иде. – Килеп җитүегез белән! Без инде сезне көтеп арыдык! Зар-интизар булдык! Ә бездә бүген кар ява! Гафу итегез! Танышырга мөмкинме, иптәш майор!

Кораллы конвой, – өчесе дә колакчын бүрек кигән, өсләрендә солдат формасы, – тоткынны, юллар аша алып чыгып, ябык машинага хәтле озатырга дип, аста көтеп торалар иде.

– Йә, төш! Нәрсә терәлеп каттың? – дип, конвойчыларның берсе ашыктыра башлады. Назир озатуында, Әбүталип дәшмичә генә баскыч буйлап аска атлады. Җил белән котырып буран улый иде, йөзгә кисәк кенә салкын һава килеп бәрелде. Баскычның тимер тоткалары кулны куырып алды. Таныш түгел станциядәге юл утлары белән генә яктыртылган караңгылыктан һәм кар белән капланып килүче рельсларның чәбәләнүеннән башлар әйләнеп китте. Моңа маневр локомотивларының төрле яктан хәтәр-куркытып сызгыртуы да килеп кушылды.

– Туксан җиденче санлы тоткынны тапшырам! – дип, өлкән назир конвойга хәбәр салды.

– Туксан җиденче санлы тоткынны кабул итеп алам! – Өлкән конвойчының җавабы кайтаваз булып яңгырады.

Әбүталип белән саубуллашканда, өлкән назир:

– Булды! Кая кушалар, шунда атла! – диде. Аннары ни өчендер өстәп куйды: – Ә анда машинага утыртырлар да алып китәрләр...

Бәреп яуган кар-бураннан йөзләрен каплап баралар иде. Әбүталип, җилкәсендәге юл капчыгына ышыкланды да, чамалап кына рельслар һәм шпаллар аша атлап чыга-чыга, конвой астында алдагы паровозларга таба юл тотты... Әле тегендә, әле монда төнге сменадагы локомотивлар сигнал биреп кычкыртуын дәвам итә иде.

Тансыкбаевны миһманханәгә алып китәргә килгән Ырынбур коллегалары, көтелгән кунакны каршылауны билгеләргә дип, аның җылы купесында бераз тоткарланырга карар кылдылар. Танышу хөрмәтенә, шайтан суын шунда, купеда ук, кабымлык белән йотып куярга, дигән тәкъдим дә керде: кич җитте бит инде, эш сәгате бетте. Кем риза булмасын. Сүз барышында Тансыкбаев йомгакның уңайга таба тәгәрәвен әйтергә булды: күзгә-күз очраштыруның уңышлы барып чыгасына ышаныч зур, диде, шуның өчен алар Алматыдан хәтле килделәр дә бит инде.

Коллегалар бик тиз исңәштеләр, тик, җанлы сөйләшү кызып киткәндә генә, кинәт тыштан ярсып кычкырган авазлар һәм вагон коридоры буйлап чабышкан итекләр тавышы ишетелде. Купега конвойчы белән өлкән назир ыргылып керде. Конвойчы канга баткан. Авызы-бите кыргый төскә кереп чалышайган. Тансыкбаевка честь биреп, кычкырды:

– Туксан җиденче санлы тоткын һәлак булды!

– Ничек инде һәлак булды? – Тансыкбаев, үз-үзен белештермичә, сикереп торды.

– Һәлак булды – бу нәрсә дигән сүз?

– Паровоз астына ташланды! – дип ачыклык кертте өлкән назир.

– Ташланды – ул ни дигән сүз? Ничек инде ташланды?! – Тансыкбаев, шашынып, якасыннан эләктереп, назирны селкеде.

– Без юлларга килеп җиткәч, уңнан да, сулдан да маневр поездлары кузгалды, – дип, бутала-бутала аңлатырга кереште конвойчы. – Шунда ук составны кузгатып йөртә башладылар. Тегендә-монда... Ну, без көтеп торырга тукталдык... Шулчакта тоткын кинәт, юл капчыгы белән кизәнеп, башыма китереп орды, ә үзе туп-туры узып баручы паровоз юлына, тәгәрмәчләр астына ташланды...

Барысы да хәлнең көтелмәгәнлегеннән югалып, тынып калган иде. Тансыкбаев, бәрелә-сугыла, чыгарга җыена башлады.

– Нәгъләт, кулдан ычкынды бит, кабахәт! – дип, калтыранган тавыш белән сүгенде ул. – Бөтен эшне бозды! Барып чыкмады, ә! Котылды бит, китте! – Барысыннан өметен өзеп, кулын селтәде дә үзенә, тутырып, бер стакан аракы салды.

Аның Ырынбурдагы коллегалары, шулай да, конвойчыны, килеп чыккан хәл өчен бөтен җаваплылык синең өстә, дип кисәтергә онытмадылар...

ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН:

Чыңгыз ага белән Тәүге мәртәбә (ул чакта Бельгиядә яши иде), «Мәгариф» нәшриятында эшләгән чорымда Англиядәге каләмдәшебез Равил Бохараев аша элемтәгә кердем. «Татар әдәбияты дөньясы» дигән (бүген дә дәвам итүче) рус телендәге китаплар сериясен башлап җибәрмәкче вакытыбыз. Беренче басма Аяз Гыйләҗевнең сайланма әсәрләре белән ачылырга тиеш иде (әлеге ниятемне хуплап, риясыз ярдәм итүләре өчен, Аяз аганың хәләле Нәкыя апага һәм университет галимәләренә чиксез рәхмәт). Айтматовтан шул сериягә фатиха бирүен сорадым. Ул үтенечебезне кире какмады, яңа заман татар прозасы һәм Аяз Гыйләҗев иҗаты турында фикерләрен дә теркәп, кереш сүз язып салды. Ихтимал, бу аның исән чагында басылган соңгы хаты булгандыр... Мәгълүм ки, ана йөрәге аша безнең милләткә килеп тоташкан олпат затка рәхмәтемне шул көннән бирле әйтеп җиткерә алмыйча, бик тә бурычлы булып калган сыман йөри идем. Менә, ниһаять, форсат чыкты, – аның «Чыңгызханның ак болыты» дигән әсәре әнисе теленә әлегәчә күчерелмәгән икән. Безгә бала чакта ук килеп җиткән «Беренче мөгаллим»еннән башлап, мин аны үзем өчен «беренче» дип саный идем, «...ак болыт»ны укып чыккач та, ул шул биеклектә калды. Вакытымның тыгызлыгына карамастан, «тәрҗемәче – авторның көндәше» икәнлеген дә онытмыйча (әсәрнең теле, урысча язган төрки әдипләргә хас булганча, шактый катмарлы), бу эшкә һич авырсынмый, яратып керештем. Инде менә асыл әдәбиятны бәяли белгән һәм аны күпмедер дәрәҗәдә юксынырга өлгергән укучыларыбызга, барыбыз да көтеп ала торган «Безнең мирас» журналы аша, олуг әдипнең тагын бер шаһ-әсәре аның ана телендә барып ирешер дигән өметтә калам.

P.S. *Әсәрнең тәрҗемәсенә тәнкыйди фикер-теләкләрегезне белдереп, valeevtx@mail.ru электрон адресына язсагыз, рәхмәтле булыр идем.*

Мөдәррис Вәлиев ■

Безнең мирас №5 май 2017

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

ӨЧ АНКЕТА

1964 елда (ае-көне мәгълүм түгел. – Л.Л.) Язучылар берлеге идарәсе Бөек Ватан сугышында катнашучы әдипләргә «Әдәби мирас» дигән баш астында анкета сораулары тапшыра. 13 сораудан торган әлеге анкета русча язылган һәм аңа җаваплар да шул телдә бирелгән. Минем архивта өч әдипнең (Г.Бәширов, Ш.Маннур, Х.Госман) җаваплары саклана. Шуларны укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәм.

Ләбиб Лерон

БИО-БИБЛИОГРАФИК МӘКАЛӘ ӨЧЕН БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЧЫ ЯЗУЧЫЛАРГА АНКЕТА-СОРАУЛАР

1. Фамилия, исем һәм этисенең исеме.
2. Әдәби кушаматы.
3. Туган елы (вафат булганнарның үлгән вакыты да күрсәтелә).
4. Партиялелеге.
5. Милләте. Нинди телдә иҗат итә?
6. Хәрби чины.
7. Совет Армиясе сафларында кайсы елларда булган? Кем сыйфатында? Кайда, кайсы фронтларда? Язучы буларак нинди бурычлар үтәгән?
8. Сугышта турыдан-туры катнашуы. Кайда? Кайчан? Яраланганмы? (Сугышта һәлак булучыларның кайчан, кайда һәм ничек үлүе хакында язарга.)
9. Сугыш вакытында кайсы фронт газеталары белән хезмәттәшлек иткән? Кайчан? Нинди псевдонимнар белән?
10. Сугыш вакытында нинди бүләкләргә лаек булган?
11. 1941-45 елларда нинди китаплары дөнья күргән?
12. Сугыш елларында матбугат битләрендә һәм җыентыкларда игътибарга лаек нинди әсәрләре басылган?
13. Сугыштан соң хәрби темага нинди әсәрләр язган?


ВОПРОСЫ ДЛЯ БИО-БИБЛИОГРАФИЧЕСКИХ ЗАМЕТОК
О ПИСАТЕЛЯХ - УЧАСТНИКАХ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ

I. Фамилия, имя и отчество

2. Литературный псевдоним

3. Год рождения (для умерших и дата смерти)

4. Партийность

5. Национальность. На каком языке пишет?

6. Военное звание

7. С какого времени и по какое был в Советской армии в годы войны? В качестве кого? На каких фронтах, когда? Какие задания выполнял в качестве писателя?

8. Участвовал ли в боевых действиях? Где? Когда? Был ли ранен? (для погибших на войне: когда погиб, где, при каких обстоятельствах).

9. В каких газетах сотрудничал в годы войны? Когда? Под какими псевдонимами?

I0. Какие правительственные награды получил за годы войны? Когда? За что?

II. Какие книги изданы в I94I-45 гг?

I2. Какие значительные произведения опубликованы в эти годы в газетах, журналах, сборниках?

I3. Какие наиболее значительные произведения написаны после войны на военном материале?





2

9. В годы войны я работал главным редактором Татрадиокомитета и сотрудничал в областных газетах.

10. Медаль „За доблестный труд в Вел. Отечественной войне 1941-1945 гг."

11. В Таткнигоиздате изданы отдельными книгами в 1941-45 гг. сборник военных очерков „Месть", рассказов и очерков „Гармонист" (на тат. языке). В Воениздате в соавторстве с композиторами А.С. Ключаревым и Я. Агишевым выпустили на русском и тат. языках сборник татарских песен (для бойцов-фронтовиков)

12. Ответил в п. 11.

13. Все, что сумел написать в годы войны было опубликовано в газетах и журнале (литературно-художественном) „Совет эдэбияте" (на тат. языке).

14. В 1947 году издал роман „Честь" о самоотверженном труде тружеников села во время Великой Отечественной войны.

15 VIII – 1964 г.
г. Казань.

Г. Баширов

Гомәр Бәширов һәм аның култамгалы язуы

ГОМӘР БӘШИРОВ ҖАВАБЫ

1. Бәширов Гомәр Бәшир улы.

2. Г.Бәшир, Г.Разин.

3. 1901 ел.

4. 1928 елдан КПСС әгъзасы.

5. Татар, татар телендә язам.

6. Өлкән политрук, өлкән лейтенант.

7. 1942 елның августында КПССның Татарстан өлкә комитеты кушуы буенча Төньяк-Көнбатыш фронтына караган «Ватан өчен» татар газетасы редакциясенә командировкага бардым. Шул елның октябренә кадәр анда очерк язучы сыйфатында хезмәт куйдым, ягъни офицерлар һәм солдатларның сугышчан батырлыклары хакында әдәби очерклар яздым, хәлиткеч һөҗүмнәр алдыннан офицерларга һәм солдатларга тарату өчен татар телендә листовкалар язарга булыштым, сугышчылар белән очрашып сөйләшү өчен алгы сызыкларга бардым. Безнең армиянең бер һөҗүме алдыннан фронт политидарәсе күрсәтмәсе нигезендә рус милләтеннән булмаган сугышчылар арасында агитатор булып йөрдем, аларга дошманга каршы көрәштә Совет Армиясенең хәрби эшчәнлеге турында аңлаттым.

8. Сугыш хәрәкәтләрендә турыдан-туры катнашмадым.

9. Сугыш елларында мин Татрадиокомитетта баш редактор булып эшләдем һәм өлкә газеталары белән хезмәттәшлек иттем.

10. «1941-45 елларда Бөек Ватан сугышында күрсәткән фидакарь хезмәте өчен» медале.

11. 1941-45 елларда Таткнигоиздатта «Үч» дигән очерклар, шулай ук «Гармунчы» дигән хикәяләр һәм очерклар җыентыгы басылды. Воениздатта композиторлар А.С.Ключарев һәм Я.Агишев белән бергә фронтовик-сугышчылар өчен рус-татар телләрендә татар җырлары җыентыгы төзеп чыгардык.

12. 11 нче пунктта җавап бирдем.

13. Сугыш чорында язылган барлык язмаларым да газеталарда һәм «Совет әдәбияты» журналында басылды.

14. 1947 елда тылдагыларның сугыш вакытында үз-үзләрен аямыйча хезмәт итүләре турындагы «Намус» дигән романымны бастырдым.

Имза
15 август, 1964 ел.
Казан шәһәре.



Западный, Калининский, III Белорусский. С января по октябр. 1942; с октября 42 по декабрь 1943; с февр. 44 г. по октябрь 1945 г. (соответственно). Ведал отделами редакции газет.
8. Не участвовал. Не ранен.
9. Газ. „Боевой призыв" орган 61 армии; „Вперед на врага" (на тат. языке) Калининского фронта; „За счастье родины" – газета 83 гв. дивизии 11 гв. Армии. И в татарских газетах и журналах Казани.
10. ~~Орден „Красная Звезда", медали~~ ...
„За Кенигсберг", „За победу" и т. д.
12. „Парень из нашей деревни", „Слава победителям" (сборники стихов) и много фронтовых очерков.
13. Все они являются значительными. Писал под огнем.
14. Книга стихов „Мелодии годов", поэма „Девушка из Казани" и др.

Шәйхи Маннур һәм аның анкетага җавабы

ШӘЙХИ МАННУР ҖАВАБЫ

1. Маннуров Шәйхи Фәрхулла улы.

2. Ш.Маннур.

3. 1905.

4. КПСС әгъзасы.

5. Татар. Шул ук телдә.

6. Капитан.

7. 1941 елның 23 декабреннән алып 1945 елның 18 октябренә кадәр. Әдәби хезмәткәр. Көнбатыш, Калинин, III нче Белоруссия. 1942 елның гыйнвареннан октябренә кадәр; 1942 елның октябреннән 1943 елның декабренә кадәр; 1944 елның февраленнән 1945 елның октябренә кадәр (тиешенчә). Газета редакцияләре кушканны үтәдем.

8. Катнашмадым. Яраланмадым.

9. «Сугышчан чакыру» («Боевой призыв») газетасы – 61 нче армия органы; «Алга дошманга каршы» (татар телендә) – Калинин фронты газетасы; «Ватан бәхете өчен» («За счастье Родины») – 11 нче гвардия армиясенең 83 нче гвардия дивизиясе газетасы. Шулай ук Казанда чыга торган газета һәм журналлар.

10. «Кызыл Йолдыз» ордены, «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Кенигсберг өчен», «Җиңү өчен» медальләре һ.б.

11. (Бу пункт күрсәтелмәгән).

12. «Безнең авыл егете», «Җиңүчеләргә дан». (Шигырьләр җыентыгы). Һәм сугышка нисбәтле бихисап очерклар.

13. Алар барысы да игътибарга лаек кебек.

14. «Еллар моңы» дигән шигырьләр китабы, «Казан кызлары» поэмасы.

Имза.

ХАТИП ГОСМАН ҖАВАБЫ

1. Госманов Хатип Госман улы.

2. Хатип Госман.

3. 1908.

4. КПСС әгъзасы.

5. Татар. Татар телендә.

6. Рядовой. Сугыш ахырында – гвардия капитаны.

7. 1941 елның 15 июленнән 1946 елның 30 апреленә кадәр Совет Армиясе сафларында булдым. Башта артиллерист – разведчик-күзәтүче. Артилле-



ное выполнение заданий командования по полит. обеспечению операций.

11. ——

12. Издана книги: „Бой на границе" – ~~1942 году~~ написания на передней линии и выпущена Полит. упр. Сев.-Зап. фронта в 1942 году; книга „На линии огня" (на татарском языке) – в Казани в 1943 году; „Пламенное сердце" (на тат. яз.) – Казань, 1943 году.

13. Опубликованы очерки (о героях сражений) в газетах „Ватан өчен", „Совет Татарстаны", в журнале „Совет әдәбияты" и т.д.

14. Сборник рассказов.

Хатип Госман һәм аның култамгасы

рия полкы штабы писаре. 1941 елның декабреннән 188 нче укчы дивизия командованиесе кушуы буенча дивизиянең барлык сугышчан операцияләре турында кәгазьгә теркәп бардым. 1942 елның апреленнән – «Дошманга таба» дивизия газетасы хезмәткәре. 1942 елның июненнән – Төньяк-Көнбатыш фронтның «Ватан өчен» («За Родину») газетасында тәрҗемәче. 1944 елның сентябреннән сугыш беткәнчегә тиклем – Үзәк командованиенең резервтагы 1 нче гвардия аерым инженер-сапер бригадасы хезмәткәре. Бригаданы операцияләргә әзерләү эшендә катнаштым. Бригада белән бергә 2 нче Белоруссия фронтындагы барлык бәрелешләрдә (Наревтан (Нарев – Польшадагы елга. – Л.Л.) Померниянең Гюстров каласына кадәр) катнашырга туры килде.

8. Наревтагы немец оборонасын өзүгә нисбәтле сугышчан хәрәкәтләрдә һәм Данцигны (хәзер Гданьск. – Л.Л.) штурмлауда катнашатым. Яраланмадым. 1944 елның 30 октябрендә Плша (Польша) елгасы янындагы сугышчан операция вакытында контузия алдым.

9. «Дошманга таба», «Ватан өчен» газеталары белән хезмәттәшлек иттем.

10. 1943 елда татар телендә «Ватан өчен» газетасын оештыруда һәм чыгаруда катнашкан өчен «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале; 1945 елда командование кушканны сугышчан операция вакытында уңышлы башкарып чыккан өчен – «Кызыл Йолдыз» ордены.

11. (Сызык сызылгын. – Л.Л.).

12. Басылып чыккан китаплар: «Чик буендагы сугыш» – фронтның алгы сызыгында язылды һәм Төньяк-Көнбатыш фронтның политидарәсе тарафыннан 1942 елда бастырып чыгарылды; «Ут сызыгында» һәм «Ялкынлы йөрәк» (икесе дә татар телендә) – 1943 елда, Казанда басылды.

13. Сугыштагы геройлар турындагы очерклар һ.б. «Ватан өчен», «Совет Татарстаны» газеталарында, «Совет әдәбияты» журналында басылды.

14. Хикәяләр җыентыгы.

Имза.

*Анкеталарны басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде* ■

Безнең мирас №5 май 2017

Гадел Кутуй Згеж госпиталендә. 1945 ел



ГАДЕЛ КУТУЙ
(1903-1945)

Тарихта «Җидегән» исеме белән мәгълүм, соңыннан ачыкланганча, дөньяда бөтенләй булмаган яшерен милли-сәяси оешмада әгъза булып торуда гаепләнеп, утызынчы еллар башында Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) һәм тагын биш «җидегәнче» (Н.Исәнбәт, Г.Минский, С.Кудаш, Т.Ченәкәй, С.Агиш – күрәсез, исеме җисеменә дә туры килми, «Җидегән»нең җиденче әгъзасын махсус органнар «уйлап таба» алмый) җавапка тартыла. Гадел Кутуй, каләм хезмәте белән яшәү мөмкинлегеннән мәхрүм калып, шактый еллар мөгаллимлек итәргә мәҗбүр була. Бары тик 1935 елда, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повесте басылгач кына, әдипнең абруйлы исеме яңадан матбугатка әйләнеп кайта.

Ватан сугышы башлануга, Гадел Кутуй үзенең каләмен көрәш коралына әверелдерә: патриотик шигырьләр («Озату җыры», «Партизанка», «Батыр каберендә», «Яңа ел бүләге» һ.б.), «Рәссам» (1941), «Хәнҗәр» (1941) кебек хикәяләр, «Патриот Тукай», «Партизаннар», «Җиңү хәбәрчесе» сыман зур күләмле мәкаләләр язып бастыра.

1942 елның июнендә фронтка китә. «Батырлык өчен» медале, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Сугыш бетәр алдыннан, 1945 елның язында, сәламәтлеге начараеп, хәрби госпитальгә эләгә һәм 15 (яисә 16) июньдә Польшаның Згеж шәһәрендә вафат була. Шәһәр зиратының хәрбиләр участогында, 35 нче санлы кабергә җирләнә.

Красноармейскую книжку иметь всегда при себе. Не имеющих книжек — задерживать

1. Фамилия Кутуев
2. Имя и отчество
3. Звание и должность красноармеец
4. Наименование части (учреждения) 72. О.Т.М.Д. 80 Г.М.П.
5. Наименование подразделения (батальон, рота) 2ᵃ Батарея
6. № личного знака
Личная подпись владельца книжки

Место для фотокарточки владельца книжки

Командир ~~роты~~ батареи
«21» июня 1942 г.
(Место печати части)

I. Общие сведения

1. Номер военно-учетной специальности
2. Грамотность и общее образование (если окончил техникум, рабфак или ВУЗ, то указать его название) Высшее
3. Национальность Татарин
4. Год рождения 1903 г.
5. Год призыва (указать также — нормальный или досрочный призыв)
6. Каким военкоматом призван
7. Специальность до призыва Писатель Журналист

3

Язучының кызылармеец кенәгәсе. 1942 ел

Язучы Ибраһим Газиның 1945 ел 18 июль датасы белән шагыйрь Әхмәт Ерикәйгә язган хатыннан өзек китерик[1]:

«Эш болай: кышкы һөҗүм вакытында (ягъни, Висладан алып Одерга кадәр) Кутуй танковый корпуста безнең газетаның[2] корреспонденты булып эшләде. Һөҗүм тукталып торганда, ул кире редакциягә кайтты һәм шул кайтудан инде китә алмады. Баштарак ул һич авыру төсле түгел иде[3]. Чандыр, ябыграк, ләкин гел шат, көләч, шаян. Озакламый без Познаньга күчтек. Ул авырый башлады. Ләкин ул үзе дә, без дә, җитди авыру белән авырыйдыр, дип уйламадык. Ятты, йөрде, эшләде. Шул хәлендә «Хәнҗәр» дигән хикәя язды, газетага гел катнашып килде. Зарлану аның гадәтендә юк иде.

Ябыкты. Әмма үзенең ябыгуын тешләре юклыктан, рәтләп ашый алмавыннан күрде. Ясалма тешләр (протез) ясатып алды.

«Инде хәзер тазарам!» – дип йөргәндә генә, бөтенләй урыннан тора алмый башлады. Аның болай һаман кирегә китүен күреп, без аны госпитальгә салдык. Госпитальдә 2-3 атна ятып, бик эче пошып, ул кире чыккан. Аны якын-тирәдәге ниндидер госпиталь-санаторийга җибәрергә уйлаган булганнар, ул риза булмаган, тизрәк чыгып, безнең Познаньдагы квартирабызга кайтып яткан. (Без инде күчкән идек.) Познаньга аның янына барсам, күрәм: Гадел һич яхшы якка үзгәрмәгән: төсе юк, ашамый, йөрми. Мин аңарга үзебезгә, редакциягә кайтырга тәкъдим иттем: «Нарат урманы, менә дигән һава, ашау яхшы, кызыл аракы күп», – дип мактадым. Ул көнне мин юлаучы машиналар белән аны алып китмәдем (ул турыда уйларга да ярамый иде). Бер-ике көннән аны алып кайттылар. Ул миңа ярыйсы гына күренде. Көлеп, сөйләшеп ятты. Икенче көнне иртә белән завтракка алып барырга дип керсәм, Гаделне танырлык түгел: битләре җилсенгән, төсе юк, сөйләшми, кәефе гаять начар. Кат-кат төренеп, башына малахай киеп, линотип бүлмәсендә боегып утыра.

– Әйдә, ашарга барабызмы, – дисәм:

– Туңам, хәлем юк, – дип җавап бирде.

Аңа завтрак алып кайтып бирергә кушып, ятып йокладым. (Төн буе газета чыгарган идек.) Мин төшке ашка торганда, ул инде юк иде. Аны ашыгыч рәвештә госпитальгә озатканнар.

[1] Автор орфографиясе һәм пунктуациясе саклана.
[2] «Кызыл Армия» фронт газетасы.
[3] Гадел Кутуй һөҗүм вакытында бик каты салкын тидерә, әмма барыбер сугышның алгы сызыгына чыгып репортажлар әзерләвен дәвам итә.

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

НКО ☆ СССР

ПОЛИТИЧЕСКОЕ УПРАВЛЕНИЕ
1-го БЕЛОРУССКОГО ФРОНТА

ОТДЕЛ

№ 25 „8“ января 1945 г.

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Пред"явитель сего МЛАДШИЙ ЛЕЙТЕНАНТ КУТУЙ, АДЕЛЬША НУРМУХАМЕТОВИЧ состоит на действительной военной службе в РЕДАКЦИИ газеты "КРАСНАЯ АРМИЯ" в должности КОРРЕСПОНДЕНТА-ОРГАНИЗАТОРА.

В виду отсутствия стандартных бланков, выдано настоящее удостоверение взамен постоянного удостоверения личности.

Действительно по 1-е марта 1945 г.

...ИК ПОЛИТУПРАВЛЕНИЯ 1-го
...ЕЛОРУССКОГО ФРОНТА
...РАЛ-ЛЕЙТЕНАНТ /ГАЛАДЖЕВ/

При отсутствии обязательно ссылаться на мое *

«Кызыл Армия» газетасында эшләү таныклыгы. 1945 ел

Беркадәр вакыттан соң без (Гариф Гали[4] һәм мин) ул ята торган госпитальгә бардык. Сорашабыз.

– Аны күчерделәр, – диләр.

– Кая күчерделәр?

– Тылга, Польшага.

Мин госпитальнең канцеляриясенә кердем. Сорадым. Безгә бер адрес, дөресрәге, госпиталь номеры, бирделәр.

– Нәрсә белән авырый? – дидем.

– Туберкулёз, – диделәр.

– Нинди туберкулёз: ачык формасы яки ябык формасымы?

– Ачык.

Мин икеләнә калдым. Познаньда, аны рентген белән карап, аңардан туберкулёз тапмаганнар иде. Эчебез пошып, күңелсезләнеп, кире кайтып киттек.

Ул бөтенләй без эзләгән җирдә түгел, ә Лодзь янындагы бер госпитальгә җибәрелгән булып чыкты. Язган хаты өметсез түгел иде. Туберкулёз турында бөтенләй телгә дә алмаган, тик биле авырту турында гына әйткән һәм тиздән терелүе хакында язган иде.

«Туберкулёз түгел икән, булса, бездән яшермәс иде», – дип өметләндек. Хатлар яздык. Берлинга күчеп, байтак торгач, хатларыбыз кире кайтты. Аларның тышына: «Выбыл по неизвестному адресу», – дип язылган иде.

Без: «Тагы да каядыр озатканнар икән, әллә илгә кайтып киттеме?» – дип торганда, кайгылы хәбәр килеп төште. Кутуй 16/V-45[5]нда вафат. Ярмәки[6] язган хатның конвертына кәгазь ябыштырып, госпитальдән шулай дип язып җибәргәннәр. Гариф Гали бөтенләй белеп кайтырга дип китте. Ул 20/Vләрендә кайтса, син әлегә бик шауламый тор. Чөнки, кем белә, госпитальдә хаталану азмыни. Берәр буташтыру булып чыкса, кирәксезгә куркыту һәм кайгы салу булмасын...»

Әдәбият:

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.741-742.
2. Ибраһим Гази хатлары // Мәдәни җомга. 4 сентябрь 2015. Б.9.

*Язманы **Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

[4] Гариф Гали (Гариф Закир улы Галиев, 1903-1985) – татар совет язучысы.
[5] Гадел Кутуй июньдә вафат була.
[6] Шагыйрь Зыя Ярмәки (Зыя Шәйхи улы Насыйров, 1887-1965) булса кирәк.

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

ОЛУГ ӘДИПКӘ БӘЙЛЕ КАЙБЕР ИСТӘЛЕКЛӘР

Лирон Хәмидуллин

Ибраһимовлар гаиләсе Ялтадагы танышлары белән. 1929 ел

1960-1980 елларда, Татарстан Язучылар оешмасында һәм китап нәшриятында эшләгәндә, миңа Галимҗан Ибраһимовның хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдова (ул 1940 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде) белән еш аралашырга туры килде. Һәм мин аның Галимҗан Ибраһимов язмышын һәм иҗатын чагылдырган өч документаль повестен берләштергән ике китабын («Эзләнүләр», 1987; «Олы юл», 1994) редакцияләп чыгарган идем.

Гөлсем Мөхәммәдова – 1903 елда Әстерхан шәһәрендә җитеш бер гаиләдә туган кыз. Яшьли үк аңа татарның байтак кына күренекле шәхесләрен, шул исәптән Габдулла Тукай белән Сәгыйть Рәмиевне дә күрергә насыйп булган. Шәһәргә килгән зыялы кешеләрне Давыт бәй Мөхәммәдовның кунакчыл гаиләсе, зур мәҗлес җыеп, кунак итмичә җибәрми торган була. Ә кайберләре аларның иркен йортының махсус мансарда бүлмәсендә яшәгән дә. Шагыйрь Сәгыйть Рәмиев тә алар өенең өске кат бүлмәсендә берникадәр вакыт яши. 1911 елда Габдулла Тукай Әстерханга кунакка килгән вакытта да аның Гөлсем

Гөлсем Мөхәммәдова улы Рөстәм белән. Ялта. 1929 ел

апалар йортында аерым бүлмәдә яшәгән чагы була. Петербург консерваториясендә җыр сәнгате үзенчәлекләрен үзләштерә башлаган, тәүге тапкыр Идел буйлап гастрольгә чыккан җырчы Мәрьям Искәндәрова да шул ук елда Гөлсем апаларда кунак булып китә. (Кызганыч ки, бу матур тавышлы җырчының зур түнтәрешләрдән соңгы язмышы бөтенләй ачыкланмаган. «Мин гимназиядә укыган елларда әле аның исеме телгә алынгалый иде», – дигән иде Гөлсем апа.)

Өй шартларында мөселманча-татарча, шәһәр гимназиясендә русча һәм бер кыш Әстерхан медицина институтында укыганнан соң, Гөлсем Казан университетының медицина факультетына күчү теләге белән зур юлга чыга. Казанга килә. «Олы юл» китабының «Көньяк кызы» бүлегендә шул вакыйгалар тасвирлана. Биштәрендә берничә дәреслек китабы һәм олуг әдипнең «Безнең көннәр» романы белән авторына тапшырылырга тиешле ике хат та була. Гөлсем, ул язучыны ничек эзләп табармын да, аңа дигән хатларны кайчан тапшырырмын икән, дип борчылып йөргән көннәрдә генә Галимҗан Ибраһимовның университетка киләчәге ачыклана. Ул студентларга Каюм Насыйри турында нотык сөйләячәк икән. Шушы танышу бераздан соң яңа гаилә коруга китерәчәк. Бер-ике ел үткәч, уллары Рөстәм туачак. «Галимҗан белән

Гөлсем Мөхәммәдова кызы Сөмбел белән. 1960 нчы еллар

Өммегөлсемне чиксез бәхетле дә иткән, фаҗигале аерылышуга да этәргән бердәнбер бала инде ул», – дип искә алыр иде өлкән буын язучылар. Катлаулы үпкә чиреннән беркадәр савыктыру өчен, Галимҗанга Ялта хастаханәләрендә берничә операция ясала. Ул, берникадәр тернәкләнеп, дәртләнеп язу эшен дәвам итәргә керешкәч кенә, бала фаҗигасе аны кабат аяктан ега.

Янә Гөлсем апа истәлекләренә күз төшерик: «*Рөстәм 1926 елның ноябрендә туды. Ул чакта әтисе Гульрипштә (Кавказ) дәвалана иде...*» Бала бик зиһенле була. Өч яшьтән татарча да, русча да сөйләшә, зурлар белән дә иркен аралаша. 1931 елның мартында бала кинәт авырый башлый. Участок врачы: «Салкын тигән, бер-ике көннән үтәр», – ди. – Шуннан соң әтисе: «*Ялтаның иң атаклы педиаторын чакыртты. Ул да: «Ике-өч көн өйдә ятар да, терелер», диде*», – дип яза Гөлсем апа. Ә бала 21 мартта вафат була. Дүрт яшь тә дүрт ай ярым яшәгәннән соң, Рөстәмнең дифтерия авыруыннан үлүе ачыклана.

Укучыга тәкъдим ителгән фотоларда без Рөстәм Галимҗан улы Ибраһимовны да күрәбез. Бу фотолар икесе дә 1929 елда Ялта шәһәрендә төшерелгән. Зур күмәк фотода Рөстәм атасының аяк очында уйнап утыра. Галимҗан белән Өммегөлсем арасындагы арткы рәсемдәге бала Гозәеровлар улы булса кирәк. Гөлсем апа алдындагы кыз – аның бертуган сеңлесе, кунак кыз. Галимҗанның уң ягындагы хатын – аның туганнан-туган сеңлесе Рәйхана. Артта ул хатынның ире Батыр Гозәеров, 1929 елдан Ялтада китап нәшриятында эшли. Аның истәлек язмасы «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» китабына кергән (1966). Илленче елларда Б.Гозәеров шушы фотоның үзендә сакланган нөсхәсен Татарстан Язучылар союзына, Гомәр Бәшировка атап Үзбәкстаннан җибәргән була. Ул нөсхәне миңа туксанынчы елларда Гөлсем апаның кызы Сөмбел Мөхәммәдова күрсәтте. Ул елларда алар ире Ралиф Сафин белән КДУда укытып йөриләр иде.

Икенче фотода Гөлсем апа улы Рөстәм белән. Арткы якта «1929 ел» дигән язу да бар. Өченче фотода Гөлсем апа кызы Сөмбел белән төшкән. Алтмышынчы еллар фотосы булырга тиештер, мөгаен. Гөлсем апаның өстәл өстендәге бер папкада 1920-1930 елларга караган фотолар байтак иде. Араларында матбугатта чыкмаганнары да булгандыр. Хәзер аларның кемдә саклануын әйтә алмыйм. Соңгы вакытта Сөмбел белән Ралиф Пионер урамында яшәделәр. Гөлсем апа фатирында аларның кызлары белән кияүләре яшәде бугай.

Апрель, 2017 ■

Безнең мирас №5 май 2017

Очучы Салих Баттал.
1930 ел

БАТТАЛ БУЛУЫН ОНЫТМАДЫ...

Фәрит Баттал

Шагыйрь һәм драматург Салих Баттал 1905 елның 5 августында элекке Казан губернасы Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Әләксәй районы) Зур (Олы) Тигәнәле авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Аның бертуганнары – Ләйлибәдәр, Галимҗан, Мөбарәк, Габдулла (тарихта ул җәлилче Абдулла Баттал булып калды) һәм минем әти Фуат (1920 елгы).

Ачлык башлангач, Салих, апасы белән җизнәсенә ияреп, Мәскәү өлкәсенә китә, анда төрле эштә эшли. 1927-1929 елларда Ленинградтагы хәрби теория мәктәбендә, 1928-1929 елларда – Оренбург һава сугышы мәктәбендә укый, 1929-1933 елларда – очучы булып Брянск һәм Казан шәһәрләрендә, ә 1933-1935 елларда – П.И.Гроховский җитәкчелегендә Махсус конструкторлык бюросы каршында оештырылган сынау отрядында хезмәт итә. (Җөмләдән, шул бюро СССРда һава десанты гаскәрләренә нигез сала.)

Батталның әсәрләре белешмәлекләрдә китерелгәнгә, бу язмада ул темага тукталып тормыйм, язучының үзе турында белгәнемне сөйләп китәм.

Әти-әнине генә таныган яшьтә үк сеңелем Фәридә белән без Салих абыйдан бүләкләр ала идек инде. Башта ул безгә бала коляскасы табып биргән. Бусы минем истә түгел. Ләкин пычкы чүбе белән тутырылган, чыбык каркаслы кара эт алганы хәтердә. (Кырык ел узгач, оныта алмыйча, Фәридә шул уенчыкка охшаган чын кара пудель сатып алды хәтта.)

Бу вакытта Салих абый Казанның Бутлеров урамындагы 20 нче йортта тора иде. Без 1961 елда шул урамга күчкәндә ул, опера театры артисткасы Мәдинә апа белән өйләнешеп, Гагарин урамына күченде. «Яңа» йортыбыз да утын ягып җылытылганга, без мунча урынына еш кына аларга – барлык уңайлыклары, ваннасы булган квартирага йөри идек. Барыбыз да юынып, ашап, чәйләр эчеп алганнан соң, өлкәннәр сөйләшеп китә. Бала-чага исә Салих абый ясаган уенчык үлчәү (җылыту торбасына таякчык бәйләнгән, таякчыкның ике ягында – шырпы кабы – «тәлинкәләр») белән мәш киләбез. Бәхеткә, ул безгә шактый вакыт уйнарга җитте.

Озакламый шундый кызык уйлап тапты: «Миңа массажны кем ясар икән?» – дип, урынына ятып, өстеннән йөрергә тәкъдим итә иде. Гәүдәгә җиңел булсак та, авырттырырга мөмкинбез, дип уйлап, акрын, сикермичә, стенага тотынып, гәүдәсе-аяклары буйлап йөри идек. Әтиәни безне мактый, билгеле, ә Салих абый, ләззәтләнгән булып: «Уф, рәхәт!» – дип кабатлый. Мондый «массаж» ясауны без «Салих абыйны таптау» дип атый идек. Әлбәттә, үсә төшкәч таптавыбыз бетте. Ул вакытка бу эшне башкалар яхшы ук башкара башлады. Улы яшендәге егетләр, сабыйлардай «өстән» дәртләндерелеп һәм Салих абыйны кайгыртуларына нык ышанып, аны тырышып таптадылар.

Салих абый архивында 1980 елда Әдәби фонд директорына язылган гариза бар. «Батый ханга мөрәҗәгать» поэмасы аркасында күргән матди авырлыкларын телгә алып, ул биш йөз сум акча сорый һәм: «Ә инде мораль яктан күргән газапларны бертөрле үлчәү белән дә күрсәтеп бетерерлек түгел. Ничә мәртәбә үземә кул салу чигенә җиттем, ләкин «немец шпионы» яласы тагылган һәм Капланның агулы пулясы белән яраланган бөек Ленин үрнәге мине коткарды», – дип өсти.

Таптаучылар никадәрле үчексәләр,
Шулкадәрле мине күбрәк үрчеттеләр.

Советлар Союзы таркалганда Салих абый кебек кешеләрне җәберләү программасының мәгънәсе юкка чыкты. Шулай да, аның өстеннән миңа тагын бер мәртәбә йөреп алырга туры килде. Бу юлы туры мәгънәдә...

Салих абыйның табутта күмелүен белепме, кабер казучылар ләхет алмаган иде. Әрәм булмасын өчен, ләхет такталарын барыбер куярга хәл иттек. Кабергә мин төштем. Табутның бер ягына җирне сибә тордылар, ә мин, урын биреп, тегендә-монда күченеп йөрдем – Салих абыйны соңгы мәртәбә «таптап»...

Сабыйлыкта Салих абыйлар Фәридә белән мине чиратлап үзләрендә кунарга калдыра иде. Бер тапкыр сеңелемнән шактый ук көнләштем. Чөнки Мәдинә апа аны «Евгений Онегин» операсына алып барган. Фәридә, әлбәттә, анда йоклап киткән һәм «дуэль» вакытында пистолет «аткан» тавышка гына уянган.

Бутлеров урамына күченеп өч ел узуга, фатирыбызга су һәм газ үткәрелде, аңа да карамастан, Салих абыйларга кунакка йөрүебезне киметмәдек – шәһәрдәге «кышкы» фатирларына да, бакчаларына да. Безнең белән бергә күп чакта Са-

лих абыйның улы Виктор абый да килә иде. Энесе Мөбарәк абый да кушылып, сугыштан исән кайткан өч туган бергә җыелгач (берсе – әтием инде), вакыт бик күңелле уза иде. (Ләйлибәдәр апалары монда сирәгрәк, күп вакытта бездән аерым йөргән. Ул 1981 елда бакыйлыкка күчте.)

Бакчасында Салих абый күп нәрсәне үз кулы белән ясый иде. Дачаның бер почмагында – фонарь баганасына беркетелгән верстак торды, йорт алдында – чарлау станогы, участок үзәгендә – кечкенә бассейн.

Өйләрендә ике генә кешелек урын булгач, без башта палаткада куна идек. Соңыннан Салих абый искесенә терәп гипсолит плитәләреннән зуррак йорт, ә шушы ике йорт каршына тактадан кечкенә мунча корып куйды. Мунчаның алты почмагы булып, әти аны Америкадагы бишпочмаклы «Пентагон»га охшатып, «Алтыгон» дип атады. Иске өй янында яшенүткәргеч тора иде. Яңгырлы төндә яшен яшьнәп күк күкрәгәндә, өй эче балкып-балкып алганда, без – әни, сеңелем, мин – озак йоклап китә алмый идек.

Бакчада җиләк җыю, җир казу, су ташу кебек йөкләмәләр булмаганда мин, рөхсәт алырга ашыгып, Салих абыйның язу машинкасында башыма килгән теләсә нәрсәне басарга ярата идем. (Хәзер бу машинка аның туган авылы Олы Тигәнәле музеенда саклана.) Дүртенче сыйныфта укыганда Жюль Вернга ияреп һәм аның «Серле утравы»ннан берничә персонаж исемен күчереп, роман язам, дип игълан иттем. Бу «бөек» әсәрне мин Салих абыйның чирек табак кәгазьләрендә кулдан яза идем. Көлгәнен сиздермәскә тырышып, ул миннән вакыт-вакыт: «Йә, романны язу эшең ничек бара?» – дип сорап, төп геройның язмышы белән кызыксына иде. Ул әсәрем әле дә иске дәфтәрләр арасында ята.

Шул ук вакытта мин шигырьләр дә язып маташтым. Әти-әни моны күреп, аларны Салих абыйга күрсәтергә күндерде. Минем белән бергә үзенең берничә юлын Фәридә дә күрсәтергә булды. Аның әсәре мондыйрак иде:

Без абыем белән югалттык
Сары саплы мылтык,
Аннары аны таптык.

Минем бөтен язганым унике битле дәфтәрнең яртысын тәшкил итте. Эчтәлеге ягыннан сеңелемнән ерак китмәгән идем: Куба башлыгы Фидель Кастро, ошаган уенчык, песи, бәлеш пешерү... Салих абый шигырьләремне мактады, язуымны дәвам итәргә киңәш бирде. Арадан берсен тыңлап көлгәч, архивымда калдырам, дип, җыеп та куйды хәтта. Ләкин Фәридә югарырак бәягә лаек булды, чөнки аның бу кыска «шигыре»... татарча иде. Аныкын тыңлап бетерүгә үк Салих абый елмайды: «Моны, мәсәлән, шулай дәвам итеп булыр иде:

Булды шундый шатлык,
Без алдык та аттык!»

Яңа чыккан китапларын Салих абый да әти-әнигә бүләк иткән, әти үзе дә аларны кибеттән сатып алган. 1959 елда Фәридә белән икебезгә Александр Пушкинның «Руслан и Людмила»сын биргән иде ул, 1982 елда хатыным Кадрия белән миңа «Тылсымлы балдак» исемле җыентыгын һәдия кылды. 1971 елда әти Салих абыйдан «В небе Чукотки» (Магадан нәшрияты) китабын алып кайтты. Аны утызынчы елларда Салих абый белән бергә Махсус конструкторлык бюросы каршындагы очу отрядында самолетлар сынаган Михаил Каминский язган иде. Автор берничә биттә Салих абыйның төгәл психологик портретын биреп, аны мактап уза. Виктор абый да безгә килгән саен букинистика кибетеннән берәр китап алып килә иде. Шулар арасында бая телгә алган Жюль Верн романнары да булды.

Дачадан поездда кайтканда мин һәркемнән үзем төзегән кроссвордны чишүләрен үтенә идем. Бигрәк тә Салих абый алдында мактанасым килә. Ул җавапны шул мизгелдә үк таба алмаганда, уйга бирелеп, акрын-акрын гына бай биографиясен барлый, истәлеккә чума һәм... кроссворд Казанга кайтып җиткәндә дә чишелмичә кала. Бу хәл мине гаҗиз итә иде. Моңа шатланып, ишеткәнемне хәтергә сеңдерә барасы калган лабаса!

Мәдинә, Нурфигаль (мәкалә авторының әнисе), Салих. 1967 ел

Син тарих дәреслекләреннән генә белгән күренекле шәхесләр турында аларны үз күзе белән күргән кеше авызыннан ишет әле! (Алар турында алга таба сүз булыр...)

Вагон көпчәкләренең рельслар тоташкан урында шакылдавы сезгә берәр нәрсәне хәтерләтәме? Колхозлар оештырылган заманнан ук Салих абыйга ул тавыш: «Кол-хоз-га кер! Кол-хоз-га кер!» – дигән агитация сүзләрен искә төшерә иде.

Салих абыйның хәтере шәп, акылы үткен иде. Дәһри (атеист) булса да, әти юри сорагнда, Коръән сүрәләрен баштан гарәпчә укып, мәгънәләрен безгә аңлата иде. Сорау биргән кешене бүлдермичә тыңлап бетерә. Җавап биргәндә башта яхшылап уйлый, аннары әңгәмәдәшкә карамыйча, күзләрен ярым йомып, ашыкмыйча темага бәйле белгән бар нәрсәсен бәян кыла.

Салих абый атеист булып китүенең сәбәпләрен күрсәтә. Мәсәлән, алты-җиде яшендә ул, әтисе күрше Урта Тигәнәле авылы базарына җыенганда, аннан чана сатып алырга сорый һәм, үтенече тормышка ашсын өчен, догалар укый. «Ләкин теләгем кабул булмады. Алып кайтмау гына түгел, эти каршына чана турында сорашып баргач, ул мине берсүзсез сугып тәгәрәтте», – дип яза үзе. Ярты битен бәйләп кайткан әтиләре белән ни булуы соңрак беленә: тишеге юкмы икәнен тикшерер өчен, ул күңеленә яткан комганның эченә өреп караган һәм... кышкы салкында авызы тимергә ябышып каткан икән. Комганнан аерылгач, авыртуга чыдаргамы, чана турында уйларгамы?!

Элек дингә ышануыңны икърарлау күңелсезлеккә китерергә мөмкин иде, хәзер «динсез», «атеист» дип әйтү начар сыйфат сыман кабул ителә. Ни гаҗәп: Салих абый дин тотучыларга ихтирамлы иде. Намаз укуны файдалы эш саный иде – физзарядка ясау бит! Хәмер белән мавыкмады, иң авыр, кыерсытылган елларда, саф исеме кайтуына ышанычы беткәндә генә салгалады. Гадәттә, ул бакчасында үскән карлыган йә кура җиләген шикәр белән изеп, килеп чыккан төнәтмәне берничә көннән эчеп чикләнә иде.

Мин кунакта якын бер дустымда.
Якын тоелды ул тагын да,
Чөнки исерткечнең тамчысын да
Ул куймаган иде табынга.

Сала торган кеше шундый юллар яза алыр идеме? Киресенчә, Гомәр Хәйям шикелле шәрабка мәдхияләр яудырыр иде...

Салих абыйның элек тәмәке тартуын беләм идем. Әмма үзем бер генә мәртәбә

Безнең мирас №5 май 2017

күрдем: ресторанга чакырып бәйрәм иткәндә төтенне божралап чыгаруы белән шаккаттырды ул мине.

Салих абый беркайчан да бакча йортының ишеген бикләп йөрмәде. Теләсәләр, барыбер ватачаклар, дип, җил ачмасын өчен генә эчтәге биген элде. Ә биккә бәйләгән бауның икенче очын стенадагы тишек аша чыгарып, кыска язу калдыра иде: «Товарищи воры! Просьба дверь не ломать, она не заперта. Чтобы открыть ее, потяните за веревочку». Өйне тар-мар ук итмәсәләр дә, кайбер караклар барыбер тәртип бозып китә иде. Лампалы зур радиоалгычын урлаганнан соң, Салих абый каракларга каршы үтемле чара уйлап тапты – җиңел җыела торган карачкы ясады: иң очлары яшерелгән җылы фуфайка, киң кырыйлы эшләпә аның якасын ярым каплап куя, ике күн итек... Янәшәдә балта ауный – эшләпә турысындагы идән сыман, ул да «кан»га (чынлыкта, кайнатмага) буялган. Карачкыны җыю гади булып күренсә дә, кеше гәүдәсе пропорцияләрендә төзелгәч, аны чын мәеттән аеру авыр иде. Бервакыт Фәриданең кечкенә кызы Гүзәл моны күреп: «Анда абый ята!» – дип атылып чыкты.

Абыйның сөенче алганын да хәтерлим: «Менә, курай ясадым, «Галиябану»дан беренче өч нотаны да уйнарга өйрәндем, бүтән барып чыкмый әле...» Ләкин шул өч нотаны ике мәртәбә безгә уйнап күрсәтте дә, кураен җыеп куйды ул. Музыка белән шөгыльләнгәнен бүтән күрмәдек.

1973 елның августында Салих абыйны туган көне белән котларга килгәндә, ул күчәргә утыртылган күп шестерня һәм рычаглы җайланма көйләп маташа иде. Безне күргәч: «Мин дулкыннар көче белән хәрәкәт итә торган механизм ясадым, – дип сөйләп китте. – Дулкыннар рычаглар очындагы калкавычларны күтәреп, күчәргә беркетелгән винтны боралар да, бөтен җайланма кузгалып китәргә тиеш. Мин моны «волноход» дип атадым». Күпме кыстаса да, без бу җайланманы су буена алып төшеп сынаудан баш тарттык.

Салих абый туган көннәргә әһәмият бирми иде. Чын күңелдән ихтирам итеп, ел саен котларга килсәк тә, өендә туры китермичә, еш кына кире кайткаладык. Соңыннан аның үз йомышлары белән чыгып киткәнлеге ачыклана иде...

Сүз ара сүз чыкканда, әти: «Абый! Сиңа бүген таныш самолетыңны бирсәләр, очып китә алыр идеңме?» – дип сораштырды. «Ник оча алмаска? Җиңел, хәзер үк, барысын хәтерлим бит...» Әти белән без моңа әлләни ышанмадык. Ләкин үзе ышанып сөйләгән, күрәсең, юкса:

...Әйләнәсем килә Җир шарын.
Тик гомерем калды бик кыска...
Очыр, илем, мине космоска!

– дип язмас иде.

М.Н.Каминский, авыру сәбәпле очмаган очучыларны терелеп эшкә чыкканнан соң берничә көн буе мөстәкыйль очуларга җибәрмиләр, дип күрсәтә. Бәян кылынган вакытта Салих абый егерме ел очмаган, яше алтмышны узган иде инде...

Ачуын китергән кешеләр белән Салих абый бәхәсләшергә, араны бозарга ашыкмады. Бакча ызанын узып, өлешенә кергән күршесенә дә бернәрсә әйтмәде. «Ник дәшмисең?» – дип сораган әтигә: «Әйтмәвем миңа файдалы», – дип җавап бирде. «Монда нинди файда булуы мөмкин соң?» – «Минем честный икәнем күренә...»

Салих абый үз күзе белән күргән, очраткан мәшһүр кешеләр арасында кемнәр генә булмаган! Илнең беренче мәгариф наркомы А.В.Луначарский, беренче сәламәтлек саклау наркомы Н.А.Семашко, В.И.Ленинның хатыны Н.К.Крупская, испан революционеры Долорес Ибаррури, Болгария коммунистлары башлыгы Г.М.Димитров, Арктиканы өйрәнүчеләрнең берсе И.Д.Папанин, Ерак Көнчыгышка тукталыш ясамыйча очып җиткән П.Д.Осипенко белән М.М.Расковаларның чыгышларын тыңлаган ул, Төньяк котып аша Америкага җиткән очучы, «һава хулиганы» В.В.Чкаловка кунакка барган. Бервакыт Салих абыйның: «Мәскәүдә Горькийны тыңларга йөри идек», – дигәнен ишеткәч, аптырап калдым: Максим Горь-

Безнең мирас №5 май 2017

Туганнар җыелгач. Сулдан уңга: Мөбарәк, Фуат, Виктор, Салих, Фәрит. 1971 ел

кий күптән үлгән, аны мәктәптә «узалар», ә Салих абый – менә, минем алдымда, исән-сау тора, ничек ул данлыклы урыс язучысын күрә, тыңлый алган? Бу соравымны Салих абый: «Ник Горькийны тыңларга йөрдең?» – дип аңлады, ахры – гади мәсьәлә турында сүз барган кебек: «А как же, классик бит!» – дип кенә җавап бирде. Казанда ул Һади Такташны күргән, Ялтада Галимҗан Ибраһимов белән танышкан, бу очрашулар турында Салих абый үзе дә язган, аның сүзеннән эти дә көндәлегенә теркәгән. Муса Җәлил хәтта якын дусты булган. 1957 елда Кави Нәҗми үлгәннән соң, Хәсән Туфан болай дип язган:

Таянырга минем кем бар тагы
Нәҗмидән соң дәвам итешли?
Талантлы да, дус та, ләкин кырыс,
Металл хисле Баттал что ли?

Сибгат Хәким 1979 елда Салих абыйга шундый юллар кергән хат җибәргән:

Шагыйрь ул колын ташлаган
гаепле байтал кебек,
яки ул кире һәм үҗәт –
баш бирмәс Баттал кебек.

Берсендә эти белән сөйләшкәндә Салих абый: «Миңа Девятаев килеп китте», – дип ычкындырды. Шулай ук адашы – атаклы композитор Сәйдәш белән аралашып яшәгән.

Сара Садыйкова архивында Салих Баттал юллаган хат бар. Анда сүз «Җүләрең көтә сине» шигыре турында бара: «Сара ханым! Композитор буларак лирика – сезнең амплуа бит! Минем дә бу әсәр – лирик ачкычта язылган, бәлки сезне бер көй язарга рухландырыр? Сәлам белән: С.Б. Адресым...» Бу үтенеч җавапсыз калган, дип белдерде композиторның кызы Әлфия апа Айдарская.

Салих абыйның күренекле танышлары моның белән генә чикләнми, билгеле. Ул «Зоркий» фотоаппараты ярдәмендә бик күп мәгълүм замандашларын рәсемгә төшереп калган. (Аннары әлеге фотоаппарат безгә бүләк ителде. Озак файдаланганнан соң – 2002 елда аны авыл музеена тапшырдык.)

...Салих абый белән аралашкан шәхесләр турында язып бетердем генә, икенче бер танылган композиторның улы – телестудиядә музыкаль режиссер булып эшләгән Эмиль Александрович Ключарев очрады: «Карале, мин радио фонотекасында эти белән Салих Баттал сөйләшкән язмага юлыктым, ул сезнең туганыгыз түгелме?» Җавабымны ишеткәч, әңгәмәдәшем яхшы ук таныш җөмләне әйтте: «Беләсеңме, Салих Баттал белән минем эти якын дуслар булган!»

Ахыры киләсе санда ■



МИНЕМ БЕРЕНЧЕ ТЕАТРЫМ

Наил Дунаев,
Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

«Театр» дип аталган могҗизаның асыл мәгънәсен мин шактый соң аңладым әле...

Әү беренче тамашаны үсмер чагымда ук күрдем.

Көзге көннәрнең берсендә: «Күрше Кадер авылына Минзәлә театры килгән!» – дигән хәбәр ишеттек. Кичкырын, көтүләр кайткач, авыл клубында театр уйналачак икән.

Көн кичкә авышты, без – авыл малайлары, хәзерге футбол җанатарлары кебегрәк төркемгә җыелып, театр күрергә («спектакль карарга» дип тә әйтә белмибез) дип, бер-беребезне узыша-чаба, үзән-болыннар аша Кадергә «очтык».

Ул заманнарда дөньяны балачакта ишеткән әкиятләр, укыган китаплар, радио тапшырулары аша гын күз алдына китерә идек. Әле бу якларда нефть, газ чыкмаган, тирә-як болыннарны, инеш буйларындагы әрәмәлек-камышлыкларны мазут басмаган, каз өерләре нефтькә батмаган чип-чиста чаклар иде. Күз ачып йомган арада калкып чыгып, тирә-як авылларын үзләренә суырып алган шәһәр-калалар да юк иде. Керсез күңелле авыл халкының, артык зур хыялларга бирелмичә, үзе дә сизмәстән туган төбәкнең матурлыгына, табигатенә сокланып, тыныч кына гомер кичергән чаклары иде...

«Театр» төшенчәсен һәркем үзенчә күзаллагандыр. Минем күңелемдә ул сурәтләп бирә алмаслык, әкияти бер дөнья – Тукайның «Кисекбаш»ындагы Дию пәрие сарае кебегрәк, затлы-сихри бер бина сыман тоелды.

Менә килеп җиттек. Әле көтү дә кайтмаган. Ләкин клуб алды умарта күче кебек гөжләп тора. Бөтен тирә-як халкы бирегә җыелган, диярсең.

Ниһаять, урам тутырып, акыра-бакыра, мал-туар кайтты. Урам тузаны бераз басылгач, клуб ишеге ачылып, аның төбенә бер өстәл чыгарып куйдылар да, халыкны эчкә уздыра башладылар. Ишеккә ябырылдык. Шулвакыт бер абзый чыгып, җәмәгатьнең тынычланганын көтте һәм: «Спектакль бушлай күрсәтелми, теләгән кеше билет алып керә ала», – диде.

Билгеле инде, без фәкыйрь малайларның берсендә дә акча юк иде. Дусишләрем ишек төбен спектакль ахырына кадәр сакласа да, берсе дә керә алмаган. Беренчедән, клуб эченә керерлек түгел, шыгрым тулы; икенчедән, бусага төбен каравыллап торучы абзый спектакльнең ахырына кадәр урыныннан кузгалмаган. Ә мин исә...

Мине инде, акча түләп, җизни алып керде. Озын-озын эскәмияләргә кысылышып утырдык. Бик тыгыз булды. Кеше күплектән, клуб эче кызып, тирләп пештек.

Ниһаять, баягы таныш абзый чыкты. «Кадерле тамашачылар! Без бүген сезгә *(авторның исемен хәтерләмим. – **Н.Д.**)* «Йөз миллион» дигән пьеса буенча куелган спектакль күрсәтәбез!» – диде ул. Пәрдә ачылды. Сәхнә ул заманда безнең авыл өйләренә якын да тормаганча бай итеп җиһазландырылган зиннәтле фатир рәвешендә иде. Күпертелгән урын-җир өстендә ябык, күгәргән йөзле бер ир-ат ята. Гаять кызгандым үзен. Клуб эче бик бөркү булса да, тора-бара ияләнелде. Спектакльнең эчтәлеге, интригасы халыкның игътибарын үзенә тартып алды. Авыл халкы «ыһ» та итмичә вакыйгалар өермәсенә кереп китте.

Бүгенге көндә спектакльнең һәр детален хәтерләмим, билгеле. Иң кызыгы шунда – теге затлы урын-җирдә авырып яткан «күгәргән йөзле» адәм жулик булып чыкты. Анысы истә.

Спектакль тәмамланды, пәрдә ябылды, аннары яңадан ачылды. Уйнаучылар алга чыгып баш иделәр, исемнәре белән аталдылар. Авыл халкы артистларның һәммәсен хуплап кул чапсалар да «Күгәргән йөзле» артистка карата гына

Минзәлә театры коллективы

чиный-чиный, ду килеп, ләгънәтләр белдерделәр. (Уйнаучыларның бер-икесе генә хәтердә калган: Мөхит Кичүбаев, Мөхәррәм Зәйнуллин...)

Минзәлә театры куйган тамашада хыялымда күрергә теләгән «могҗизалар»ны күрмәсәм дә, шушы беренче караган спектакль, күңелемә кереп калып, гомер онытылмаслык эз салды.

Инде үзем артист булып эшли башлагач, беренче мәртәбә спектакль караган хатирәләремне хезмәттәшләргә дә сөйләдем. Шунда Камал театрының баш администраторы, соңыннан Күчмә театрның директоры булып эшләгән драматург Сәет Шәкүров: «Ул жуликны мин уйнаган идем бит», – дип көлеп куйды. Мин аны «чын жулик булуы» белән ихлас күңелдән котладым.

Сиксәненче елларда Мәдәният министрлыгының махсус комиссиясе составында миңа Минзәлә, Әлмәт театрларының иҗат тормышы, репертуары белән якыннанрак танышып кайтырга насыйп булды. «Солдат хатыны», «Алыштыргысыз хатын» спектакльләрендә яшь артистлар – кыңгырау кебек чыңлап торган Әлфинур Хисамова, Зәйтүн Яркәев, Венера Нигъмәтуллиналарның иҗат башын күреп кайттым...

Шөкер, Минзәлә театры нинди генә авыр, газаплы елларда да сүнмәс учак, сәнгать йолдызын даими биеклектә тоткан якты маяк булды, даны Татарстан авыл-шәһәрләренә генә түгел, күрше төбәкләргә, Россия, бөтен Советлар Союзына таралды. Бу хакта сөйләгәндә театрның киң кырлы репертуарын («Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Уракчы кыз», «Өйләнү», «Шайтан шәкерте», «Бирнәсез кыз», «Хәят», «Упкын читендә», «Ардуан батыр», хәзерге репертуарындагы «Сөннәтче бабай», «Упкын» спектакльләрен һәм шул шедеврларны бар иткән искиткеч талантлы, фидакяр сәнгатькярләрне (Сабир Өметбаев, Хәдичә Сәлимова, Гомәр Калинин, Мөхәррәм Зәйнуллин, Мөхит Кичүбаев, Мулланур Мостафин, Әнвәр Фәсхетдинов, Барый Әшрәпов, Нәсимә Җиһаншина, Мөнәвәрә Нигъмәтҗанова, Рәшит Мәрдеханов, Анатолий Богатырев, Илүсә һәм Фәиз Бәдриевләр, Рузилә һәм Рөстәм Муллиннар) олы хөрмәт белән искә алам. Бүгенге көндә театрны җитәкләгән «хуҗалар» – Роберт Шәймәрданов белән Дамир Сәмирхановка рухи ныклык һәм сабырлык, коллективка үзара аңлашып яшәү, татулык, иҗат юлында бердәмлек теләп, язмама нокта куям.

Данлыклы театрга сәнгать юлында тагын да югарырак үрләргә ирешү насыйп булсын! ■

Безнең мирас №5 май 2017

«Син сазыңны уйнадың... »

Эльмира Каюмова

Саз (саратов гармуны) һәм кабал/кавалда (бубен) уйнау. Р.Якупов фотосы. «Түгәрәк уен» фольклор фестивале вакытында төшерелгән. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондыннан.

Әстерхан татарларының формалашу тарихы гаять катлаулы. Ул Төрки каһанлыгы заманнарына ук барып тоташа. Юрт/йорт татарлары (яисә кариле нугайлары) һәм кундырау татарлары төп халык булып санала. XVII гасырдан алып, Әстерхан җирлегенә Идел-Урал якларыннан казан татарлары, мишәрләр һ.б. күченеп килә. Биредә татарлар белән бергә карагашлар (элегрәк алар татарлар исәбенә керсә, хәзер исә нугайларның бер өлеше итеп санала), казакълар һәм төрекмәннәр дә яши. Озак вакытлар бергә аралашып яшәгәнгә күрә халык музыкасы өлкәсендә тыгыз бәйләнешләр, уртаклыклар барлыкка килгән. Әлеге күренеш уен коралларында да сизелә.

XX гасырда әстерхан татарларының көнкүрешендә саз һәм кабал/кавал аеруча киң кулланыла. Кызыгы шунда ки, «саз» исеме кыллы музыка коралына түгел, ә саратов гармунына (сирәгрәк – тальянга) карата әйтелә. Гомумән, «саз» – күптөрле мәгънәгә ия булган төшенчә. Татарларда ул оста кешене, көйне дә аңлаткан (көй мәгънәсендә казакъларда хәзер дә йөри).

Саратов гармунында уйнаучыны «сазчы» диләр. Башкаручылар арасында ирләр дә, хатын-кызлар да булган. Музыка белгече Наилә Агдеева (Гайнуллина) мәгълүматлары буенча, сазда ешрак хатын-кызлар уйнаган. Гармуннарны туй вакытында кәләшнең дус кызларына өләшү – махсус гадәткә кергән[1]. Уен коралларын җитештерүче җирле осталар да булган.

Элек әстерхан татарларында бик үзенчәлекле, башка төбәкләрдә очрамый торган «сазда сөйләшү» дигән күренеш таралган булган[2]. Аерым көй кисәкләре билгеле бер сүзләрне аңлаткан. Аларны белүчеләр шулай саз аркылы яшерен сөйләшкәннәр. Мәсәлән, егет белән кыз музыкаль җөмләләр (ягъни музыкаль шифр) аша очрашу турында килешкәннәр.

«Кабал» (икенче әйтелеше – «кавал») – бубен сыман бәрмә уен коралы. Кысасына тимер (бакыр) тәлинкәләр куелса, кайчакта арткы ягына (өстәмә яңгыраш өчендер, мөгаен) кыңгыраулар да эләләр иде. Кабалда уйнау осталыгын күпчелек ирләр үзләштергән.

Саз белән кабал дуэты – бик тә популяр инструменталь төркем. Репертуарын гаҗәеп кызу тизлектәге, бормалы-сырмалы ритмдагы бию көйләре тәшкил итә. Туйларда, бәйрәмнәрдә «Кияүсый», «Акчатыр», «Шарка-барка», «Залы» кебек әсәрләр уйналган. Стилистик яктан бу үрнәкләр калмык һәм кавказ халыклары көйләренә якын тора.



«Сазда сөйләшү» көе. Сүзләрне җырламыйлар, истә генә тоталар. Ноталар «Әстерхан татарлары җырлары» җыентыгыннан алынды. (Казан, 2007. № 84а. Б.393).

Бүтән якларда саратов гармуны алай ук актив файдаланылмаган. Тальян һәм хромканы күбрәк яратканнар, чөнки өрдергечне ачканда-япканда тавыш югарылыгы үзгәрми. Саратов гармунында уйнарга җайсызрак булса да (күрекне җәйгәндә-кысканда тавыш үзгәрә), аның кыңгыраулы, көчле һәм ачык тембрлы булуы әстерхан татарларының күңеленә хуш килгән. Хәтта татарлар аркылы саз (шулай ук кабал да) Әстерхан төбәгендәге төрки телле кардәшләребезнең (карагаш, казакъ, төрекмән) мәдәниятенә үтеп кергән[3].

Үткән заманнарда думбра, скрипкә, сыбызгы һ.б. музыка уен коралларының кулланышта булуы билгеле.

Ни кызганыч, хәзерге көннәрдә халык коралларында башкару традицияләре югалып бара. Дәүләт Үмәров (татар бию сәнгате белгече, тумышы белән Әстерхан өлкәсенең Кызан авылыннан) фикеренчә, музыка мәктәпләрдә балаларны халыкчан итеп уйнарга өйрәтсәк, уңышлы нәтиҗәгә ирешә алыр идек. Буыннар арасындагы дәвамчылык өзелмәсен иде! ■

[1] Агдеева Н.Г. Инструментальная музыка астраханских татар // Из истории татарской музыкальной культуры. Казань, 2010. С.91.
[2] Нигмедзянов М.Н. Татарские народные музыкальные инструменты // Музыкальная фольклористика. Вып. 2. М., 1978. с.287.
[3] Усманова А.Р. Этномузыкальные параллели татар и тюркских этнических групп (ногайцев-карагашей, туркмен и казахов) Астраханской области: Автореферат дисс. ... канд. искусствоведения. Саратов, 2008. С.17.

Саз (саратов гармуны) һәм кабал/кавалда (бубен) уйнау. Р.Якупов фотосы. «Түгәрәк уен» фольклор фестивале вакытында төшерелгән. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондыннан.

Безнең мирас №5 май 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТАТАР УКЫТУЧЫЛАР МӘКТӘБЕ *тар.* – Укыту нигездә рус телендә алып барылган бу мәктәп (Татарская учительская школа) 1876 елда җирле хакимият тарафыннан, татар авылларына рус гыйлеме тарату максаты белән, Казан шәһәрендә оештырыла. Мәктәп хәзерге Тукай урамында ике катлы кирпеч йортта урнашкан була (73 нче йорт). Мәктәпне рәсми ачу җыелышында Шиһабетдин Мәрҗани дә катнаша һәм анда чыгыш ясый.

Мәктәпнең дүрть еллык укыту программасында рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты, математика, табигать фәннәре, җәгърәфия, тарих, педагогика, исламият, рәсем дәресләре каралган була. Исламият дәресләрен Ш.Мәрҗани, аннары Таиб Гыйльманов бирә, ә педагогик практиканы К.Насыйри алып бара. Рәсем дәресен мәгърифәтче Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров укытканлыгы мәгълүм. 1894 елда гимнастикага отставкадагы фельдфебель Мифтахетдин Шәмсетдинов өйрәткән. Шулай ук биредә Шәрык белгече академик В.В.Радлов, Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы В.А.Богородицкий, тарихи китаплар авторы П.В.Траубенберг, М.Н.Пинегин (рус теле), математик Н.Г.Лексин, «Шәрык клубы» идарәсе рәисе Ибраһим Терегулов эшләгән.

Мәктәпнең беренче директоры (ул инспектор дип аталган) мәгърифәтче Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1876-81 елларда), икенчесе надворный советник Шаһбазгәрәй Әхмәров (1881-1900 елларда) була. Татар укытучылар мәктәбенә 16 яшьлек үсмерләр кабул ителгән һәм дүрт класста барлыгы 90 укучы исәпләнгән.

Вафа Бәхтияровның Фатих Әмирхан турындагы истәлекләрендә бу мәктәп

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.



Татар укытучылар мәктәбе

Ш.Мәрҗани

укучылары һәр кыш Раштуа, Пасха бәйрәмнәрендә берничә тапкыр рус телендә спектакаль куйганлыгы искә алына. Еш кына Гогольнең «Ревизор»ын уйнаганнар. Башлап йөрүчеләр арасында Чанышев, Кудашев, Әхтәриев, Юскаевлар булган. Тамашаны карарга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре дә килә торган булган һәм, табигый, аларда шушындый спектакльләрне татарча сәхнәләштерү идеясе туган.

Мәктәптә белем алып чыккан күренекле шәхесләр байтак. Шулардан Ильяс Ашказарскийны, Гаяз Исхакыйны, Садрый Максудины, Мирсәет Солтангалиевне, Гафур Колахметовны, Сәгыйть Сүнчәләйне, Хөсәен Ямашевны, галимнәрдән Мөхетдин Корбангалиевне, Гыйбад Алпаровны, Гыйлем Камайны, генерал-лейтенант Якуб Чанышевны, тел белгече Риза Газизовны күрсәтергә мөмкин.

Татар укытучылар мәктәбе 1917 елга тикле эшләп килгән. 41 ел эшләү дәверендә аны 396 кеше тәмамлап чыга. Экстерн тәртибендә мәктәпне 134 кеше, шул исәптән 8 хатын-кыз тәмамлаган. 1917 елда ул Татар укытучылар семинариясе итеп үзгәртелгән.

Татар укытучылар мәктәбе ачылып 20 ел үткәннән соң, Казанда рус грамотасына өйрәтә торган 9 уку йорты эшләгән.

Татар укытучылар мәктәбе урта белем бирә торган уку йорты дип исәпләнгән һәм аны тәмамлаучылар, рус-татар мәктәбендә яки мәдрәсә кар-

Ильяс Ашказарский

шындагы рус классында 6 ел эшләгәннән соң гына, югары уку йортына керергә теләкләре уянса, башта гимназиядә белем алырга тиеш булган.

Казаннан соң, «Учительская школа»лар Сембердә (Чуаш укытучылар мәктәбе), Уфада, Бөредә, Унжада (Мари укытучылар мәктәбе) һәм Карлыганда (Удмурт укытучылар мәктәбе) ачылган.

Казандагы «Учительская школа»ны тәмамлаучылар арасында милли культура һәм фольклор белән кызыксынучылар җыйган татар халык әкиятләре мәҗмугасы 1924 елда рус телендә Казанда басылып чыккан. ■

ТЕЛ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Һади Атласи

Бу язмабызда Һади Атласиның 1910 елда «Шура» журналында басылып чыккан «Бай һәм ярлы телләр, югалган төркичә сүзләр» [1] исемле мәкаләсен, гарәп графикасыннан күчереп, укучыларга тәкъдим итәбез. Шулай ук, әлеге хезмәткә бәйле фикерләребез, аның телен тикшереп, XX гасыр башы татар әдәби теле турындагы кайбер күзәтүләребез белән дә уртаклашырга телибез.

Мәкаләнең авторы – мәшһүр галим Һади Атласи (1876-1937) Казан губернасының Буа өязендәге (Иске) Чәке авылында (хәзерге Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә үз әтисеннән ала, аннан соң Буа мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлагач, Оренбург янындагы Сәет бистәсендә мөгаллимнәр курсында гыйлем эсти. 1898 елда Буага кайтып, мәдрәсәдә укыта башлый. 1903 елдан Әлмәт авылында имам вазифасын башкара. 1904-1908 елларда вакытлы матбугатта төрле темаларга мәкаләләр бастыра. 1907 елда II Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлана. 1911-1914 елларда аның тарихи хезмәтләреннән иң күренеклеләре – «Себер тарихы», «Казан ханлыгы» һәм «Сөенбикә» китаплары дөнья күрә. 1920-1929 елларда Бөгелмә мәктәпләренең берсендә тарих һәм немец теле укыта. 1929 елда кулга алына, хөкем ителмәвенә һәм гаебе дәлилләнмәвенә карамастан, Соловкига сөрелә. 1934 елда Бөгелмәгә кайта һәм ярты елдан гаиләсе белән Казанга күчеп килә. 1936 елда кабат кулга алына. 1937 елның октябрендә трибунал карары нигезендә атып үтерелә. Шул рәвешле, болганчык елларда яшәгән һәм иҗат иткән Һади Атласиның хезмәтләрендә һәм шәхси тормышында шул замананың казанышлары да, каршылыклары да, фаҗигаләре дә киң чагылыш таба. (Һади Атласиның тәрҗемәи хәленә кагылышлы мәгълүматлар Сәлам Алишевның «Татар зыялылары» дигән җыентыгында басылган мәкаләсеннән алынды [2, 170-174 б.]).

Һ.Атласиның мәкаләсен гарәп графикасыннан кириллицага күчергәндә, язы-

лыш үзенчәлекләренең барысы да диярлек сакланды. Мәсәлән, хәзер саңгырау аваз хәрефләре белән бирелә торган кайбер сүзләрдә мәкаләдәгечә яңгырау аваз хәрефләре белән язуны калдырдык: күптер – күбдер, булып – булуб, тутыра – тулдыра, катыштырылып – катышдырылыб һ.б. Бары тик бер генә сүзне, дил рәвешендә язылган булуына карамастан, аңлаешлырак булсын өчен, хәзергечә тел дип бирүне кирәк таптык.

Хәзерге телдә бөтенләй кулланылмый торган кайбер гарәп-фарсы алынмаларына һәм диалекталь төрки сүзләргә, җәяләр эченә алып, текстта ук аңлатмалар бирә бардык. Эчтәлеккә кагылышлы кайбер аңлатмаларны тексттан соң кушымтада искәрмәләр рәвешендә бирдек.

Асия Рәхимова

Бер милләтнең зурлыгы ул милләтне тәшкил иткән берәмләрнең күплеге илә булган кебек, бер телнең һәм байлыгы ул телдә сөйләнә торган сүзләрнең күплеге иләдер. Безгә билгеле телләрнең иң байы, һич шөбһәсез, гарәпчәдер. Бу телдәге сүзләр шулчаклы күбдер ки: бер гарәб язучысы икенче телдән һич бер сүз алмаенча әллә ничаклы нәрсә яза ала. Бәгъзе [кайбер] галимләр иң бай тел немесчә, дисәләр дә, немесчә билмәдегемездән, гарәпчә илә аның арасындагы мөнәсәбәтне карый алмыйм. Әмма бер рус, йаһуд [яки] төрек һәм татар язучысы саф үз телендә генә яза алмаенча, әллә ничә телләрдән гарийә [бурычка; кулланып торыр өчен] сүзләр алырга мәҗбүр була. Чөнки үз телендә уйлаганнарын язарлык сүзләр булмаганга вә йахуд булуб да онытылганга күрә, саф үз телендәге сүзләр илә генә максудыны яза алмый. Ләкин шунысы вар: рус язучысы ничаклы әдәби язса да башка телләрдән сүзләр күп алырга вә бинаэн галә [һәм шул сәбәпле] язганының яртысыны йахуд андан да артыгыны йат тел илә язарга мәҗбүр булдыгы хәлдә, төрек-татар язучысы яртысыны вәйахуд [яисә] өчдән ике өлешене йат сүзләр илә тулдырадыр.

Мәзкүр [алда сүз алып барылган] телләр арасында иң ярлысы вә бинаэн галә [һәм шул сәбәпле] гарийәтчесе, шөбһәсез, шимдике [хәзерге] Төркиядә истигъмаль иделә [кулланыла] торган Госманлы теледер. Бу милләтнең теленә караганда, ул мәмләкәтнең атаклы төрек милләтенең утрагы [яшәгән җире] булган Төркия булмаенча, Гарәбстан вәйахуд Аҗәмстан [Иран] булу хәтергә килә. Иң гаҗәбе шунысы: һәр милләтнең теле язучылар күбәйгән

Һәди Атласи

сайен үз телендәге сүзләре арта барып, байый бардыгы хәлдә, госманлы теле гел тарайыб, төрекчәгә ярлыланып килгән. Гарәпчә һәм фарсыча белмәгән, йәйсә ул телдәге лөгать китаплары [сүзлекләре] булмаган бер кеше госманлы төркисене укыб аңлый алмый. Түгел кара халык файдасыны күзәтми язылган гәзитәләрне генә, хәтта халык файдасыны күзәтү фикере илә язылган вә бинаэн галә «демократическая» булган «Сәрбәсти»ләрне [3] дә гарәпчә, фарсыча белмәгән төрек аңларлык түгел. Мәсәлән: «Сәрбәсти»нең 115 нче номерындагы «Эскидән сарайда ижра олунан музалим кәрәмәт бигаять җөмләләр илә тәзийн вә муваффакыйәт сәгадәт айат тәркибләре илә таквиҗ эдилирди...» дигән җөмләсендә саф төрекчә ничә сүз бар? Өч генә түгелме? Шуны гарәпчә, фарсыча белмәгән ничек аңласын? Әмма шул өч юллык сүзләрне

«Шура» журналының 1 нче саны

рус телендә ике генә рус сүзе илә язган гәзитә дә юк, китаб да юк. Рус телендә иске заманда язылган китаблар рус сүзенә бик йарлы һәм дә аңланылмый торган дәрәҗә кыйын булдыклары хәлдә, бу көндәге русча әдәбият һәм тел көнләшерлек дәрәҗәдә яхшы вә шуның илә бәрабәр чын рус сүзләренә байдыр.

Госманлы төрекләре голүм [гыйлем, фән] вә мәгарифдә башка төркиләргә кыяс иделмәз [чагыштырылмас] дәрәҗәдә алда булсалар да, тел бабында [мәсьәләсендә, ягыннан] анлар [алар] бик йарлылар. Госманлыларның ана телләре булган төрекчәне ташлаб, гарәбчә, фарсычадан кушылма бер тел ясауларының сәбәбе һич аңланылмый. Хөкүмәт – Төркия хөкүмәте, милләт – төрек милләте улгач, тел дә төрек теле булырга тиеш иде.

Һәр милләт тәрәккыйга [прогресска] башлаган чагында, үз теленә күп әһәмият вирмиенчә, борынгыдан араларында атаклы булыб калган бер телгә әһәмият виргәнләр, русларның һәм элекдәге язучылары рус телене ишкә санамый, әсәрләрене французча язып маташканнар. Ләкин руслар хакыйкате тиз аңлаб, үз телләрене алга йибәргәнләр вә аны чикдән тыш байытканлар. Госманлылар исә һаман да шул борынгы начар гадәт илә килеб, безнең өчен изге булган төрки сүзләрне күмеб калдыра килгәнләр. Мин үзем чын госманлы мухиббе [яратучысы, яклысы] булсам да, госманлы телене һич сүмим [сөймим]. Анлар сөйләгән төрекчәне төрек теле дип белмим. Аңарга гарәпчә, фарсычадан вә бер аз гына төрекчә дә катышдырылыб ясалган боламык дийеб кенә карыйм.

Русиядәге мөселман төрки кавемләр арасында мишәр теле төркичәгә ничаклы йарлы исә, төрекчәнең әдәби теле саналган госманлыча һәм шулчаклы йарлыдыр. Аерма шунда гына: мишәрләр телләрене руслашдырдыклары хәлдә, госманлылар гарәб-фарсылашдырганлар. Төркиядә төрек телене төзәтмәк өчен бер җәмгыять ясалганлыгы гәзитәләрдә язылды. Язуларыны һәм төзәтмәкче вә шул хакда бер «Язу төзәтү лөгать китабы» ясамакчы булалар икән. Бу бик һәйбәт эш булыр иде. Ләкин китаблары төрек теленә байлыкда русларның «Полный орфографический словарь»лары чаклы була алыр микән? Монысында шик бар.

Аңланадыр ки, госманлы төрекчәсе төрки сүзләргә бик йарлы булганга күрә, аны төрки теле дип булмый. Лиһәзә [шуңа күрә] башка төркиләрне госманлыча язарга димләргә юл юк. Без – татарлар, үземезне госманлы төрекләрдән голүм вә мәгариф алырга шәкерд[лек] идергә тиешле диеп белсәк дә, тел бабында анларга шәкерд булырга ихтыяҗымыз юк. Шулчаклы дияргә мөмкин: Казан телендә язылган китаб вә рисаләләр [журналлар, брошюралар] чын төркичә сүзләргә һаман да йарлы булсалар да, башка төрки телләргә караганда төркичә йарыйсы гына байлар.

Йир йөзендә яшәүче төрки ыруглар телләрене төркиләшдерәселәре килсә, әлбәт хәзерге халык телендәге ушандак [шундый] борынгы төрки сүзләрне әдәбиятка кушып йибәрүгә тиешледер. Үткән йылларда берничә борынгы сүзләр гәзитәләргә кереб, хәзерендә шул сүзләргә тәмам иләшелде [ияләшелде], йәгъни әдәби сүзләр булып китделәр. Борынгы төрки телендә гаскәр вә падишаһлык эшләренә даир [караган] шулчаклы сүзләр

Дәрдемәнд «Шура» журналын чыгаручылар белән. 1909 ел

күбдер ки, анларны алып истигъмәл иткәндә төрек теленең бик бай булачагында һич шөбһә юкдыр. Үз телемездә сүзнең саф төркичәсе булдыгы хәлдә, гарәпчә фарсычадан, ушандак русчадан шул мәгънәдәге сүзләрне алып әдәбиятда истигъмәл итүнең сәбәбе нәрсә икән? Нигә кирәк икән? Мин моны аңлый алмыйм. Хәзерге татар әдәбиятына русчадан алынган берничә сүзләр бар. Ул сүзләр саф русча түгел, руслашкан сүзләр генә булганга күрә, анларны Йаврупадан алынган дияргә дә ярый. Менә шунлар урынына саф төркичә сүзләр истигъмәл итүне тиеш дип беләм. Мәсәлән, нимесчәдән алынып руслашкан, руслардан безгә һәм алынган штраф сүзе урынына чын төркичә булган түләк сүзене, латинчадан алынып руслашкан вә безгә һәм кергән манифест урынына бойрок/бойрог сүзләрене, русчага латинчадан алынган конфискация урынына йаргу/ йаргы сүзләрене, италйанчадан алынып руслашкан шпион урынына узчы/ исгүче/алчык сүзләрене; латинчадан алынып руслашдырылган реформатор урынына илтөзәр сүзене, французча парламент, русча дума сүзләре урынына корылтай/уйлама сүзләрене кабул итүне тиеш дип беләм.

Корылтай рус тарих китабларында еш кына очрыйдыр. Шәех Сөләйман әфәнде [4] һәм: «Корылтай – мөшәвәрә өчен иҗтимаг идән мәҗлес, шура», – дидер. Уйламак (тәфәккер итмәк) масдарындан алынган уйлама илә думаның мәгънәләре арасында ничаклы йакынлык варлыгы лөгать ияләренә мәгълүмдер. Уйлама, тәһи [бушкул калу] вә тыюга дәләләт иткән [аңлаткан, белдергән] уйлама мәгънәсендә улмаенча, иләнә торган урын мәгънәсендә булган «иләнмә»гә охшашлы уйлана торган урын мәгънәсендәдер.

Кайсыбер сүзләр рус лөгать китабларында башка телнеке итеб күрсәтелсәләр дә, мәсәлән, тилмач (толмачъ) сүзене галәм-е лисан [тел] голәмәләрендән [галимнәреннән] Соколовлар, Кремерлар [5] полякча дисәләр дә, ул һәм чын төрки сүзе булырга тиеш. Телем ач, телемне ач димәк булырга кирәк. Анларда ач төрки сүзе диеп истигъмәл иделергә кирәк! [6]

Әгәр милләт бу фикерне кабул итсә, бу хакда тагы да йазгалап, әдәбиятка хәйле [шактый] яңа сүзләр артдырырга мөмкин булыр иде.

***

Һади Атласи әлеге мәкаләсендә, исеменнән үк аңлашылганча, телләр, төрки телләр арасында татар әдәби теленең урыны, сафлыгы, байлыгы турында фикер йөртә. Төрки телләрдән кала, гарәп һәм рус телләрен яхшы белгәнлеге аңлашыла. Болардан тыш: «Бәгъзе [кай-

бер] галимләр иң бай тел немесчә, дисәләр дә, немесчә билмәдегемездән, гарәпчә илә аның арасындагы мөнәсәбәтне карый алмыйм», – дигән сүзләре мәкалә басылган 1910 ел өчен генә дөрес булып чыга. Чөнки С.Алишев мәгълүм язмасында 1920-1929 елларда Һ.Атласиның немец теле укытучысы булып эшләвен әйтә.

XX гасыр башында, татар әдәби теле оешып кына килгән ул чорда, әлбәттә, аның сөйләм төрләре дә, диалектлары да әле өйрәнелмәгән. Алай да, башка төрки әдәби телләр белән чагыштырганда, татар әдәби теленең төрки сүзләргә барысыннан да бай, ә мишәр сөйләшенең рус сүзләре белән артык чуарланган булуы Атласиның дикъкатеннән читтә калмаган. «Русиядәге мөселман төрки кавемләр арасында мишәр теле төркичәгә ничаклы йарлы исә, төрекчәнең әдәби теле саналган госманлыча һәм шулчаклы йарлыдыр», – ди ул.

Һ.Атласи госманлы төрек телен гарәп-фарсы алынмаларына бераз гына төрки сүзләр кушылган «боламык» тел дип атый да, шуңа бәйләп, кызыклы бер фикер әйтә: «Аңланадыр ки, госманлы төрекчәсе төрки сүзләргә бик йарлы булганга күрә, аны төрки теле дип булмый. Лиһәзә [шуңа күрә] башка төркиләрне госманлыча язарга димләргә юл юк. Без – татарлар, үземезне госманлы төрекләрдән голүм вә мәгариф алырга шәкерд[лек] идергә тиешле диеп белсәк дә, тел бабында анларга шәкерд булырга ихтыяҗымыз юк». XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар әдәби теле белән госманлы төрек теле арасындагы уртаклыкларның, ә кайбер каләм ияләренең хәтта бөтенләе белән госманлыча язарга тырышуының бер сәбәбе бу юллардан аңлашылса кирәк.

Телне алынма сүзләрдән арындыру кирәклеге турында сүз алып барылса да, мәкаләдә гарәп-фарсы алынмалары байтак. Бу күренеш әле формалаша гына башлаган милли әдәби телнең, үзендә урынлы, мантыйклы сүзләр булуына карамастан, аларның вазифасын гарәп, фарсы, рус, европа телләреннән алынганнарына тапшыруы кебек җитди мәсьәләне бик ачык чагылдыра. Әйтик, бәгъзе – «кайбер»; гарийә – «бурычка, кулланып торыр өчен»; бинаэн галә – «шуңа күрә, моңа нигезләнеп»; мәзкүр – «алдарак телгә алынган»; истигъмаль – «кулланылыш»; лөгать китабы – «сүзлек»; кыяс итү – «чагыштыру»; мухиб(б) – «яратучы, яклы»; даир – «караган, бәйле»; хәйле – «шактый күп» һ.б. шундыйлар моңа мисал була ала.

Хәзерге татар әдәби телендә бәйлек вазифасын башкара торган һәм сүзенең ул чорларда кулланылыш мөмкинлекләре ачыкланып җитмәгән булуы да күренә. Мәкалә телендә ул күбесенчә да/дә кисәкчәсе урынында кулланылган: ...немесчәдән алынып руслашкан, руслардан безгә һәм алынган (... «немец теленнән алынып руслашкан, руслардан безгә дә алынган») һ.б.ш.

Әлеге алынмаларны XX гасыр башы татар әдәби телендә госманлы төрек теле йогынтысының чагылышы дип тә каларга мөмкин. Атласиның сүзләре белән әйткәндә, «гарәпчә, фарсычадан вә бераз гына төрекчә дә катышдырылыб ясалган боламык» телнең йогынтысы, әлбәттә, угыз төркеменә кергән төрки телләр өчен уртак булган сүзләр яки грамматик шәкелләр алынудан гына гыйбарәт булып калмаган. Билгеле, бу соңгылары да мәкаләдә аз түгел. Лексик берәмлекләр берничә генә: шимдике – «хәзерге», илә – «белән», вар – «бар», вир – «бир», улмаенча – «булмыйча» һ.б. Әмма грамматик шәкелләр еш кулланыла: нимесчә белмәдегемездән – «(без) немецча белмәгәнгә», байый бардыгы хәлдә – «байый барса да», саф төркичәсе булдыгы хәлдә – «саф төркичәсе булуга карамастан» һ.б.ш. Госманлы төрек һәм гомумән төрек теленә хас бу – dığı шәкеле шактый еш кулланылган булса да, татар телендәге параллельләре дә мәкаләдә урын алган: бик ярлы булганга күрә, тиешле дип белсәк дә, алда булсалар да һ.б. Исем фигыль дә, инфинитив дип тә атарга мөмкин булган –мак/-мәк шәкеле дә очрый: ... төрек телене төзәтмәк ичөн бер җәмгыять «... төрек телен төзәтү өчен бер җәмгыять...». Түбәндәге мисалларда исемнең килеш белән төрләнешендә төрек теле үзенчәлекләре чагыла: ха-

кыйкате тиз аңлаб – «хакыйкатьне тиз аңлап», йазганынының йартысыны – «язганының яртысын» һ.б. Моннан тыш, җөмлә төзелешендә дә беркадәр йогынты сизелә. Мәсәлән, исем белән белдерелгән хәбәрнең төрек телендәгечә-дыр кушымчасы алуы (мәсәлән, ... уйлана торган урын мәгънәсендәдер), төрек телендә хәзергәчә еш кулланыла торган җөмлә төрләре очрау (мәсәлән, «Түгел кара халык файдасыны күзәтми язылган гәзитәләрне генә, хәтта халык файдасыны күзәтү фикере илә язылган вә бинаэн галә «демократическая» булган «Сәрбәсти»ләрне дә гарәпчә, фарсыча белмәгән төрек аңларлык түгел») һ.б.ш.

Шул рәвешле, татар әдәби теленең шәкелләнүе чорында, госманлы әдәби теле аңа шактый сизелерлек йогынты ясаган. Һ.Атласи мәкаләсендә дә бу ачык чагылыш таба. Артык күләмле дә түгел бу язма, әмма зур галимнең каләменнән төшкән булганга, аны җитди чыганак дип санарга була. Иң мөһиме: Һ.Атласиның бу хезмәте бер фактны – госманлы зыялыларының башка төрки халыклар әдипләрен дә госманлыча язарга димләүләре, татар әдәби теленә госманлы төрек теленең йогынтысы белән бәйле мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертергә, аның бер сәбәбен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Мәкаләдә хәзерге әдәби тел өчен диалекталь дип саналган, ләкин чорына күрә татар әдәби теле өчен ят булмаган берәмлекләр очрый. Алар арасында, йир йөзендә – «җир йөзендә», кушып йибәрүгә тиешледер – «кушып җибәрергә тиешле», сүмим – «сөймим, яратмыйм», аңланылмый – «аңлашылмый», ушандак – «шундый», утрак – «яшәү урыны» кебек, бүгенге көн күзлегеннән карагандa фонетик, морфологик яисә лексик үзенчәлекләре булган сүзләр бар. Ушандак/ошандак сүзе ушы/ошы/ошо һәм андак сүзләренең кушылуы нәтиҗәсендә килеп чыккан. Бу сүзләр себер татарлары диалектларында һәм эчкен сөйләшендә очрый: ошо – «шул, шушы», андак – «андый» (ТТЗДС, 44, 509). В.В.Радловның сүзлегендә ошандак «таким же образом» мәгънәсендә чагатайчада (иске үзбәкчәдә), отурак «место, где останавливаются; стоянка, станция» мәгънәләрендә чагатай, кырым һәм госманлы телләрендә кулланыла дип күрсәтелә (Радл., I, 2 ч., 1108, 1150).

Шул рәвешле, төрки-татар теленә нигезләнеп тикшергәндә, мәкаләнең шул чор өчен шактый эшкәртелгән, шома әдәби тел белән язылуын билгеләп була. Зур галимнең әлеге хезмәте исә, телне яшәтү һәм яшәртү, аның чит сүзләр белән чүпләнүен булдырмау юнәлешендәге эшчәнлек үткән гасырда җанлы барган, ул хәзер дә тукталмаска тиеш, дигән фикерне куәтли.

Искәрмәләр

1. Атласов Һади. Бай һәм ярлы телләр, югалган төркичә сүзләр // ШУРА, 1910, №7, 206-208 бб.
2. Татар зыялылары: тарихи портретлар. Укытучылар һәм югары сыйныф укучылары өчен мәкаләләр җыентыгы/ Төз. Р.М.Мөхәммәтшин. – Казан: Мәгариф, 2003. – 208 б.
3. «Сәрбәсти»ләр – 1908-1913 елларда Мәвланзадә Рифат Әфәнде җитәкчелегендә Истанбулда чыгарылган «Serbesti» газетасы (Türk Ansiklopedisi. Cilt XXVIII. Milli Eğitim Basımevi. Ankara, 1980. - s.456) һәм шул газетада язмаларын бастырган язучылар турында сүз бара.
4. Шәйх Сөләйман (Бохаралы) (1821/1822 – Истанбул, 1890) – тюркология тарихында «Lugat-i Çağatay ve Türk-i Osmani» (1882/1883) исемле әсәре белән билгеле. Венгр тюрколог Игнац Кунош бу сүзлекне немец теленә дә тәрҗемә иткән – Şejx Sülejman Efendi's Çagataj – Osmanisches Wörterbuch. Budapest, 1902. (Türk Ansiklopedisi. Cilt XXX. Milli Eğitim Basımevi. Ankara, 1981. – s. 273).
5. «Самый полный общедоступный словотолкователь и объяснитель 150000 иностранных слов, вошедших в русский язык, с подробным всесторонним исследованием о значении и понятии каждого слова. Составлен филологами Соколовым и Кремером. Вновь обработал и дополнил по новейшим источникам С.Н.Алексеев. Москва, Типография Н.Н.Булгакова, 1903 г.» исемле хезмәтне әзерләгән Соколов һәм Кремер фамилияле рус телчеләре.
6. Татар телендәге тылмач «переводчик; толмач» сүзе килеп чыгышы буенча төрки һәм монгол телләре өчен уртак булган борынгы тылмачы<тылмарчы/телмәрче сүзенә барып тоташа: борынгы төрки tılmaçı «переводчик» (Древнетюркский словарь, 1969, с.566); монг. хэлмэрч «устный переводчик» <(хэл «язык») (Монгольско-русский словарь, 1957, с. 584, 586).

Кыскартылмалар:

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.
Радл. – В.В.Радлов Опыт словаря тюркских наречий. Т. I, часть 2. Санкт-Петербург, 1893. – С.970-1914. ■

Безнең мирас №5 май 2017

Дени (Денисов) В.Н., Долгоруков Н.А. «Чүкечнең һәрбер сугуы - дошманга удар!». 1941 ел

Ватолина Н.Н., Денисов Н.В. «Телеңне тый!» 1941 ел

ҖИҢҮ ПЛАКАТЛАРЫ

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

Татарстан Республикасы Милли музеенда Бөек Ватан сугышы плакатларының бай тупланмасы саклана. Алар сугыш елларында Мәскәү һәм Ленинград үзәк нәшриятларында, шулай ук Кзанда рус һәм татар телләрендә нәшер ителгән. Совет сәяси плакаты сугышның беренче көннәреннән үк пропаганда һәм агитациянең төп коралы, халыкны фашизмга каршы көрәшкә берләштерүдә үтемле чара булып торган.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.* ■

Әлмәнов Б.М. «Калдырма!» 1943 ел

Сокольский Н.М. «Канга кан! Үлемгә үлем!» 1941 ел.

Сәйфуллин Р.Ф.
«Безнең совет сугышчылары фашист вәхшиләргә каршы ничек сугышсалар, без дә кырдагы эшне шулай эшлик!»
1942 ел.

Казан халкы сугыш башлану хәбәрен тыңлый.
22 июнь, 1941 ел.

Казан, Бауман урамы. Матбугат йорты. XX йөз уртасы

Туфан Миңнуллин йорты

Олы Мәрәтхуҗа һәм...

Т.Миңнуллин салдырган мәчет

Олы Мәрәтхуҗа авылы Кама Тамагы районында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы бистәсеннән 17 км көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда урнашкан. Казан белән Олы Мәрәтхуҗа авылы арасы – 130 км чамасы.

Халкының төп шөгыле – иген игү һәм терлек асрау. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Олы Мәрәтхуҗада мәчет була. XX гасыр башында авылда ике җил тегермәне, мануфактура-бакалея һәм ике вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1782 дисәтинә җир тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 елдан ТАССРның Тәтеш, 1927 елдан Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан – Кама Тамагы, 1963 елның 1 февраленнән – Тәтеш, 1965 елның 12 гыйнвареннан – Кама Тамагы районында.

Туфан чишмәсе

Безнең мирас №5 май 2017

... мәшһүребез Туфан Миңнуллин

Олы Мәрәтхуҗа – Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның (1935-2012) туган авылы.

Абдулла Миңнуллин гаиләсе

ӘТИ

«Юаш иде әти, ләкин үзсүзле, принципиаль кеше иде. Бер генә эшне дә намусына каршы барып эшләмәде».

ӘНИ

«Әнинең балаларына булган мәхәббәтендә аз гына да ясалмалылык юк иде».

Әти янәшәсендә

Мөдәррис Әгъләм

БӘҺАСЕЗ ЗАТ

Әйтәләр бит: кояшта да
Гыйбрәтле таплар була –
Халыкта да мәңге калыр
Бәһасез затлар була.

Андыйлар бездә дә бар ул –
Тарихта кала торган:
Әлдермештән – Әлмәндәр карт,
Мәрәтхуҗадан – Туфан.

«Язмыш минем кулыма каләм биргән. Мин аңа рәхмәтлемен. Ул мине – авылның бер малаен, татарның бер баласын – үз исемемне бүтәннәргә дә ишеттерерлек итеп яшәтте».

Т.Миңнуллин

2015 елда, мәшһүр драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел тулу уңаеннан, Мәрәтхуҗа авылында «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Лотфулла Нурислам** улы **Шәфигуллин** җитәкчелегендә әдипнең музей-йортын төзекләндерү һәм яңарту эшләре башланган иде. Әлеге музей-йорт, тулысынча яңартылып, 2016 елның 25 августында – язучының туган көнендә кабат ачылды. ■



Туфан Миңнуллин музей-йортының эчке күренеше

Безнең мирас №5 май 2017

Ядкярләргә – бер гасыр

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 1 мае

ВАКЫТЛЫ ХӨКҮМӘТНЕҢ ҖИР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ РОССИЯ ГРАЖДАННАРЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ БАСЫЛГАН ЛИСТОВКАСЫННАН



Временное Правительство.

МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЛЕДѢЛІЯ:

граждане!

Лѣса составляютъ громадныя богатства свободной Россіи.

За послѣднее время, къ сожалѣнію, изъ многихъ мѣстностей поступаютъ извѣстія о томъ, что населеніе начинаетъ самочинно производить какъ въ государственныхъ, такъ и въ частныхъ лѣсахъ порубки лѣса, выпасъ скота и другія пользованія, а во многихъ случаяхъ удалять лѣсничихъ, завѣдывающихъ лѣсами и стражу. **Подобное отношеніе къ лѣсамъ**, въ чьемъ бы владѣніи они въ настоящее время ни находились, **неминуемо тяжело отзовется** въ ближайшемъ же будущемъ **не только на интересахъ самого мѣстнаго населенія, но и всего государства.** Лѣса, дающіе кровъ, тепло и заработки мѣстному населенію, могутъ обратится въ пустыри, во многихъ же мѣстахъ отъ вырубки лѣсовъ и пастьбы скота поднимутся пески и начнутъ дѣйствовать разрушительные овраги.

Къ Вамъ, граждане, къ Вашимъ лучшимъ чувствамъ обращаюсь и прошу прекратить самочинныя дѣйствія. Знайте, что новымъ Правительствомъ принимаются всѣ мѣры къ возможно полному удовлетворенію Вашихъ нуждъ въ лѣсныхъ матеріалахъ и пастьбѣ скота За всѣми Вашими нуждами идите къ мѣстнымъ лѣстничимъ, которымъ Временнымъ Правительствомъ даны надлежащія указанія по отпуску лѣса и пастьбѣ скота за умѣренную плату, а въ необходимыхъ случаяхъ и безплатно. Въ случаяхъ необходимости покупки лѣса и пастьбы скота обращайтесь спокойно къ частнымъ владѣльцамъ и завѣдывающимъ ихъ лѣсами и. **помните, что для разрѣшенія всѣхъ вопросовъ,** относящихся къ пользованію какъ въ государственныхъ, такъ и въ частныхъ лѣсахъ **имѣются образуемые вновь Уѣздные Земельные Комитеты.**

Не допускайте же никого производить безпорядки въ охранѣ лѣсныхъ богатствъ, не разводите огня въ лѣсахъ и вблизи ихъ въ неуказанныхъ мѣстахъ. Помогайте тушенію лѣсныхъ пожаровъ и являйтесь на нихъ безъ зова, по долгу гражданъ. **Спокойно ждите созыва Учредительнаго Собранія, которое вмѣстѣ съ земельнымъ вопросомъ разрѣшитъ и судьбу лѣсовъ.** Пусть не скажутъ Ваши дѣти, что отъ лѣсныхъ богатствъ—наслѣдія дѣдовъ и отцовъ—мы оставили имъ пустыри и не помогли Родинѣ въ годину тяжелыхъ испытаній.

Министръ Земледѣлія А. ШИНГАРЕВЪ.

1 мая 1917 года.

Казань. Типо-литографія Губернскаго Правленія.

Гражданнар! Урманнар иректә Россиянең чиксез байлыкларын тәшкил итәләр. Кызганыч ки, соңгы вакытта төрле җирләрдән, халык дәүләт урманнарында да, шәхси биләмәләрдә дә законсыз рәвештә агачлар кисә, көтү йөртә һәм аннан башкача файдалана башлады, урманчылар, урман хуҗалыгы җитәкчеләре, урман каравылчылары бетерелә, дигән хәбәрләр килә. Урманнарга мондый мөнәсәбәт, алар кем карамагында булуга карамастан, якын киләчәктә җирле халыкныкына гына түгел, дәүләт мәнфәгатьләренә дә котылгысыз рәвештә зур зыян китерәчәк.

Җирле халыкка азык, җылылык һәм хезмәт хакы бирүче урманнар ташландык җирләргә әйләнергә мөмкин, урманнарны кисүдән һәм көтү йөртүдән ком өскә күтәреләчәк һәм җимергеч ерганак-чокырлар барлыкка киләчәк. [...]

Урман байлыкларын саклаудагы тәртипсезлекләргә юл куймагыз, урманнарда һәм күрсәтелмәгән урыннарда учак якмагыз. Урман янгыннарын сүндерүдә ярдәм итегез һәм моны, чакырганны көтеп тормыйча, гражданлык бурычы буларак эшләгез. Тыныч кына Учредительное собрание чакырылганны көтегез, ул, җир мәсьәләсе белән бергә, урманнар язмышын да хәл итәчәк. Балаларыгыз киләчәктә, урман байлыкларыннан – ата-бабалар мирасыннан ташландык җирләр генә калдырганнар, Ватанга авыр сынаулар елында ярдәм итмәгәннәр, дип әйтерлек булмасын.

ТР ҮДА ТСД ф.36, тас.1, э.109, 40б.

1917 елның 3 мае

ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ БУЕНЧА КАЗАН ГУБЕРНА КОМИТЕТЫНЫҢ КАЗАН ГУБЕРНАСЫ ГРАЖДАННАРЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Авыл хуҗалыгы эшләрендә эшләүче хәрби әсирләрнең тоту шартларына һәм ризыкка карата артык зур таләпләр куюы, тиешле таләпләргә буйсынмаулары һәм авылдан шәһәргә китеп, эштән баш тартулары уңаеннан, Губерна комитеты, әлеге тәртипсезлекнең булырга тиеш түгеллеген танып, губерна гражданнарына мондый чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать итә:

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.


ОБЪЯВЛЕНІЕ

отъ Губернскаго Исполнительнаго Комитета

Гражданамъ Казанской губерніи.

Въ виду того, что военноплѣнные, работающіе на сельско-хозяйственныхъ работахъ предъявляютъ непомѣрныя требованія въ отношеніи содержанія и пищи, не подчиняются установленнымъ требованіямъ и отказываются отъ работъ, уходя изъ деревни въ городъ Губернскій Комитетъ, признавая такую распущенность военноплѣнныхъ недопустимой, обращается къ Гражданамъ губерніи съ просьбой принять слѣдующія мѣры.

1) Слѣдить за тѣмъ, чтобы плѣнные не оставляли тѣхъ хозяйствъ, куда они направлены для работы, и самовольно не переходили бы къ другимъ лицамъ. Такихъ военноплѣнныхъ необходимо задерживать и возвращать въ то хозяйство или тѣмъ лицамъ, на работу которымъ они были предоставлены.

2) О всѣхъ извѣстныхъ гражданамъ случаяхъ оставленія плѣнными работъ необходимо сообщать или Комитету безопасности или милиціи.

3) Бродящихъ по уѣзду плѣнныхъ, не имѣющихъ при себѣ удостовѣреній о томъ, гдѣ и у кого они находятся на работѣ, слѣдуетъ немедленно задерживать и передавать милиціи или Комитету безопасности.

4) Разъяснять всѣмъ, имѣющимъ у себя на работахъ военноплѣнныхъ, что питаніе плѣнныхъ не можетъ быть лучшимъ, чѣмъ питаніе мѣстныхъ рабочихъ, и что предъявленіе ими непомѣрныхъ требованій и самовольное оставленіе работъ вызоветъ по отношенію къ нимъ самыя суровыя мѣры взысканія.

Исполнительный Органъ Казанскаго Губернскаго Комитета Общественной безопасности.

Казань. Типо-литографія Губернскаго Правленія.

1. Әсирләрнең эшкә җибәрелгән хуҗалыкларны калдырып китмәүләрен һәм үз белдекләре белән башка затларга күчмәүләрен күзәтеп торыгыз. Андый хәрби әсирләрне тоткарларга һәм эшкә билгеләнгән хуҗалыкларга яки затларга кире кайтарырга кирәк.

2. Әсирләрнең эш калдырып китүләренең бөтен очраклары турында да Җәмәгать куркынычсызлыгы комитетына яки милициягә хәбәр итү сорала.

3. Өяз буенча каңгырып йөргән, кайда һәм кемдә эштә булулары турындагы таныклыклары булмаган әсирләрне кичекмәстән тоткарларга һәм милициягә яки Җәмәгать куркынычсызлыгы комитетына тапшырырга.

4. Үзләрендә эштә хәрби әсирләр булган һәркемгә әсирләрнең туклануы җирле эшчеләрнекеннән яхшырак була алмавын һәм аларның артык зур таләпләр куюлары һәм эш урыннарын рөхсәтсез калдырып китүләре кырыс җәзага тартуга китерәчәген аңлатырга.

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 143б.

1917 елның 3 мае

КАЗАН СУД ПАЛАТАСЫ ПРОКУРОРЫ МИРОЛЮБОВНЫҢ МӨРӘҖӘГАТЕННӘН

Казан суд палатасы Прокуроры вазифасын үтәүгә керешкәч, мин, яңа стройны ныгыту өчен, бөтен гражданнарга да, бигрәк тә бүгенге күчеш чорында, барлык чаралар белән дә тәртип кертү һәм урнаштыруның мөһимлеге турында белдерүне бурычым санаем; тәртип булган очракта гына безне Учредительное собраниегә китерәчәк планлы эшне башкарып чыгарга мөмкин. Тәртип булмаганда анархия хөкем сөрәчәк, ә бу – теләсә кайсы ирекнең һәлакәте дигән сүз. Ирек канун кысаларында гына була ала, ә аннан башка, теләсә нинди оешкан җәмгыятьтә, бигрәк тә дәүләттә түзеп тормаслык башбаштаклык урнаша.

Кисәтәм: теләсә нинди провокацион чыгышлар һәм халыкның бер өлешен икенчесенә каршы куярга омтылу, теләсә нинди көч куллану, кайдан килүенә һәм нәрсәгә – шәхескә яки гражданнарның милегенә (үз белдегең белән кулга алу, җирләрне, милекне һәм башка нәрсәләрне кулга төшерү) юнәлтелүенә карамастан, минем тарафтан тайпылышсыз рәвештә эзәрлекләнәчәк, гаепле затлар кичекмәстән җинаять җаваплылыгына тартылачак. [...]

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.109, 3б.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире ***Римма Садыйкова*** *әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның май ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселманнарның фронттан качуы

Мөселман хәрби комитетына штабтан түбәндәге эчтәлектә бер мөрәҗәгать бар иде. Җәяүле һәм атлы гаскәрләрнең начальниклары, солдатлар, бигрәк тә мөселманнарның фронттан качканлыкларын белгезеп, безгә тиешле чараларны кылырга мөрәҗәгать итәләр. «Без, мөселман хәрби комитетына, олуг ышаныч бәян итеп, ватан өчен дә, мөселманнар өчен дә мондый җаваплы минутларда тиеш булмаган агымнарны туктату өчен, тиешле чаралар кылуын үтенеп мөрәҗәгать итәбез».

Мөселман хәрби комитеты, үзенең мәйданга чыккан көненнән бирле, шундый тиешсез агымнарны туктату юлында эшләп ята, соңгы көннәрдә фронттагы һәм тылдагы мөселман гаскәрләренә брошюралар, хитабнамәләр тарату эше белән мәшгуль иде, дип җавап биргән.

Кояш. – 1917. – №1113. – 2 май.

«Сез»ме яки «син»ме?[1]

Мөселманнар «Сез» дигән сүзне бөтенләй әйтми диярлек. Алар моның урынына демократический һәм самимилекне аңлата торган «син» дигән сүзне файдаланалар.

Кабан күлендә пароход йөри

2 нче майдан башлап, Кабан күлендә Казаннан бункерлар бара-китә һәм күл буендагы дачаларга пароход йөри башлады.

Кәләпүшче хатын-кызлар җыелышы

29 апрельдә Рәфиков йортында кәләпүшче хатын-кызларның гомуми җыены булып, берләшергә, берсе арзан вә берсе кыйммәт бәһа белән эшләми, һәммәсенә эш хакы арттыртырга карар бирделәр. Бу карарларны бастырып, кәләпүшче кибетчеләргә таратачаклар.

Кояш. – 1917. – №1114. – 4 май.

Гаскәриләр җомгасы

5 нче майда, Юнысовлар мәйданында мөселман гаскәрләренең гарнизонный җомгасы булды. Җомгага төрле полклардан җыелган солдатлар, лазаретлардан мәҗрухлар һәм мондый кешеләр – барлыгы 3-4 йөзгә якын кеше җыелган иде. Җомганың әүвәлендә әфитсәрләр тәртип саклап йөрделәр. Вакытлы имам җомга алдыннан вәгазь сөйләп, җомга соңында башланган яңгырга карамыйча, кечкенә генә митинг та булып, һәйбәт кенә үтте.

Кояш. – 1917. – №1115. – 7 май.

Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] «Татарлар Мәскәүдә» исемле күләмле мәкаләдән өзек.

Зиярәт туфрагы – дамбага

Шәһәр тарафыннан зиярәт өчен бирелгән җирдән, Екатеринбург вә Казан тимер юлы идарәсе, яңа дамбалар ясау өчен, зиярәтнең балчыгын алып, зиярәтне эштән чыгарып ташлаган иде. Инде бу ел эшләгән дамбаларын су юып бетергәнлектән, дамбаны яңадан эшләү өчен кирәк кадәр балчык вә туфрак алып һәм зиярәтне мәет күмәргә яраксыз итеп калдырмакчы була икән.

Кояш. – 1917. – №1116. – 9 май.

Татар роталарын оештыру

Мөселман хәрби комитеты татар солдатларының тормышын яхшыртуның тиешлеген һәм, мөмкин булганда, һәр полкта татарларны руслардан аерып, аларның үзләренә махсус роталар тәшкил итеп, шул роталарда өйрәтелүләре кирәклеген дә белдереп, штабка мөрәҗәгать иткән иде. Моңа җавапта, татарларны руслардан аерып аерым роталарда өйрәтү полковой командирлар кулында икәнлеге, алар аеруны теләсәләр, штаб тарафыннан каршылык юклыгы бәян ителгән.

Кояш. – 1917. – №1120. – 18 май.

Мөселман чәйханәләрендә хезмәт итүчеләргә

Мөселман чәйханәләрендә хезмәт итүче швейцар, буфетчик вә башка ир вә хатын-кыз хадим вә хадимәләрнең барысы да бу көн, кич 8 сәгатьтә «Амур» мосафирханәсенә чакырылалар. Җыенда сигез сәгать эш вакыты турында чәйханә хадимнәренең хуҗаларга куя торган шартлары сөйләнәчәк. Җыючы – Әхмәд Биктаһиров.

Кызганыч вакыйга

16 нчы майда Кирмән авылының имамы Хәбибрахман әфәнде, авыл мәсҗеденә иганә җыю максаты белән, Казанга килеп, мөселман комитетына барыр өчен, 3 нче номер трамвайга утырып барганда, вагоннан егылып төшеп, башын ярган. Үзен һушсыз хәлдә хастаханәгә илтсәләр дә, анда һушына килә алмый вафат булган.

Мөслимә солдаткалар бюросында

18 нче апрельдә мөслимә солдаткаларның бюро мәҗлесе булып, 17 майда рус вә мөслимә солдаткаларның солдат вә эшче вәкилләре шурасына җыелып барып, теләкләр белдерүләре хакында доклад укылды. Анда солдаткалар паёк арттыруны, сугышны бетерүләрен таләп итеп, «Икмәк һәм солых» дип язылган флаглар белән кергәннәр икән.

Кояш. – 1917. – №1121. – 21 май.

Эшчеләр клубы

Бу көн, кич сәгать 8дә мөселман социалистлары комитеты тарафыннан мөселман эшчеләр клубы ачылачак. Клуб һәр көн, кич 6дан, төнге сәгать 1гә кадәр ачык. Клуб Тихвинский-Варламский урамнары чатында.

Кояш. – 1917. – №1125. – 30 май. ■

---

[2] Тимер юл өчен дамба зират туфрагыннан төзекләндерелгәнме? Бу турыда журналның алдагы саннарының берсендә укырга мөмкин.

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 апрельдә Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча дәүләт комитетында «Тарихи бранч» клубының «Татар гаиләсе 100 ел элек һәм хәзер» дигән темага икенче утырышы узды. Утырышта галимәләр А.Мәхмүтова («XX гасыр башында татар хатын-кызлары һәм җәмгыять»), Э.Сәлахова («Метрикә кенәгәләре битләрендә татар гаиләсе: язылышулар, аерылышулар һәм балалар»), Л.Сәгыйтова («Бүгенге дөньяда татар гаиләсе») чыгыш ясады. Чарада «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон һәм баш мөхәррир урынбасары М.Закир катнашты.

● 3 апрельдә Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында Татарстанның халык шагыйре, «Безнең мирас» журналының киңәшче идарә әгъзасы Разил Вәлиевка 70 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

● 3 апрельдә Арча көллиятендә «Илһам» Россиякүләм иҗат бәйгесенә нисбәтле чара узды. Әлеге чарада жюри әгъзасы сыйфатында язучы-галимә Р. Рахман, галим-журналист В. Гарифуллин һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон катнашты.

● 3-4 апрельдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре – Р.Сәгъди белән Л.Гобәйдуллин Чистай районынның Иске Роман, Каргалы, Яушырмә авыллары мәктәпләрендә очрашуда булды.

● 3 апрельдә Балтач районының Чепья авылындагы «Халыклар дуслыгы» музеенда әлеге музей директоры, Татарстанның мәдәният хезмәткәре, СССР мәгариф отличнигы, Бөек Ватан сугышы ветераны Гарифҗан ага Галиевка 90 яшь тулуга багышланган зур чара узды. Әлеге чарада «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары М.Закир катнашты.

● 7 апрельдә Казандагы 81 нче мәктәптә Яшүсмерләрнең К.Насыйри исемендәге 15 нче төбәкара фәнни-эзләнү укулары булып узды. Анда Башкортстан, Чуашстан һәм Мордовия республикаларыннан, Оренбург, Самара, Ульяновск һәм Төмән өлкәләреннән килгән укучылар да катнашты. Әлеге чарада «Безнең мирас» журналының җаваплы редакторы Ф.Зариф чыгыш ясады.

● 12 апрельдә Чаллы шәһәрендәге С.Садыйкова исемендәге Концертлар залында күренекле язучы Факил Сафинның иҗат эшчәнлегенә 45 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Д Салихов, шагыйрьләр Р.Миңнуллин, Ф.Зыятдинов, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе З.Гыймаев, «Мәгариф» һәм «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррирләре С.Таишева, Л.Лерон, шулай ук Чаллы, Мөслим һәм Түбән Кама районнарында яшәп иҗат итүче каләм әһелләре катнашты һәм чыгыш ясады.

● 13 апрельдә Актанышта һәм Качкын авылында танылган язучы, бакчачы-галим Ф.Зыятдиновка 80 яшь тулуга багышланган иҗат кичәләре булып узды. Әлеге күркәм чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Д.Салихов, «Безнең мирас» журналының һәм «Көмеш кыңгырау» газетасының баш мөхәррирләре Л.Лерон, Ф.Сафин, Татарстанның халык шагыйре Р. Миңнуллин, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе З.Гыймаев, язучы А.Әхмәтгалиева һәм Актанышта яшәп иҗат итүче әһле каләмнәр Ф.Дәүләтбаев, А.Авзалова, Р.Сәлахиев катнашты һәм чыгыш ясады.

● 20 апрельдә Казан шәһәренең 144 нче балалар бакчасында шагыйрь Ләбиб Лерон иҗатына багышланган чара узды. Чарада «Безнең мирас» журналының даими авторы, шагыйрь Р.Мөхәммәтша катнашты.

● 22-23 апрельдә Свердлау шәһәрендә мәшһүрләребез Г.Тукай һәм М.Җәлилгә нисбәтле күркәм чаралар булып узды. Әлеге чараларда М.Җәлилнең кызы Ч. Җәлилова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон катнашты.

Безнең мирас №5 май 2017

«ШАЛТЫР-ШОЛТЫР ШАУЛАТА...»

Әстерханда чыккан «Туп» журналыннан

Әстерханда чыккан «Туп» журналының 1907 елгы 1 саны

***

– Иптәш, син кайсы партиядән?

– Мин бер генә партиядән түгел, әллә ничә партиядән, санап бирә алмассың: трудовик, монархист, черносотенец, социалист, милләтче... тагы әллә ниндәйләр.

– Кит аннан, бер кеше әллә ничә мәсләк тота аламы? Булмый бит ул.

– Ник булмасын, менә мин ресторанга барганда бик ашыгып барам, анда трудовик буламын, пиво эчкәндә бүрекне салмыйм – менә монархист, официант күрмәгәндә, акча бирми качып чыгам – менә черносотенец, атайның кассадан киткәнен көн буена саклап торам – менә шпион, хулиган; кассадан урлап чыккан акчаны бөтен товарищлар бергә эчәмез – менә социалист; бер рестораннан качып чыгарга форсат көткәндә, барачак ресторанымы берлән ике араны уйлап торам – менә милләтче.

– Алай икән.

***

– Әни, әни, күршеләрнең сыеры котырган.

– Ни эшләгән икән соң ул, әллә котырган бүре тешләгәнме?

– Юк, бүре тешләмәгән, моннан 41 көн әүвәл, киленнәренең җидесен укыганда, шул сыерның колагын: «Син дә тиз арадан минеке булырсың», – дип, котырган мулла тешләп киткән икән.

Туп. – 1907. - № 2. – Б.8.

АВЫЛ ХӘБӘРЛӘРЕ

Сүләнкәдә

Сүләнкәдә бер хаҗи иске арбасына яңа күчәр куйдырган. Шатлыкка ун бия суеп, 200 бучка кымыз хәзерләп, бөтен тирә-як мулла, мөәзин, хәлфә вә хаҗиларны чакырып, 4000 сумга төшереп, бик зур бер туй ясады.

Аргы Тияктә

Бер никахта шаһит булырга язу белгән кеше хаҗәт булып эзләгәндә, авылның бер башыннан икенче башына кадәр санап чыксалар да, язу белгән кеше табылмаган.

Туп. – 1907. - № 2. – Б.17.

Гәзитәгә мөштәри алу.
– Әйдә, язып!
– Укый белмим, җаным.
– Белмәсәң дә язып, милләт хидмәте.

Табышмаклар

Шалтыр-шолтыр шаулата, үткеннәрне аулата, юри канны ярата, ганимәт малы тарата. Ул нәрсә?

(Черносотенецлар)

Тамакларын кыргалар, күзләрен дә җомалар. Ходай сазан бирде дип, агызын-башын боргалар. Ул ни?

(Хәзрәтнең бай кеше берлән сөйләшүе)

Бишеккә салып тирбәтә, ләззәт берлән йоклата. Ул нәрсә?

(Муллаларның җомга хөтбәсе)

Җалт-җолт итә, күзгә күренеп китә, гашыйклары – исе килә, дип куаналар, дошманнары – ычкынып китмәсә ярар иде, дип сызланалар. Ул нәрсә?

(Чын хөррият)

Туп. – 1907. - № 2. – Б.18.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Татарстан Язучылар берлеге бинасы 1907 елда төзелгән

«Безнең мирас» елъязмасы / май

• 1095 ел элек (310 һиҗри, 922 милади ел)

21 майда Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кабул ителә.

• 205 ел элек (1812)

Титуляр һәм коллегия киңәшчесе Шаһиәхмәт Мөхәммәд улы Алкин (1812-1878) дөньяга килә.

• 105 ел элек (1912)

12 майда күренекле рәссам, график, монументаль сәнгать рәссамы, педагог, профессор, Үзбәкстан ССРның һәм Татарстанның халык рәссамы Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәров (1912-1995) дөньяга килә.

• 80 ел элек (1937)

8 майда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Конституциясенең проекты игълан ителә.

• 75 ел элек (1942)

27 майда фронтовик-шагыйрь Рәхим Саттар фашистлар кулына әсирлеккә эләгә.

• 70 ел элек (1947)

27 майда Баку радиостанциясе Азәрбайҗан радио тыңлаучылары өчен Габдулла Тукайга багышланган махсус тапшыру оештыра.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы каршындагы тел, әдәбият һәм тарих институтының кулъязмалар бүлегендә 1784 елгы кулъязма китап табыла. Әлеге китапта XVIII йөздә яшәгән һәм моңа кадәр әдәбиятта исеме билгеле булмаган татар шагыйре Рәхимкол Әбүбәкеровның Пугачев хәрәкәтенә багышланган шигырьләре, шул ук темага Габделҗәлил Габделмәннанов тарафыннан язылган тарихи очерк һәм Габделмәннан Мөслимовның шигырьләре тупланган.

• 60 ел элек (1957)

24 май – 4 июньдә Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырыла.

26 майда татар совет балалар шагыйре Бари Рәхмәт (1897-1957) вафат була.

• 50 ел элек (1967)

Татарстан китап нәшриятында урта гасырларның бөек шагыйре Мөхәммәдьяр поэмаларыннан тупланган мәҗмуга дөнья күрә. ■

Мирасворд

Алтын Урдада, татар ханлыкларында хан балаларын тәрбияләүче

1911-1916 елларда Троицкида татар телендә чыккан журнал

Тиз йөрешле, өч мачталы җилкәнле судно

Шагыйрь ... Аитов

Корыган, кипкән агач, үлән

XX йөз башы татар шагыйре

Патша армиясендә кече командир

Башкорт халык биюе

Урта гасыр төрки әдәбияты ядкәре

Композитор ... Әхмәтов

Нота

Кем беләндер бер якта, төбәктә туган кеше

Хәким Хәйруллин романы

Кәрим Тинчурин драмасы

Татарстандагы район

... Намдаков (бурят сынчысы, рәссам)

Зәңгәр төстәге минерал, бакыр карбонаты

Иделле, Кашаф-Үзиле

Цирк клоуны (иск.)

Полк (бор.)

Сорау алмашлыгы

Шагыйрь-җан

Ярмәки, Мансур

Заһидулла, Фәрит, Мирсәет

Иван Тургенев повесте

Кәҗә мамыгын чистарта торган тарак

1917 елда Казанда Шәһит Әхмәдиев чыгарган газета

Урта гасыр болгар шәһәре

Борынгы рус баһадирлары турындагы героик хикәят

Дезинфекцияләү, кан туктату өчен кулланылучы таш

... -Вегас

Төрле төстән буй-буй сугылган киндер

«Ул» алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

Нәрсә буласын алдан күреп әйтеп бирүче

Грек хәрефе

Кабилә, халык, этник төркем (иск.)

Агач чиләк (диал.)

1912-1918 елларда Казанда татар телендә чыккан журнал

Кари, Камал

Камыштан ясалган үзбәк курае

4 нче санда дөнья күргән мирасворднын җаваплары:

Сулдан уңга: Сәет, вәхи, әл, бөят, Ләйлә, төер, һәдия, әрә, Сөн, Госман, намә, «Тәүбә», Блок, «Атака», тоба, шыт, фазыйләт, Рәхмәт, Аитова, Азин, Кари, Таҗи.

Өстән аска: Сибат, Гаттар, Сөббух, түтәрәм, Ла, Маари, Отар, Фәиз, «Һәнәк», Аттика, Онат, Вәлиди, Батыев, Нәкый, Агиш, Хәй, яса, Ашлы, илле, «Өмет», янә, аять

Рәис Габдулла төзеде.



СОДЕРЖАНИЕ. МАЙ 2017

Историческое наследие: «Булгар. Лагерь шатров»; «Юртские татары» И.Торопицын; «На пути сохранения высокой культуры: Габдельбари хазрат Исаев». А.Бустанов; «Татарские пленники в Финляндии» Ч.Сафиулла.

Духовное наследие: «Исламский мир» Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик. («Благодатное знание»)». Й.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана» Ч.Айтматов;

Татарский мир: «Деревня – колыбель нации» (круглый стол); «Прелесть жизни» (интервью главного редактора «Безнең мирас» Л.Лерона с Председателем Государственного Совета Республики Татарстан Ф.Х.Мухамметшиным).

Культурное наследие: «Музыкальные инструменты астраханских татар». Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин; «Размышления о языке » Х.Атласи.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: май 1917 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. MAY 2017

Historic heritage: «Bulgar. The camp of the tents»; «The Tatars of Urt» by I.Toropitsin; «On the way of the keeping high culture: Gabdelbari khazrat Isaev» by A.Bustanov; «The Tatar prisoners in Findland» by Ch. Safiulla.

Religious heritage: «The Islamic world» by G. Ibragimov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov.

The Tatar world: «The village is the nation's cradle» (round table); «The beauty of life» (the interview of L.Leron, the chief editor of «Our heritage» with chairman of the State Council ot the Republic of Tatarstan F.X.Mukhammetshin).

Creative heritage: «The musical instruments of Astrakhan Tatars» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «The reflection about language» Kh.Atlasy.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: May of 1917».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Кызыл күләгәле автопортрет». Киндер, майлы буяу. 1993 ел

ВИКТОР ФЁДОРОВ
(1940-2001)

СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы.

«Шиһабетдин Мәрҗани портреты». Киндер, майлы буяу. 1989 ел

«Тукай сүзе». (Тукай"«Сәйяр» труппасы белән). Киндер, майлы буяу. 1986 ел

АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ:

«Менә хикмәт! Аяз Гыйләҗевнең җиңгәчәе Ркаил Зәйдулланың әнисенең татар теле укытучысы булган икән. Фидания апа Шыгырданнан булса да бер хәл инде, диярсең! Аяз Гыйләҗев Ркаил Зәйдулла турында «Йәгез, бер дога!» романында: «... Рөстәм Сүлти яза, Ркаил Зәйдулла яза, аларның һәр язганы Ходай биргән талант югарылыгында калачак!» – ди. Ә Ркаил Зәйдулланың «Аяз Гыйләҗевкә» дигән шигырендә түбәндәге юллар бар:

Офыккача аклык бүген,
Ирексездән җаннарга йога.
Аксакалның эзләренә карыйм
һәм кабатлыйм: йәгез, бер дога!..»

Шыгырдан төене. **Фатих Кутлу**

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*

№06 / 2017